ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№2 (326) – ФЕВРАЛЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Казан форматындагы сөйләшү

Билгесез Фатих Кәрим

Казан тәхетендә – Кырым ханнары

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов,
Ната Смирнова, Алинә Әхмәдишина
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: Әфганстанда хезмәт иткән
Наил Гарифуллин һәм Фәнис Фәезов.
Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-410
Басарга кул куелды: 22.02.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ПАТРИОТИЗМ – СОКЛАНУ ҺӘМ ГОРУРЛАНУ УЛ

Февраль – традицион ир-егетләр ае. Һава шартлары буенча хәрбиләрчә кырыс булса да, кешелекнең көчле затларына карата – йомшак һәм кече күңелле ул. Табигать кар көбәсеннән ничек акрынлап кына арына башлый, безнең патриотик хисләребез дә бу айда шундыйрак халәткә килә. Ватанны саклаучылар көне уңаеннан гына, дип уйламагыз, без бу дулкынга һәрчак көйләнгән. Бу бәйрәмдә без искә алган һәм олылаган кыйммәтләрнең тормышта иң әһәмиятлеләре булганы өчен – бигрәк тә.

Әйтик, мәсәлән, Тәтешкә туристлар йөри торган маршрутларны барларга, Вшиха тавына карап сокланырга, могҗизалы балык музеена кереп хозурланырга барган җирдән без никтер, көтмәгәндә-уйламаганда, кадетлар мәктәбенә барып эләгәбез. «Ватанга мәхәббәтне көчләп тагып булмый, ә әкренләп сеңдерергә кирәк», – ди безгә әлеге мәктәпнең директоры Вил Нуруллин. Һәм, булачак хәрбиләргә тиңләпме икән, чын солдат боткасы белән сыйлый.

Кадетлар белән очрашканнан соң, без Тәтешнең төп хәзинәсе – кырпы балыгын авыз итәргә юл тотабыз. Кырпы бу шәһәрнең символы да әле ул. Аның һәйкәле шундый мул сый-нигъмәткә ия елгаларыбыз өчен горурланырга дәшеп, безнең балыкчыларга афәрин дияргә өндәп балкып тора. Ә бу балык никадәр кешене ачлыктан коткарып калган! Ничек сокланмыйсың да горурланмыйсың!

Безнең балалар да чып-чын офицерлар булып үсәр, дип ышанасы килә. Ванька Трофимов шикелле.

«Безнең балалар нәкъ менә үзләренең бабалары һәм бабаларының бабалары фашистны тар-мар итүен белеп үсәргә тиешләр», – ди Әлмәт активисты Александр Лапко. Ул Әлмәт һәм Татарстанның башка мәктәпләрендә укучы балаларга патриотлык турында лекцияләр укып йөри, Нюрнберг процессы турында сөйли. Балалар исә тын да алмый тыңлый, күзләреннән яшь бәреп чыга. Әнә шулай, тарих сәхифәләренә орынып карап, алар аның белән чын-чынлап горурланырга өйрәнә. Ә мондый горурлыкны тиз генә юк итәм димә.

Ә менә армиягә чакырылучының наказ кәгазе, аның чит-читләре кыршылып беткән. Авылдашлары биргән бу наказны сугышчы-интернационалистлар дембель альбомнарында утыз елдан артык кадерләп саклый. «Халык сиңа ышанып корал тапшыра. Яхшы хезмәтең белән батыр сугышчы бурычын ахыргача акла!» – диелә анда. Боларның әнә шул наказны кулларына алып солдат хезмәтенә китеп, Әфган кичкән егетләр икәнлеген без бүген хәтерлибезме соң?

Бәйрәм, дигәннән, Татарстанның яшь-яшь гүзәлләре безгә бу санда татарча азу пешерү серләрен дә өйрәтәчәк. Монысы да үзеннән-үзе килеп чыкты, димәк, шулай булырга тиеш булган!

Ярату һәм горурлык тойгысы – чын патриотик тойгылар ул! Без сезгә яңа саныбызны нәкъ менә шундый тәмләткечләр өстәп тәкъдим итәбез!

СЕЗНЕҢ ПАТРИОТЛАРЧА РЕДАКЦИЯГЕЗ.

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

Рашит Сәфиуллин «Свияжск утрау-шәһәре»

ФЕВРАЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. «Казан» форматындагы диалог.
Россия Президенты җәмәгатьчелек белән нәрсәләр турында сөйләште

11. Фән шәһәре. Киләчәккә бурычлар.
Цифрлы икътисад башкаласының перспективалары турында

20. Сәламәтлек марафоны.
Бассейннар кайларда пәйда булды

24. Көндәлек могҗиза.
Медицина – кәсеп түгел, сәнгать ул

30. Стратегик билгеләнештәге полигон.
Радиолокацион көрәштә кемнәр катнашачак

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

38. Язмышлар.
Йөз яшьтә дә ничек картаймаска

40. Кече Ватан патриотлары.
Билгесез Фатих Кәрим

46. Ватанга хезмәт итү – намус эше!
Ватанпәрвәрләрне кайда әзерлиләр

56. Мәхәббәт һәм миһербанлык рецепты.
Шаһиналәр кемне көтә

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

64. Сугыш тәмамланган көн.
Казанда совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуының 30 еллыгын ничек билгеләп үттеләр

70. Хәтергә уелып калган мизгелләр.
Ни өчен «әфганчыларның» «дембель альбом»нары булмаган

74. Алар безнең арада.
Иске альбомдагы бер фото

76. Татар авыллары.
Кыр Шонталасында кунакта

80. Тарихи сәхифә.
Казан тәхетендә – Кырым ханнары

84. Безнең киштәдә.
Бездән китмәгән дөньялар

90. Гаҗәеп балыклар.
Тәтеш музее раритетлары турында

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

30.01

Сергей Шойгу, Россиянең оборона министры, – Татарстанда, С. П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводындагы киңәшмә барышында:

– Кораллы Көчләр мәнфәгатьләрен истә тотып, Татарстан предприятиеләре дистәләгән эре дәүләт контрактын тормышка ашыра. Шул рәвешчә төбәк икътисадына сизелерлек инвестиция кертеп, Оборона министрлыгы аның үсешенә, эш урыннарының саны артуга, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә булышлык итә. Республика җитәкчелеге үз чиратында хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаиләләренең социаль проблемаларын хәл итүгә зур игътибар белән карый. Киләчәктә дә безнең хезмәттәшлек шундый ук уңышлы булыр дип өметләнәбез.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

29.01

Станислав Поздняков, Россиянең Олимпия комитеты президенты, – РФ территориясендә халыкара спорт ярышларын оештыру һәм үткәрү буенча ведомствоара комиссия утырышында:

– Казан алда булачак Европа уеннарын үткәрүгә үз гаризасын бирде. Россия Олимпия комитеты бу карарны тулысынча хуплый һәм гариза җиңсен өчен һәрьяклап ярдәм күрсәтергә әзер. Бүгенге көндә Татарстанда Россия буенча гына түгел, халыкара бәяләмәләр буенча да уникаль спорт инфраструктурасы булдырылды, ә республика башкаласы, Олимпия уеннарын да кертеп, теләсә нинди комплекслы чараны кабул итәргә һәм оештыруны иң югары дәрәҗәдә хәстәрләргә әзер. Соңгы елларда ул моны берничә тапкыр эшләде инде.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.01

Валерий Петросян, Россия табигать фәннәре академиясе вице-президенты, БМОның химик куркынычсызлык буенча эксперты, – чүплекләрнең җир йөзеннән юкка чыгарга тиешлеге турында:

– Татарстанда каты коммуналь калдыкларны термик зарарсызландыру буенча завод төзү карары бик вакытлы һәм бик тә дөрес кабул ителгән. Мин моны гаять кирәкле эш дип саныйм, чөнки мондый технологияләр бөтен дөньяда кулланыла, хәзерге вакытта мең ярымга якын чүп яндыру заводлары эшли. Алар экологик куркынычсызлыкның барлык заманча таләпләренә тулысынча җавап бирә торган бүгенге технологияләр буенча төзелгән.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА
ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан җәмәгатьчелеге
Владимир Путин белән **НИ** турында сөйләште

Иннополиста талантларны **НИЧЕК** әзерлиләр

Медицина детективын **КЕМНӘР** чишә

Радиолокацион көрәш
эшләнмәләрендә **КЕМНӘР** катнаша



ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК БЕЛӘН ДИАЛОГ: **КАЗАН ФОРМАТЫ**

Җәмәгатьчелек вәкилләре: эшкуарлар, ректорлар, төзүчеләр, укытучылар, студентлар... Казанда РФ Дәүләт Советы Президиумының халыкның торак шартларын яхшыртуга һәм уңайлы шәһәр мохите формалаштыруга багышланган утырышы алдыннан Россия Президенты Владимир Путин министрлар һәм губернаторларны түгел, нәкъ менә аларны җыеп сөйләште.

Автор:
Әскәр Сабиров

Популистлыкмы бу? Мөгаен, күбрәк сәламәт акылга таянудыр. Очрашуның модераторы Сергей Когогин (Гомумроссия халык фронты үзәк штабы рәистәше – *ред. иск.*) әйтүенчә, 12 февральдә Казанның «Мәскәү» мәдәният комплексында «җирдә» нәрсә баруын төгәл белүче кешеләр җыелды. Илдә «Торак һәм шәһәр мохите» проектының ни рәвешле гамәлгә кертелүенә алардан да яхшырак бәя бирүче табылырмы икән? Бу кешеләр үзләренең

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды (Марат Хәсәнов)

ишегаллары, урам һәм паркларының ничек үзгәрүен күрә, әлеге эштә үзләре турыдан-туры катнаша һәм, табигый ки, хакимият карарларының яхшымы-начармы булуын бәяләргә сәләтле. Һәм бәяләргә генә дә түгел – алар иң алдынгы карашлы чиновникның башына да килмәслек идеяләр тәкъдим итә ала.

МАКСАТ – ТЫРЫШЛЫКНЫ БЕРЛӘШТЕРҮ

Хакимият өчен мондый диалог никадәр мөһим? Сөйләшүне башлаганда ук Владимир Путин моның әһәмиятле генә түгел, бәлки зарур булуына басым ясады: «Милли проектларны уңышлы тормышка ашырыр өчен, федераль үзәк, төбәкләр, муниципалитетлар һәм, аңлашыла ки, барлык бу проектларны гамәлгә кертүдә турыдан-туры катнашучыларның уртак эшен җайлау бик мөһим. Безнең барыбызга да тырышлыгыбызны берләштерү зарур», – диде РФ Президенты.

Бурычның мөһимлеге стратегияне дә билгели. Җәмәгатьчелек белән яңа, Казан форматында сөйләшүнең, әгәр ул бер генә тапкыр үткәрелә икән, ил масштабында җитди нәтиҗәгә китерүе шикле, әлбәттә. Әмма Президент моңа да шундук ачыклык кертте: Татарстан башкаласындагы әлеге чара – үзенә күрә бер старт, «мондый очрашу, киңәшмә һәм фикер алышулар сериясенең башы» гына ул. Фикер алышу предметы – «үсешнең төп юнәлешләре буенча илнең алга барышын» тәэмин итәргә тиешле милли проектлар. «Белүегезчә, без моңа бик күп акча тәгаенләдек, финанслау чыганаклары, үсешнең өстенлекле юнәлешләре турында карар кабул иттек. Әмма боларның барысының да яхшы сәгать кебек эшләп китүе һәм куелган максатларга ирешү механизмнары, инструментларының бергә кушылуы кирәк».

ИКЪТИСАД ЛОКОМОТИВЫ БУЛАРАК ТОРАК МӘСЬӘЛӘСЕ

Хакимиятнең җәмәгатьчелек белән киңәшләшүенең ни өчен нәкъ менә «Торак һәм шәһәр мохите» милли проектыннан башлануы аңлашыла. Владимир Путин аеруча басым ясап әйткәнчә, «бу ил, җәмгыять, дәүләт үсешендәге фундаменталь бурычлардан берсе, чөнки яшәү мохитенең

сыйфаты, торак мәсьәләләрен хәл итү җәмгыятьтәге кәефнең нинди буласын билгеләп кенә калмый», бәлки, Россия икътисадының «үзләре артыннан башка юнәлешләрне дә иярткән» тулы бер секторлары үсешенә йогынты ясый. Шул ук вакытта максат җиңелләрдән түгел. Президент әйтүенчә, берьюлы ике бурычны хәл итү зарур: бер яктан, үсеш һәм төзелешкә стимул бирү, икенче яктан караганда исә эшне оештыруның заманча, цивилизацияле ысулларына күчү, анда инде озакка сузылган төзелешләр һәм алданган өлешчеләр булмаска тиеш.

Казанда әлеге «мәгълүмат алмашу җыенын» ачканда, Владимир Путин анда җыелучыларны сораулар белән генә чикләнмәскә чакырды. «Минем, барыннан да бигрәк, сезне, сезнең уй-фикерләрегезне, борчуларыгызны ишетәсем килә. Россия Федерациясе төбәкләре җитәкчеләре белән бүгенге очрашуда карар кабул иткәндә, без аларны исәпкә алыр идек», – диде РФ Президенты.

Җәмәгатьчелек вәкилләре белән аралашу Президентның өметләрен акладымы икән? Очрашуда катнашучыларның чыгышлары бу сорауга җавап булыр кебек. Аларның безнең карашка аеруча мөһим тоелган кайберләрен сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәбез.

Илшат Гафуров,
ГХФ төбәк штабы рәистәше:

– Чүп-чар җыйган өчен түләү кайбер урыннарда – ике тапкырга, кайдадыр өч тапкырга артты. Халык аптырашта: «Бу нәрсәгә бәйле соң? Безгә хезмәт күрсәтү сыйфаты яхшырдымы, әллә бездә төбәк операторлары пәйда булдымы?» – дигән сорау еш ишетелә. Урамга чыккач, без чүп-чар җыю урыннарының һаман да шундый ук хәлдә икәнен күрәбез. Алай гына да түгел, җаваплылык бүленеше күзәтелә – элегрәк контейнерлы участоклар, чүп җыю урыннары өчен идарәче компания җаваплы булса, хәзер участоклар өчен идарәче компания, ә контейнерлар өчен төбәк операторы хисап тота. Гайре табигый хәлләр дә очрый. Менә чүп ята, миңа: «Ә бу калдыклар контейнерны тәэп киткәндә коелган, шуңа аны идарәче компания түгел, бәлки төбәк операторы вәкилләре җыярга тиеш», – диләр. Минемчә, әлеге проектка анyклык кертергә һәм төбәк операторлары җаваплылыгын төгәл билгеләргә кирәк.

Икенче момент. Элек чүп түккән өчен түләү квадрат метрларга пропорциональ булса, хәзер ул фатирда теркәлүчеләр санына пропорциональ. Барысы да дөрес, чөнки чүп-чар кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә пәйда була. Икенче яктан караганда, аз метражлы фатирларда безнең халыкның аеруча социаль якланмаган өлеше яши, һәм хәзер нәкъ менә аларга ике, өч, дүрт тапкыр күбрәк түләргә туры килә. Минемчә, халыкның бу өлешенең хәлен җиңеләйтерлек нинди дер субсидияләр каралырга тиеш булгандыр.

Һәм өченчесе. Бик күп халык кече торак пунктларда яши, аларга чүп-чар реформасы тиз арада гына барып җитмәс әле. Шәһәр шәһәр инде ул, күпчелек халкы пенсионер булган авыл исә – бөтенләй башка. Шунлыктан, мөгаен, аларны беренче елны гына булса да мәҗбүри түләүдән азат итү максатка ярашлыдыр.

Дамир Нургалиев,
ГХФның ТРндагы яшьләр бүлеге:

– Чүп-чар реформасының кимчелеге аның турында мәгълүматның бөтенләй диярлек булмавында да. Моннан чыгып, без РФнең һәр гражданы ала торган түләү квитанциясенә төбәк операторының телефон номерын һәм каты коммуналь калдыкларны түгү графигын өстәргә тәкъдим итәбез. Әлбәттә, әлеге телефон эшли торган булсын һәм теләгән һәркем шалтыратып, үзен борчыган проблема белән уртаклаша, үзен кызыксындырган сорауга җавап таба алсын. Без шулай ук төбәк операторының халык белән очрашуларын оештырырга тәкъдим итәбез – чүпне кая ташлау һәм аны кайдан алып китү өчен җайлырак урынны ике як килешеп хәл итсен.

Анастасия Ярёменко,
Казаннан «Архитекторы. РФ»
программасы финалчысы:

– Бу программа кысаларында финалда минем темам «Казан шәһәре онкология диспансерының сәламәтлек архитектурасы» дип атала иде. Мин үзем дә әлеге диспансерда дәваландым һәм яхшы беләм: депрессив мохиттә яман чиргә каршы көрәшү бик кыен. Әгәр төссез, әчпошыргыч, ямьсез тирәлек чолгап алган икән, син үзеңне искиткеч хәлсез, зәгыйфь тоясың.

Мин медицина учреждениеләре өчен саклагыч, сәламәтләндерә торган мохит булдырырга тәкъдим итәм. Ул фәнни дәлилләнгән дизайнга нигезләнәчәк. Әлеге фәнни методлар сыналган, һәм аларның кеше сәламәтлегенә уңай тәэсире дәлилләнгән. Әлеге ысуллар бөтен дөньяда диярлек

күптәннән һәм шактый уңышлы кулланыла.

Мин саклагыч һәм сәламәтләндергеч дизайн принципларын барлык медицина учреждениеләрендә куллану мөмкинлеге бирәчәк карар кабул итәргә өндим. Без, үз ягыбыздан, объектларны сәламәтлек саклауны үстерү программасына кертеп, сәламәтләндерү дизайны методларын медицина учреждениеләрендә ничек кулланып булуны Татарстандагы пилот проектта күрсәтергә әзер.

Надежда Снигирёва, архитектор һәм гавами катнашулар буенча белгеч:

– Мин Татарстанга моннан өч ел элек җәмәгать урыннары программасы буенча эшләргә дип килдем. Бу вакыт эчендә бездә инде 300 дән артыграк парк, сквер, яр буе проекты гамәлгә кертелде. Безнең методология – бергәләп проектлау, хәтта башлангыч этапта халыктан бернинди тәкъдимнәр кермәгән очракта да, проектларны барлык этапларда да кешеләр белән бергәләшеп эшләүгә юнәлтелгән. Әмма, кызганычка, бүген барлык шәһәрләр дә үзендә яшәүчеләр сүзенә колак салмый һәм моны игътибарга лаек дип санамый. Мәсәлән, минем туган шәһәрем Вологдада хәзер яр буен төзекләндерүнең резонанслы проекты тормышка ашырыла: тарихи үзәктә елганы бетон астында калдыралар, агачларны кисәләр. Халык та, экспертлар да, шәһәр мәнфәгатьләрен яклаучылар да моңа каршы, әмма безне ишетмиләр. Гамәлдәге законнарда халык үз шәһәренә йогынты ясый алырлык бернинди легитим инструментлар да юк. Гавами тыңлаулар оештырыла, әлбәттә, әмма, дөресен әйткәндә, алар бик нәтиҗәле инструмент түгел, чөнки аларда инде алдан ук килештерелгән мәсьәләләр тикшерелә, һәм халыкның монда катнашасы килми.

Гамәлдәге законнарны ничек тә үзгәртеп булырмы? Без коллегаларым белән хәтта конкрет тәкъдимнәр дә әзерләдек, рөхсәт итсәгез, мин аларны Россия Федерациясе Төзелеш министрлыгына, Дәүләт Советының эшче төркеменә тапшырыр идем. Һәм тагын бер нәрсә. Төрле белгечләр, архитекторлар гына түгел, бәлки юристлар, җәмәгатьчелек белән эшләүче белгечләр дә безнең тәкъдимнәрне өйрәнсен, гамәлдәге законнарны илебез халкы мәнфәгатьләрендә актуальләштерсен өчен, экспертлар мәйданчыгы төзү мөмкинме? Әгәр бу мөмкин булса, экспертлар төркемен Дәүләт Советы базасында да, Рөстәм Нургали улы Миңнехановкаршындагы эшче төркем базасында да оештырып булыр иде.

Александр Даренков, Татарстан Республикасы Җәмәгать әһелләре берлеге, «Доступный дворовый спорт» проекты җитәкчесе:

– Әгәр ишегалларында буш урын бар икән, аны гадәттә машина кую өчен файдаланалар. Кайчакта теннис кортына яки зур булмаган спорт мәйданчыгына урын табыла. Тик еш кына мондый урын табылмый. Ягъни ишегалдында әйбәт эскәмияләр, нәни балалар өчен уенчык таулар тора, ә менә үсмерләргә туп тибәрлек мәйданчык юк. Бу нормаль хәлме? Ярый әле һәрбер мәктәп янында диярлек төзелгән хоккей тартмалары коткара. Әмма йортларны салганда ук ишегалдында барлык кирәкле мәйданчыклар өчен урын калдырылса, шәп булыр иде. Без шундук балачакта уйнаган уеннарны искә төшерер идек. Безнең инде тренерларыбыз да бар. Менә шундый теләк.

Михаил Бейлин, архитектор, Мәскәү:

– Бүген Россиядә бик күп торак төзелә, әмма, минемчә, проблема шунда: еш кына әлеге процесста ни өчендер архитекторга урын бөтенләй табылмый. Бу – авторсыз архитектура, аны төзелеш компаниясе, техник институтлар проектлаштыра, искергән технологияләр файдаланыла, үз йөзе булмаган проектчы планлаштырганга, еш кына продукт үзе дә

шундый ук төссез килеп чыга. Иң мөһиме, бу йортлар шәһәр мохитеннән мәхрүм, алар ниндидер кеше тулы шкафны яки саклау урынын хәтерләтә.

Шундый үтенечем яки тәкъдимем бар: Дәүләт Советының тиешле комиссиясендә түбәндәге мәсьәлә каралсын иде – объектларны гамәлгә керткәндә, шәһәрләрнең тарихи мохите мәҗбүри сакланып, проектның архитектура ягыннан югары сыйфатлы һәм кеше өчен яшәү мохитенең югары сыйфатлы булуы мәҗбүри шарт итеп куелырга тиеш. Проектлар төзүчене проект авторы алыштырсын иде, бу кеше тормышына һичшиксез уңай йогынты ясаячак.

**Айрат Гыймадетдинов,
Татарстан Республикасы
Иҗтимагый палатасы әгъзасы:**

– Безнең республикада җәмәгать контроленең уникаль инструменты бар, ул «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы» дип атала. Аның асылы шунда: теләгән һәр кеше, үзен борчыган проблеманы күрсәтеп һәм фотоәлилләр китереп, республика дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталына гариза бирә ала. Портал кагыйдәләре буенча, 10 көн эчендә вәкаләтле дәүләт органы гаризаны карарга тиеш: яки аның тикшерергә алынуын хәбәр итә, яки, сәбәбен күрсәтеп, баш тарта. Система инде 2012 елдан бирле эшли, һәм бу чорда 190 меңнән артыграк гариза кергән. Әлеге гаризаларның 87 проценты канәгатьләндерелгән, проблемалар хәл ителгән, тагын 6 проценты хәл ителү стадиясендә… Үтенечләрнең өчтән бердән артыгы нәкъ менә төзекләндерү белән бәйле. Халык әлеге программадан файдалана, гариза яза һәм проблемаларны хәл итә: шугалаклар ясала, балалар мәйданчыклары төзекләндерелә, ишегалды территорияләре тәртипкә китерелә.

Программаның шундый файдалы булуын һәм күп еллар буена үзен яхшы яктан гына күрсәтүен исәпкә алып, ихтимал, аны башка төбәкләргә дә тарату һәм шул мәнфәгатьләрне кайгырта торган милли проектка кертү дә мәслихәттер.

**Лилия Мөхәммәтҗанова,
педагог-психолог, ГХФ штабы:**

– Мине шәһәр читләре, эшче районнар борчый, анда да бит шундый ук халык яши. Ягъни бездә шәһәр үзәге кайгыртыла, анда парклар, скверлар булдырыла, ә кырыйдагы эшчеләр яши торган районнар, кагыйдә буларак, федераль программага кертелми. Нәкъ менә шул районнарны кайгырта торган федераль программа булсын иде.

**Андрей Медведев,
ГХФның төбәк бүлеге:**

– Гомумроссия халык фронты инициативасы буенча үз вакытында шәһәрләрдә һәм шәһәр тирәләрендә парк зоналарын һәм урманнарны саклау турында закон кабул ителгән иде. Без Иҗтимагый палатасы белән бергәләп гавами тыңлаулар үткәрдек. Алар нәтиҗәсе буенча ТР Дәүләт Советына, конкрет объектларны, урманнарны, рекреация зоналарын күрсәтеп, үз киңәш-тәләкләребезне юлладык. Парламентарийларга яшел калкан турында республика законын кабул итү мәсьәләсен җиңеләйтергә теләгән идек. Әмма бу закон әлегә кадәр кабул ителмәгән. Безгә килеп ирешкән мәгълүмат буенча, шәһәр төзелеше планы тиздән Мәскәүгә тикшерүгә һәм раслануга җибәреләчәк. Бу план кабул ителсә, ә яшел калкан турында закон әле чыгарылмаса, нәрсә буласын күз алдына китерәсезме? Беренчедән, без яшел калкансыз калачакбыз. Икенчедән, калада гамәлдә булган шәһәр төзү регламентлары зоналары каршылыкка керәчәк. Кайсы участоклар өчен курыкканыбыз турында без конкрет мәгълүмат бирә алабыз. 1,2 гектарлы рекреация зонасы бар, ул хосусый милеккә тапшырылган. Анда исә егерме-утыз еллык наратлар үсә. Чираттагы гамәл – хәйләкәр,

әйтик, шәһәр тыңлаулары үткәрү. Аннары зоналарны кабат булэчәкләр дә, шәһәребез үзенең үпкәсе булган яшел зоналардан колак кагачак...

Денис Леонтьев, «Стрелка» КБ:
– Бүген без шәһәрләрдә тиражлаган нәрсә – моннан 60–70 ел элек булган индустриаль шәһәр төзелешен кабатлау ул. Без шул заманнан бирле һаман шул ук проектларны кабат җитештерәбез. Торак төзелеше модельләрен комплекслы үзгәртергә, кешегә туры китерелгән мохит нигезендә яңаларын булдырырга кирәк. Бу – шәһәрдә бик үк биек булмаган уртача һәм аз катлы йортлар төзү. Асылда, федераль дәрәҗәдә, күп дигәндә, 30 үзгәреш кертергә кирәк, алар процессны эшләтеп җибәрергә һәм бу мохитне торгызырга, сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирер иде. Әлеге 30 үзгәрешне кертү катлаулырак, әлбәттә, тик ул материаллар индустриясен дә үз артыннан иярттер, девелоперларны да үзгәрергә мәҗбүр итәр иде. Бары тик шул очракта гына без иминлек, уңайлылык, төрлелек ягыннан замана кешесе таләпләренә җавап бирерлек шәһәрләр яки сыйфатлы шәһәр мохите булдыру процессын кузгатып җибәрә алачакбыз.

ӘЙТКӘН – ЭШЛӘНӘЧӘКМЕ?

Яңа, Казан форматындагы «Президент – җәмәгатьчелек» диалогы никадәр файдалы соң? Сүз дә юк, бу сорауга тулы җавапны без бераз вакыт үткәч, очрашуда катнашучыларның идея һәм проблемалары конкрет карарларга әйләнгәч кенә алачакбыз. Әмма кайбер нәтиҗәләрне инде хәзер үк ясап була. Беренчедән, Владимир Путин белән иреклe, беркетмә шартларына бәйсез һәм цензурасыз аралашу ил җитәкчесенә башкала хакимияте коридорларындагылар белмәгән проблемаларны җиткерергә ярдәм итте. Ведомство коридорларында туа алмаган конкрет тәкъдимнәр белән дә шулай ук – килешәсездер, «түбәннән» кайчагында яхшырак күренә.

Икенчедән, әлеге тәкъдимнәрнең бер өлеше, Президент реакциясеннән күренгәнчә, инде каләм очына алынды, кайбер идеяләргә исә Казандагы диалог барышында ук «яшел урам» вәгъдә ителде. Мәсәлән, Илшат Гафуровның «чүп-чар реформасын» камилләштерү турында тәкъдименнән соң ук Владимир Путин киләчәктәге гамәлләр векторын билгеләде: «Беренчедән, муниципалитетлар һәм төбәкләр читкә кагылырга тиеш түгел, җаваплылыкны муниципалитетлар, идарәче компанияләр һәм төбәк операторлары арасында бүлү зарур. Бу без мөмкин кадәр якын арада эшләргә тиешле эш», – диде.

Президент Анастасия Ярёменконың медицина учреждениеләрендә сәламәтләндергеч мохит тудыру зарурлыгы идеясен дә хуплады: «Һичшиксез, кешеләргә файда китергән һәрнәрсәне кулланырга кирәк. Һәм без сез әйткән идеяләрне нинди программаларга һәм нинди күләмдә кертеп һәм тормышка ашырып буласын тикшерәчәкбез», – диде ул.

Андрей Медведевның шәһәр читендәге парк һәм урманнарның кайчагында артык эшлекле төзүчеләрдән зыян күрүе турында хафалануын да Владимир Путин бик җитди кабул итте. Һәм хәтта «үзләренә карата шик туганнарга» һәрвакыттагыча бик конкрет сигнал да юллады: «Бу уңайдан Казанга карата гына түгел, гомумиләштереп әйтәсем килә. Әлбәттә, бизнесның бурычы – табыш алу, әмма үзеңнең капиталыңны гына түгел, үзеңә булган хөрмәтне саклап калу да бик мөһим. Чөнки халык ихтирамы җуела икән, шуннан соң ук капиталсыз да калырга мөмкин...»

Соңрак, Дәүләт Советы Президиумы утырышын ачканда, Владимир Путин төбәк җитәкчеләренә игътибарны җәмәгатьчелек вәкилләре билгеләгән «авырту нокталарына» юнәлтергә кушты: «Хәзер Гомумроссия халык фронты вәкилләре бик гади нәрсәгә – шәһәр кырыендагы бистәләргә игътибар бирде. Кайчагында хәтта уңышлы, зур мегаполисларда да шәһәр читендә яшәүчеләр хакында оныталар... Мондый районнар социаль инфраструктура, балалар бакчалары, хастаханәләр, поликлиникалар һәм башкалар белән генә тәэмин ителү белән бергә, андагы җәмәгать урыннары да заманча һәм бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек булырга тиеш», – диде Президент.

...Һичшиксез, җәмәгатьчелек белән Казан форматында очрашу үзен аклый. Президент хаклы: «халыкны проектлар формалаштыру эшенә беренче этапта җәлеп итү бик файдалы булачак». Әгәр мондый очрашуларны югары дәрәҗәдә генә үткәрүгә кайтарып калдырмасалар, аларның файдасы тагын да зуррак булыр. Мөгаен, милли һәм төбәк проектларын уңышлы итеп тормышка ашыру өчен җәмәгатьчелек вәкилләренең губернаторлар, муниципаль район башлыклары, мэрлар белән профильле очрашулары да бары тик файда гына китерер. Ихтимал, бу очракта «түбәннән» кергән тәкъдимнәрнең бер өлешен үз көчләре белән, үз вәкаләтләре кысаларында да тормышка ашырып булыр. «Авыр артиллерияне» борчымыйча һәм аның куәтен локаль бурычларга сарыф итмичә дә файда китереп була бит.

www.protatarstan.ru
Поиск...
Подписка!
РУС
ТАТ
ТАТАРСТАН
Мәңгелек
Игелекле
Әһәмиятле
Милли киемнәр
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
20 февраля 2019
19 февраля 2019
Төбәк тарихы кемгә кирәк?
Авыллар турындагы китаплар. Белгечләр белән сөйләшү
«Динамо-Казан» һәм «Махеевъ»: һәрчак җиңүгә йөз тотып
Нурлат яны: су тегермәне
Tar Uram ur.
Ул. Тар Урам
6
Более 200 госуслуг онлайн
uslugi.tatarstan.ru
Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә… Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

ШВЕЙЦАРИЯ АЛЬПЛАРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

Фото ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды

НӘРСӘ:

Бөтендөнья икътисадый форумы

КАЙДА:

Давос, Швейцария

КАЙЧАН:

21–23 гыйнвар

ТУЛЫРАК:

Татарстан Президенты Давоска Россия икътисадый үсеш министры Максим Орешкин җитәкчелегендәге Россиянең рәсми делегациясе составында барды. «Глобальләшү 4.0: Дүртенче индустриаль революция чорында глобаль архитектураны формалаштыру» – халыкара форумының төп темасы шулай билгеләнде. РФ икътисады үсеше, чит ил инвестицияләрен җәлеп итү, шулай ук әлеге процессларда төбәкләрнең роле мәсьәләләренә багышланган «Россиянең көндәшлеккә сәләтлелеген саклау» сессиясендә чыгыш ясап, Рөстәм Миңнеханов икътисадый санкцияләрнең ике якка да тискәре йогынты ясавын билгеләп үтте. Әмма шулай да чит ил компанияләре Россия территориясендә эшләвен дәвам итә, биредә коммерциячел проектларын гамәлгә ашырырга да әзер алар. Әлеге җәһәттән Татарстан Президенты «КАМАЗ» белән «Daimler» компаниясенең хезмәттәшлеген мисалга китерде. Быел компанияләр кабина каркаслары җитештерү буенча уртак завод ачарга планлаштыра, предприятиенең еллык куәте 55 мең данә кабина булачак. «Узган елда Санкт-Петербургта узган форумда «Түбән Кама Нефтехим» һәм «Deutsche Bank» компанияләре арасында 807 миллион евролык кредит килешүе имзаланган иде. Акчалар эре этилен комплексы төзелеше проектын финанслауга юлланачак», – дип сөйләде Рөстәм Миңнеханов. ТР Президенты бүген Татарстанның гарәп илләре, Урта Азия дәүләтләре белән яхшы мөнәсәбәтләр урнаштыруын билгеләп үтте: «Аерым алганда, Төркия төп инвесторларыбызның берсе булып тора. Соңгы 7–8 ел эчендә республика территориясендә ун эре төрек заводы ачылды». Ел саен үткәрелә торган «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммиты да мөселман илләрендә зур кызыксыну уята.

ПЕРСПЕКТИВАЛАР:

Форум вакытында Рөстәм Миңнеханов чит ил компанияләре вәкилләре белән сөйләшүләр алып барды. Royal Philips компаниясенең халыкара базарлар буенча директоры Хенк де Йонг белән очрашу барышында медицина өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү мәсьәләләре тикшерелде. Уртак проектларны эшләү перспективалары каралды, шул исәптән – республика территориясендә атом-төш медицинасы кластерын булдыру өлкәсенә караганнары да. Авыл хуҗалыгы культураларын саклау чаралары, махсус химия продукциясе һәм башка химикатлар җитештерү буенча дөньяда әйдәп баручы компания саналган United Phosphorus җитәкчелеге белән оештырылган очрашуда минераль ашламалар җитештерү тармагында ихтимал булган хезмәттәшлек мәсьәләләре тикшерелде.

БЕЛЕШМӘ:

Быел Давоста узган Бөтендөнья икътисадый форумы дистәләгән ил лидерларын һәм эре бизнес вәкилләрен үзендә җыйды – бирегә барлыгы 110 илдән 3 меңнән артык катнашучы килгән иде. Стратегик сессияләрдә катнашучылар, атап әйткәндә, энергиянең альтернатив чыганакларын, цифрлы икътисадны үстерү темалары, дүртенче сәнәгать революциясе чорында глобальләшүне формалаштыру һәм әлеге процесста катнашучыларның хезмәттәшлеге сораулары буенча фикер алыштылар. Башка темалар: «Технологияләргә контрольлек итүнең киләчәк чикләре» (сәүдә, инвестицияләр һәм оборона сферасында идарә формалаштыруга глобаль технологик лидерлык буенча көндәшлекнең йогынтысы), «Стратегик инфраструктураның киләчәк чикләре» (бүгенге глобаль инфраструктур проектларның стратегик мәгънәсе), «Региональ дипломатия/Россия-Европа» (Россия һәм Евроберлекнең үзара мөнәсәбәтләре перспективалары).

ИННОПОЛИС: ЦИФРЛЫ ҮСЕШ ФЛАГМАНЫ

Фото ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды (Марсель Бадыйкшин)

НӘРСӘ:

Иннополис ИТ-шәһәрен үстерү сораулары буенча киңәшмә

КАЙДА:

Иннополис, Татарстанның Югары Ослан районы

КАЙЧАН:

5 февраль

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты:

– Иннополис цифрлы икътисад буенча милли проектка бик яхшы яраша. Аны мондый белем бирү һәм тикшеренү үзәкләреннән башка гамәлгә ашыру гаять катлаулы булачак.

ТУЛЫРАК:

Иннополис Университетының үстерү концепциясе, аның эшчәнлеген финанслау, һәм шулай ук фән шәһәре резидентларына дәүләт ярдәме чаралары системасы – Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Максим Акимов уздырган киңәшмәдә тикшерелгән төп сораулар шулар. Аның эшендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР вице-премьеры – ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов, «Иннополис Университеты» ЮББ АКБО Күзәтчелек советы рәисе Николай Никифоров һәм башкалар катнашты. Киңәшмәне ачканда РФ вице-премьеры шуны билгеләп үтте: Иннополис Университеты илдә цифрлы үсеш проектлары флагманнарының берсе булып тора. Аның фикеренчә, университет белем бирү учреждениесе генә түгел, бәлки бөтен ИТ-шәһәр экосистемасының өлеше дә. «Бүген Иннополис Россиядә цифрлы икътисадны үстерүдә төп үзәкләрнең берсе санала. Һәр яңа эштә ниндидер авырлыклар очрый. Уртак тырышлык белән куелган бурычларны тормышка ашырырбыз, дип ышанам», – дип басым ясады Максим Акимов. Үз чиратында Татарстан Президенты ИТ-шәһәрдә инде 170кә якын компания исәпләнүен, алар арасына «Иннополис» МИЗның 77 резиденты һәм махсус зонаның 9 партнеры керүен искә төшереп үтте. «Шулай да иң мөһиме – университет. Бүген ул шактый күркәм нәтиҗәләр күрсәтә. Эшебезне көчәйтергә, университет алдына яңа бурычлар куярга һәм уку йортына ярдәм итәргә кирәк. Үзебезгә килгәндә, без әлеге процессларда актив катнашабыз», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

БЕЛЕШМӘ:

Бүген Иннополиста дүрт меңнән артык кеше яши һәм эшли. 18 күпфатирлы йорт төзелгән (аларның икесе узган ел кулланышка тапшырылды) – бу меңнән артык фатир дигән сүз. Шәһәрлеләр тормышын уңайлы итәр өчен инфраструктура системалы рәвештә үстерелә, пилотсыз такси һәм 5G технологияләрен гамәлгә кертү проектлары тормышка ашырыла. Иннополис Университетында «Цифрлы икътисад» программасы кысаларында 4D геомәгълүмат платформасы нигезендә Татарстанның цифрлы моделе проекты эшләнә. Модель күп кенә тармак проблемаларын уңышлы хәл итәргә булышачак: авыл хуҗалыгында кыр-басуларның торышын анализларга, шәһәр сервисларын үстерергә, су саклау зоналарын мониторингларга, чыганакларның 3D-моделен һәм башкаларны төзергә.

Максим Акимов,
РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары:

– Иң югары трибуналардан цифрлы үсешнең «тимер»дән генә тормавы, ягъни алгоритмнар һәм технологияләргә генә ия булмавы турындагы сүзләр шактый күп яңгырады. Беренче чиратта, ул кешеләр, талантлар, аларның энергияләре, амбицияләре, белемнәре, элемтәләре, кооперациядә эшли алу сәләтләре – боларның барысын да кешеләргә университет белеме бирә. Һәм Иннополис Университеты әлеге билгеләмәгә тулысынча җавап бирә.



СОЧИ.
МИЛЛИ ПРОЕКТЛАР – КИЛӘЧӘККӘ АЧКЫЧ

ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды (Михаил Фролов)

НӘРСӘ:

Россия инвестиция форумы

КАЙДА:

Сочи

КАЙЧАН:

14–15 февраль

ТУЛЫРАК:

РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев «Уңыш факторлары: идеяләр, кадрлар, компетенцияләр» форумының пленар утырышында катнашты һәм РФ субъектларының башлыклары белән очрашты. Очрашуда, аерым алганда, илдә яңа алгарышлы үсеш территорияләре төзеләчәген хәбәр итте, шул исәптән – Татарстанда «Менделеевск» алгарышлы үсеш территориясе. Сочида шулай ук РФ төбәкләренең социаль-икътисадый үсеш буенча иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча Бөтенроссия конкурсына нәтиҗәләр ясалды. Татарстанның өч проекты җиңүче дип табылды: «Социаль сферада хезмәт күрсәтүнең ачыклыгын тәэмин итү» номинациясендә – «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» Дәүләт мәгълүмат системасы; «Төбәкнең мәгълүмати-технологик куәтен үстерүгә юнәлдерелгән шартларны төзү» номинациясендә – «Ачык Казан»; «Төбәкнең туристик потенциалын үстерү» номинациясендә – «Visit Tatarstan» Рәсми туристик бренды.
Сочида Россиянең Турыдан-туры инвестицияләр фонды генераль директоры Кирилл Дмитриев, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Филипс» ҖЧҖ генераль директоры Максим Кузнецов, Россия Премьер-министры Дмитрий Медведев катнашлыгында, «Россиянең Турыдан-туры инвестицияләр фонды Идарәче компаниясе» АҖ , ТР Хөкүмәте һәм «Филипс» ҖЧҖ арасында үзара аңлашу турында меморандумны имзаладылар. Документ медицина өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерүне күз уңында тота. Татарстан өчен республика территориясендә сәламәтлек саклау өлкәсенә заманча технологияләр кертү һәм нур диагностикасы өлкәсенә караган уртак проектларны гамәлгә ашыру перспективалы тоела.
Форум барышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Пенза өлкәсе губернаторы Иван Белозерцев икътисад, социаль һәм башка сфераларда хезмәттәшлек итү турында төбәкара база килешүенә кул куйдылар. Карелия Республикасы башлыгы Артур Парфенчиков белән очрашуда 2021 елга кадәрге чорга Төбәкара килешүне гамәлгә ашыру буенча уртак чаралар планы кабул ителде. Новгород өлкәсе губернаторы Андрей Никитин белән Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында хөкүмәтара килешү һәм аны гамәлгә ашыру буенча Чаралар планы имзалады.
Татарстан Хөкүмәте һәм «Дюраселл Раша» арасында ТРнда токның эшкәртелгән химик чыганакларын аерып җыю, туплау һәм утильләштерү системасын үстерү сферасында хезмәттәшлек турында килешү төзү бизнес-җәмәгатьчелек вәкилләре белән сөйләшүләр нәтиҗәләренең берсе булды.

Россия Федерациясе төбәкләренең социаль-икътисадый үсешенең иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча Бөтенроссия конкурсы Яңа проектларны алга этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы инициативасы буенча уздырыла. Максат – социаль-икътисадый үсешкә караган уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны (проектларны) ачыклау, сайлау, тасвирлау һәм тарату аша РФ субъектлары территорияләрендә социаль-икътисадый проблемаларны хәл итүдә булышу. 2018 ел йомгаклары буенча конкурс финалистлары исемлегенә Россиянең конкурс критерийларына максималь рәвештә туры килгән һәм 8 номинациянең һәркайсында уртача иң күп тавыш җыйган 16 төбәгеннән 27 тәҗрибә кергән.

БЕЛЕШМӘ:

Сочида узган Россия инвестицион форумының төп темасы – «Милли проектлар: стратегиядән – гамәлләргә». Форумның эшлекле программасы чаралары РФ субъектларында милли проектларны гамәлгә ашыруның төрле аспектларына багышланган иде. 2018 елда форумда Россия төбәкләренең күпчелегеннән һәм 63 илдән килгән 6000нән артык кеше катнашты. Форумның 55 эшлекле чарасында 500 гә якын күренекле спикер һәм модератор чыгыш ясады, шул исәптән төбәкләр, эре компанияләр һәм эшлекле берләшмәләрнең җитәкчеләре дә. Форум вакытында 790 млрд сумга исәпләнгән төрле характердагы 583 килешү төзелде.



ХАЛЫКАРА ПРОЕКТЛАР КАТАЛИЗАТОРЫ

«Алабуга» МИЗ территориясендә урнашкан «Ford Sollers» заводы конвейерыннан Россия җитештерүендәге йөзләрчә двигатель төшә. Моңа бер үк вакытта предприятиене реконструкцияләүнең нигезенә сыйфатлы һәм нәтиҗәле проект салыну сәбәбе белән дә ирешелде. Нәкъ менә шундый проектлар «Казан Гипронииавиапромы» АҖ компанияләре төркеменең визит карточкасы булып тора да инде.

Тупланган уникаль тәҗрибәсе, белгечләренең квалификациясе нәтиҗәсендә предприятие 2000 нче еллар башында ук авиасәнәгать һәм оборона объектларын һәм җитештерүләрен проектлаштыруга караган махсуслашу кысаларына гына сыешмый башлады. «Алабуга» МИЗнда Fiat автомобильләрен җитештерү заводы – «Казан Гипронииавиапромы» өчен автомобиль төзелеше өлкәсендә беренче эре проектларның берсе булды.

Институтның әлеге юнәлештәге эше 2005 елда башланды, ул чакта Fiat Ducato һәм SsangYong автомобильләрен җитештерү проектын булдыру заказы белән оешмага «Северстальавто – Алабуга» ААҖ уртак предприятиесе (соңыннан «Соллерс – Алабуга» ҖЧҖ) вәкилләре мөрәҗәгать иткән иде. Шушы заказ кысаларында «Казан Гипронииавиапромы» белгечләре тарафыннан гамәлдәге 601 нче логистика корпусы мәйданында автомобиль җитештерүнең эретеп-ябыштыру, буяу һәм җыю хезмәтләре проектлаштырылды. Җитештерү комплексының гомуми мәйданы 100 мең квадрат метрга якынлашты. Проект уңышлы рәвештә тормышка ашырылды. Заводның ачылышы 2007 елга туры килде. Проект егәрлекләренә чыкканнан соң, җитештерү күләмнәре Rexton, Kayron һәм Actyon модельләрендәге 25 мең SsangYong автомобилен, һәм шулай ук үндүрт модификациядәге 75 мең пассажирлар ташучы Fiat Ducato модельләрен тәшкил итте.

Тагын биш елдан соң, «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ уртак предприятиесен булдырган «Соллерс» ААҖ һәм Ford Motor Company бу мәйданнарда автомобильләр һәм Ford двигательләрен җитештерү буенча яңа заводлар урнаштырырга карар кылдылар. Шушы заказга бәйле рәвештә, «Казан Гипронииавиапромы» белгечләре күп пролётлы 601 нче корпусны елына 100 мең автомобиль җитештерерлек итеп, Ford Transit, Ford Kuga, Ford Explorer автомобильләрен җитештерүнең эретеп-ябыштыру, буяу һәм җыю хезмәтләренә көйләп реконструкцияләү проектын башкардылар. Институт шулай ук гомуми мәйданы 50 мең квадрат метрны тәшкил иткән һәм елына 200 мең эшләнмә җитештерү күләменә ия булачак двигательләр заводы проектын да башкарды. Җитештерүнең тулысынча һәм туктаусыз эшләп торуын тәэмин итү өчен энергия бирүнең тулы комплексы (җылылык үзәге, ягулык саклау урыны, суыту станциясе, трансформатор подстанцияләре, насос һәм компрессор станцияләре, әйләнешле су белән тәэмин итү градирнялары), мәйдан эчендәге инженерлык челтәрләре проектлаштырылды. Ашханәсе һәм медпункты булган, эчкә кертеп һәм өстәп корылган административ-көнкүреш бина-

Реклама
Фотолар «Казан Гипронииавиапромы» матбугат хезмәтеннән алынды.

сын реконструкцияләү, әйләнәтирә территорияне, керү юлларын, әзер продукция урынын яхшырту эшләре тәгәлләнде, әзер автомобильләрне сынау өчен өстә ябулы трек булдырылды.

Проект буенча төзелеш һәм реконструкция эшләре кыска срокларда тормышка ашырылды. 2015 елда иң катлаулы объектны – Россиянең иң яңа тарихында беренче булган Ford җиңел автомобильләре өчен чит ил двигательләрен җитештерү заводын төзү тәгәлләнде. Аның тантаналы ачылышы 2015 елның 3 сентябрендә – Калуга өлкәсенең шушыңа тиң «Volkswagen» җитештерүенә старт бирелүдән бер көн алданрак булды. Гомумән алганда, «Форд Соллерс Алабуга» ҖЧҖ предприятиеләрендә 2,2 меңнән артыграк кеше эш урыннары белән тәэмин ителде.

Татарстандагы инвестиция потенциалының визит карточкасы буларак, «Алабуга» МИЗ әйләнешләрен арттыра бара. Әле икътисадый зонаның үзен проектлау стадиясендә үк МИЗның ышанычлы партнёрына әверелгән «Казан Гипронииавиапромы» аның резидентлары белән хезмәттәшлеген дәвам иттерә. Шул исәптән – автомобиль төзелеше өчен компонентлар җитештерүче компанияләр белән дә.

Яңа инновацион җитештерүләр булдыру белән бәйле проектлар институтны аеруча кызыксындыра. Мәсәлән, «Казан Гипронииавиапромы» катнашында 2014 елда табаклы (Sheet Molding Compound – SMC) һәм паста хәлендәге (Bulk Molding Compound – BMC) термореактив полимер материаллар җитештерү предприятиеләрен төзү проекты эшләнде һәм тормышка ашырылды. SMC-чимал алга таба югары дәрәҗәле механик ныклыкка ия булган түбән профильле эшләнмәләрне – автокузов элементларын, транспорт утыргычларын һ.б – җитештерүдә, ә BMC – катлаулы конфигурацияле уртача габаритлы эшләнмәләрне, аерым алганда, автомобиль һәм трактор моторлары детальләрен җитештерүдә кулланыла. Проектның заказчысы булып «Татнефть – Пресскомпозит» ҖЧҖ тора.

Күптән түгел «Казан Гипронииавиапромы» «КАМАЗ» ГАҖ һәм Daimler автоконцернының уртак проектын тормышка ашыру кысаларында бер заказ башкарды. Институт проект һәм эш документациясен эшләде, ә Кама автогиганты үзендә, Яр Чаллыда «КАМАЗ» автомобильләренең SFTP кабиналары каркаслары җитештерү өчен эретеп ябыштыру, буяу, логистика цехларын төзеде. Кабина каркасларын серияле җитештерүгә стартны 2019 елның язында бирү күздә тотыла. Җитештерү күләме елына 55 мең кабина каркасын тәшкил итәргә тиеш. Җиде төрле модификация чыгару планлаштырыла. Каркаслар «КАМАЗ»ның төп җыю конвейерына, һәм шулай ук Mercedes-Benz йөк машиналарын җыю җитештерүенә ташырылачак.

«Казан Гипронииавиапромы» тормышка ашыра торган тагын бер мөһим проект – казанлылар бик күптәннән көткән бопра буенча йөриячәк электричка. Ул «РТЮ» ААҖ белән Татарстан Республикасы арасындагы килешү нәтиҗәсендә эшләнәчәк. Бу килешүне 2018 елның августында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән «РТЮ» ААҖ генераль директоры Олег Белозеров имза белән ныгытты.

Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча махсус эшче төркем булдырылды. Аның составына профильле идарә тармагы белән институтларның, шул исәптән «Казан Гипронииавиапромы» вәкилләре керде. Бурычлары – Казанда божра буенча йөри торган тимерьюл төзелешен координацияләү. Хәзер этапның беренче этабы гамәлгә ашырыла.

12 км га якын озынлыктагы беренче участок Яңа Аракчино белән Төньяк вокзалын (Казан-2 станциясе) тоташтырачак. Төньяк вокзалы инде хәзер үк эре күчеп утыру төенен тәшкил итә. Төзелеш барышында Яңа Аракчино, «787 нче километр», «Левченко» станцияләре яңадан төзелеп корылачак. Моннан тыш, хәзергесенә параллель булган мөстәкыйль тимерьюл да салыначак. Проект-смета документларын һәм экспертизаларын 2019 елда тәгәлләргә ниятлиләр. Төзелеш үзе 2020–2021 елларга тәгаенләнгән.

* Шит Молдинг Кампаунд – ЭсЭмСи.
** Балк Молдинг Кампаунд – БиЭмСи.



Фото: Ната Смирнова

ТЕРЕК СУ БЕЛӘН ТУЛЫ КАСӘЛӘР

Елгалар калын боз белән озак вакытлар капланып торган илдә кешеләрнең күпләп йөзү белән шөгыльләнүе турында сөйләнү – беренче карашка перспективасыз эш кебек. Әмма бу Татарстанга кагылмый – биредә инде йөз егермедән артык йөзү бассейны эшли! Россиядәге теләсә кайсы башка төбәктәгедән күбрәк!

Казанның Дербышки микрорайонындагы «Ракета» йөзү бассейны.

Катерина Котова
әзерләде

Республикада йөзү спорт комплексларын төзү темплары таң калдыра. Соңгы биш айда гына да Татарстанда сигез ябык бассейн ачылган – Апас, Югары Ослан, Питрәч, Түбән Кама, Мамадыш, Тукай, Теләче районнарында һәм Әлмәттә. Әлеге типовой комплексларда өлкәннәр дә, балалар да спорт белән шөгыльләнә ала. Һәр объект тәүлегенә биш йөздән артыграк кешегә хезмәт күрсәтергә сәләтле. Алар шулай ук барысы да авыру нәтиҗәсендә сәламәтлеге чикләнгән кешеләр өчен дә җайланган – һәм монда сүз пандуслар турында гына түгел, бәлки йөзү өчен каралган махсус җиһазлар турында да бара.

СӘЛАМӘТ МИРАС

ТР Спорт министрлыгында хәбәр итүләренчә, бүген республикада 120 дән артык ябык һәм ачык бассейн эшли (шуларның уникесе Олимпия үлчәмендә, ягъни аларның озынлыгы 50 метрны тәшкил итә). Объектларның кайберләре – бездә 2013 елдан бирле үткәрелгән зур ярышлардан калган мирас. Әйтик, җиде бассейн Бөтендөнья Җәйге Универсиадасына тәгаенләп төзелгән иде, FINA су спорт төрләре чемпионатында катнашучылар ярышкан өч вакытлыча корылма соңрак республикага даими файдалануга тапшырылды.

Бәхеткә, бүген Татарстанда бассейннар төзү дәвам итә. Сигез яңа объект – йөзү бассейннары һәм универсаль спорт заллары төзү буенча 2018 елда башланган Президент программасын гамәлгә кертү нәтиҗәсе. Ә менә якын киләчәктә ишекләрен ачачак объект – Чаллыдагы гаиләсәламәтләндерү комплексы дәүләт-хосусый партнерлык кысаларында төзелә. Чөнки Татарстанда бассейннар тө-

Фотолар ТР Президенты һәм ТР Спорт министрлыгы сайтларыннан алынды

Мамадыш шәһәрендәге «Лагуна» йөзү бассейны.

Әлмәт шәһәрендәге «Мирас» йөзү бассейны.

зелешендә бөтен чаралардан да файдаланып калу яхшы, дип саныйлар.

РӘХӘТЛӘНЕП ЙӨЗСЕННӘР

Әлеге тырышлыкның сизелерлек нәтиҗә бирүе дә сөендерә. Бүген йөзү – республикада халык арасында иң популяр спорт төрләренең берсе. Татарстан халкының 40 процентган артыграгы спортның нинди дә булса төре белән шөгыльләнә. Ә бу бит аз да түгел, күп тә түгел – миллион ярым кеше! Татарстан үсмерләре аеруча куандыра: 2013 елда 5,4 мең бала йөзү белән шөгыльләнсә, быел бассейнга инде 8 меңнән артык нәни спортчы йөри.

– Без милләт сәламәтлеге һәм сәламәт яшәү рәвеше турында сөйлибез икән, төбәктә бассейннар булу – әлеге максатка ирешүдә төп пунктларның берсе, – дип саный **ТР спорт министры Владимир Леонов**. – Шунлыктан безнең киләчәктәге бурычыбыз – файдалануга тапшырылган бассейннарның нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү һәм әлегә су спорты корылмаларына мохтаҗ булган районнарда бассейннар төзү программасын тормышка ашыру.

Фото: Ната Смирнова

ХАСТАХАНӘ ДИВАРЛАРЫ АРТЫНДА...

Бирედә нинди генә вакыйга турында сөйләсәләр дә – драма. Кем өчендер – детектив элементлары белән, кем өчендер – фантастик яисә хәтта хоррорга тартым. Шулай да, бәхеткә, барлык вакыйгаларның да диярлек ахыры яхшы тәмамлана, чөнки төп геройлар арасында – кеше гомере сагында торучылар. Үзләре өчен медицинаны кәсеп генә түгел, ә сәнгать төре дә итеп сайлаган табиблар.

– Уйлап карагыз: без тәүлегенә дүрт йөздән артык пациентны кабул итәбез! – дип сөйли безгә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы Республика клиник хастаханәсенең баш табибы Рафаэль Шәвәлиев. – Медицина ярдәменең барлык төрләрен күрсәтергә һәрчак әзер тору һәм моңа сәләтле булу – безнең эш концепциябез.

ЙӨРӘК КАТАСТРОФАСЫ

Яңа ел могҗизасы – Тәлгать Мусиновичны коткаруны шулай дип атарга да буладыр. Травматолог-ортопед буларак, ул үзе гомере буена кешеләрне дәвалаган. Бу очракта исә ярдәм үзенә таләп ителгән. Йөрәккә урнаштырылган стент конструкциядән ычкына да туп-туры баш миендәге кан тамырларының берсенә эләгә – аңа операция ясыйлар. Алга таба Тәлгать Мусиновичны үлемгә китерә торган инсульт көтә...

Бу хәл Россия төбәкләренең берсендә була. Клиника табиблары берничә көн бөтен ил күләмендә үз коллегаларыннан ярдәм сорый, федераль үзәкләргә мөрәҗәгать итә, ләкин берәү дә стентны алу буенча гаять катлаулы операциягә алынырга җөрьәт итми – әлеге хәбәр Казанга килеп ирешкәнчегә кадәр.

– Статистик яктан карагандa, уңышка ирешү мөмкинлеге аз иде, – ди РКХнең кардиология бүлеге җитәкчесе Альберт Гыйльманов. – Ләкин без тәвәккәлләргә булдык – өстебезгә җаваплылык алудан курыкмадык. Кешене ярдәмсез калдырып булмый бит инде! Аны машинадан туп-туры диярлек операция бүлмәсенә алып керел киттек. Бот артериясендә кечкенә генә тишек ясадык, баш мие сосудларына кадәр җитеп, чит предметны «тотып» өлгердек.

Тәлгать Мусинович инде хастаханәдән чыгып, үз шәһәренә кайтып киткән. Әмма аңа кадәр Казанда үзен коткаручыларга иң җылы сүзләр табарга һәм Яңа ел теләкләре теләргә өлгергән.

– Мин ни өчен башкаларның аңа ярдәм итәргә көч тапмаулары турында әйтә алмыйм, – ди Альберт Әнәсович. – Ләкин үзебезнең моңа нишләп алынуыбызны аңлата алам. Ихтимал, әле биш ел элек кенә мондый катлаулылыктагы операцияләр турында уйлый да алмаганбыздыр, ләкин бүген бу безнең хәлебездән килә. Үз алдыбызга амбициоз бурычлар куярга күнектек, һәм аларның берсе – иң алдынгы, беренче булу.

Бүген хастаханәдә «йөрәк» проблемалары булган авырулар кардиологик хезмәтләрнең теләсә кайсы төрен ала алалар – йөрәккә кагылышлы авыруларны кисәтүдән алып авыруның иң кискен чорында таләп ителгән квалификацияле ярдәмгә кадәр. Алар арасында уникаль ярдәм төрләре дә бар. Әйтик, сул йөрәгалды колакчыгын имплантацияләү. Россия күләмендә ясалган мондый төр операцияләрнең саны биш йөздән дә артмый. РКХндә инде дистәгә якын операция эшләнгән, тәҗрибә туплау һаман дәвам итә. Эш шунда: сул йөрәгалды колакчыгы – төп кан куерыгы – тромб чыганакларының берсе. Гади генә әйткәндә, ул – «мотор», өзек-өзек тибеп, минутына 300 тибешкә җиткән тизлектә канны миксер кебек куерткaнда йөрәк янында тромбларны туплый торган «чолан». РКХ табиблары тромбларны махсус технология ярдәмендә әлеге «чоланда бикләп куярга» өйрәнгәннәр.

Беренче мәртәбә клиникада мондый манипуляция 2017 елда уздырыла. Ул вакытта операция өстәлендә 82 яшьлек абзый ята. Ул озак еллар канның куелыгын киметә һәм тромблар хасил булуга каршы торучы препаратлар эчәргә мәҗбүр була. Ләкин аның организмы даруларга үзенчәлекле җавап кайтара – төзәлми торган җәрәхәтләр барлыкка килә, эчке органнарга кан савулар ешая.

– Пациент безгә элеккәндә йончыган һәм ябыккан иде, – дип искә ала Альберт Гыйльманов. – Ә бүген аңа инде 85 яшь! Сәламәтлек күрсәткечләре – идеаль, йөрәк тә шәп эшли.

Үзе җаваплы бүлек буенча экскурсия ясау урынына Альберт Гыйльманов безне туп-туры ординаторлар бүлмәсе – бүлек белгечләре янына алып керә.

– Беләсезме, безнең эштә иң кыйммәтлесе җиһазлар да түгел, бәлки табибларның белеме һәм сизгерлеге, – ди ул. – Уңышның 90 проценты – ул әңгәмә! – дип раслый табиб. – Кайвакыт кешенең нәрсәгә зарланганын аңлар өчен сәгать ярымга кадәр вакыт сарыф итәбез. Күкрәк читлеген күз алдына китерегез – анда йөрәктән башка тагын күпме нәрсә бар! Параллель рәвештә кешенең мимикасына, ишарәләренә игътибар итәбез, маңгаена тир бәреп чыгу-чыкмавын истә тотабыз,

Автор:
Катерина Котова

Фото: Александр Ефремов

PRESSA



«Безнең эштә иң кыйммәтлесе җиһазлар да түгел, бәлки, табибларның белеме һәм сизгерлеге», – дип сөйләде безгә Альберт Гыйльманов, кардиология бүлеге белән таныштырып йөргәндә.

ничек сулаганына колак салабыз… Безгә әлеге «пәрдәләр»не кичеп, тойгылар һәм хәтта сизенүләр чигендәге өлкәгә кадәр үтеп керергә кирәк!

Яңа ел бәйрәмнәре кардиология бүлегендә – кызу чак. Төп пациентлар – 28–45 яшьләрдәге ир-атлар. Быел аларның саны бигрәк тә күп булды. Һәм еш кына моның сәбәбе бәйрәм өстәле түгел, бәлки вакытыңны гаилә белән бергә үткәрү, активрак ял итү теләге! Менә, мисалга, Иван Григорьевич, аңа 36 яшь, балалар белән шугалакка барырга уйлаган – ярты сәгатьтән аны «Ашыгыч ярдәм» РКХнә китерә – күкрәгә ертылырдай булып авырта. Ә Рафаэль Илдарович 58 яшендә оныклары белән урманга чаңгы шуарга чыккан – ә берничә сәгатьтән ул инде операция өстәлендә ята. Яисә менә Валерий – 28 яшьлек егет – ниһаять спортзалга йөрергә уйлый, әмма беренче тапкыр барганнан соң ук, үзен начар хис итә башлый. Табибларның диагнозы шул ук – инфаркт…

Авыруның ничек пәйда булуын белгәндә, мондый бәлаләргә тарымаска да була, дип саный Альберт Гыйльманов. Шуңа күрә кардиология бүлеге җитәкчесе күп вакытын

ИНФАРКТНЫ НИЧЕК БУЛДЫРМАСКА

1. Йөрәкнең иң явыз дошманы – тәмәке тарту, дип саный кардиолог Альберт Гыйльманов. Никотин кан тамырларын үтерә. Аңардан безнең «моторда» субстратлар барлыкка килә. Йөрәк тибеше ешлыгын арттырып, әз генә йөкләнеш бирү дә инфарктка китерә. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, никотиннан баш тартырга кирәк.

2. Йөрәкнең икенче дошманы – холестерин. Шул ук вакытта аның 10 проценты гына безгә ризык аша керә. Калганын бавыр эшләп чыгара, холестерин тромбларның чыганагы булган атеросклероз яссы төерен барлыкка китерә. Һәм монда инде статиннар эчмичә булмый, дип аңлата Гыйльманов, чөнки теләсә кайсы гамәл – зарядка яисә иртәнге кофе (кан басымын арттыручы һәр нәрсә) – инфарктка яисә инсультка китерергә мөмкин.

3. Йөрәкнең өченче дошманы – стресс. Чөнки йөрәк катырак каккан саен үзе әзрәк кан ала.

Бары тик тискәре факторлардан котылган һәм табибтан хуплау алганнан соң гына, көндәлек режимыгызга физик йөкләнешләр кертә аласыз, дип аңлата табиб. Шуңа күрә «тәмәкене ташла, чаңгыга бас» дигән җыр сүзләре бик дөрес яңгырый. Нәкъ менә шул тәртиптә, киресенчә түгел.

профилактикага, авыруны алдан кисәтүгә сарыф итә. Район хастаханәләренә һәм дәваханәләргә чыга, табибларны 12 минут эчендә пациентка ни рәвешле бөтен мәгълүматны биреп бетерергә өйрәтә. Ул хәтта «Татарстан» журналистлары белән очрашуны да әлеге максатларда кулланды, яңадан инфарктка китерүче адымнарны тәфсилләп аңлатты.

ГАДӘТИ ФАНТАСТИКА

Бәла киләсен һичнәрсә белгертми. Илдар* минераль су шешәсен алып, бер йотым гына ясый. Әмма, сусавы басылып, яшәү көче алу урынына, бөтен гәүдәсен гаҗәеп эсселек биләп алуын тоя.

Шешәгә уксус кислотасы салган хезмәттәшенең җавапсызлыгы Алабугада яшәүче 47 яшьлек ирне озак һәм газаплы үлемгә дучар итә алыр иде. Бакыйлыкка кочүдән аны РКХнең торакаль хирургия бүлеге табиблары коткарып кала. Иратның үңәченнән бары тик нечкә җепсел генә кала – ашап та, эчеп тә булмый. Яшәү белән берничек тә ярашмаган тормыш сыйфаты! Туклыклы матдәләрне ир турыдан-туры ашказанына килә торган махсус трубкалар аша ала. Үңәчне яңадан торгызу буенча операция бәхетсезлеккә тарыган ир-ат өчен яңа ел могҗизасына тиң була. Табиблар пациентка яңа үңәчне аның юан эчәгеннән ясыйлар.

«Операцияне ясау гына җитми, алдагысын да уйларга кирәк, алай булмаганда бу кәсепчелек дип атала, нәрсә күрәм – шуны кисәм кебек була, – дип аңлата бүлек җитәкчесе Валерий Матвеев.

– Бу бик катлаулы операция булды, чөнки башта безгә үз эченә сосудларны да алган бөтен эчке архитектониканы исәпкә алып эшләргә кирәк, аннан соң эчәклекнең бер өлешен урнашкан урыныннан шактый еракка тартырга туры килде, – дип искә төшерә РКХнең торакаль хирургия бүлеге җитәкчесе Валерий Матвеев.

Операция уңышлы уза – пациент инде туган шәһәренә кайтып киткән. Хастаханә өчен исә әлеге очрак мөһим үсеш этабы була. Эш шунда: әле кайчан гына РКХндә үңәч хирургиясе булмый, ә бүген, карагыз, нинди катлаулы операцияләр башкарыла! Атаклы белгеч – профессор Михаил Бурмистровның бирегә килүе да әлеге юнәлешне эшләтеп җибәрүгә зур этәргеч бирә.

Ә күптән түгел генә торакаль хирургия бүлеге эшендә бөтенләй уникаль очрак туа – клиникага бик авыр хәлдәге хатынны китерәләр – үңәче ертылган. Бәлага ул район хастаханәсендә эндоскопик тикшерену узганда тарый. Инфекция эләгү нәтиҗәсендә үлекле ялкынсыну башлана – һәм бу үңәч рагы фонында. Ләкин хирурглар әлеге бурычны бернинди кисү-яруларсыз башкарып чыга: әле күптән түгел генә тәҗрибәгә кергән яңа технология – эчке яктылыклы вакуум-терапия ярдәмендә. Үлекле ялкынсынуны шулай ук тишемнәр тишеп чистарталар. Ханымны коткарып та калалар, аннан соң дәвалыйлар да. Әле алай гына да түгел.

– Беләсезме, операцияне ясау гына җитми, алдагысын да уйларга кирәк, алай булмаганда бу кәсепчелек дип атала, нәрсә күрәм – шуны кисәм кебек була, – дип аңлата Валерий Матвеев.

Әгәр пациентка операцияне гадәттәгечә ярып ясасалар, ялкынсынган үлекле үңәчне «тегәргә» тырышсалар, табиблар, мөгаен, авыруны коткарып кала алмаслар иде. Эндоскопик ысул табибларга ханымның гомерен саклап калырга мөмкинлек бирә. Ә инде гадәттәгечә ашказанына трубка беркетсәләр, алга таба рак белән бозылган үңәчне торгызу өчен ашказаныннан кирәкле кисәкне ала алмаслар иде. Ләкин болар барысы да инде артта калган. Бүгенге көндә ханым гадәти тормыш рәвеше алып бара, үзен коткаручылар – РКХнең торакаль хирургия бүлеге белгечләрен бәйрәм саен котларга онытмый.

Сүз уңаеннан, РКХнең торакаль хирургия бүлеге менә инде ничә еллар дәвамында илнең әйдәп баручы торакаль үзәкләре исәбендә. Биредә иң яңа технологияләр гамәлгә кертелә. Хастаханә территориясендә сигез ел дәвамында Европаның әйдәп баручы торакаль хирурглары съездлары үткәрелү дә очраклы хәл түгел. Әлеге чара кысаларында белем бирү семинарлары, лекцияләр һәм мастер-класслар үткәрелә. Танылган осталар тарафыннан иң катлаулы операцияләр турыдан-туры залга трансляцияләнә, коллегалар уникаль методикаларны һәм ноу-хауларны күрү мөмкинлеге белән бергә, үзләрен кызыксындырган сорауларны да бирә алалар.

РКХндә үткәрелгән соңгы уникаль операцияләрнең берсе – берьюлы

РКХ баш табибының медчасть буенча урынбасары Раиса Гуслякова, медицина – ул, иң беренче чиратта, табиб белән пациентның ышанычка корылган бәйләнеше, дип саный.

ике үпкәдән дә эхинококклы сулы шешләрне (кисталарны) кисеп ташлау! Әлеге авыру клиникага күкрәк читлегендә авыртуга зарланып мөрәҗәгать итә. Тикшергән вакытта табиблар хатынның үпкәсендә берничә шеш табалар, гади генә шешләр түгел, гельминтлар белән зарарланганнар! Алар белән яшәү мөмкин түгел – паразитлар үрчи, шуңа күрә шешләр шартларга һәм кеше буылырга мөмкин.

– Мондый операцияне ясау өчен, аерым бер осталыкка ия булудан тыш, шәп команда да булырга тиеш, – дип сөйли Валерий Матвеев. – Бер мәртәбә наркоз биреп, берьюлы ике үпкәгә дә операция ясау бик зур тәвәккәллек сорый. Күз алдына гына китерегез, анестезиологка үпкәләрне чиратлап организмнан аерып торырга, ә хирургларга, урыннарын алыштырып, берсеннән икенчесенә күчәргә кирәк…

Әлеге операциянең бер үзенчәлеге – ул эндоскопик ысул, ягъни ярмыйча белән ясала. Һәм бу Россиядә бөтен торакаль хирургия үсешендә иң мөһим инновацион моментларның берсе санала. РКХндә күкрәк читлегенә ясала торган барлык операцияләрнең (үпкәдә яман шеш булсынмы ул, үңәчне алумы) инде 75 процентка якыны кечкенә генә тишемнәр аша уздырыла.

– Мондый хезмәт көненнән соң кичегезне ни рәвешле торгызасыз? – хирургка әлеге соравымны бирми кала алмыйм.

– Төннәрен хоккей уйныйм! – дип гаҗәпләндерә мине Матвеев. – Берьюлы берничә командада торам. Әзрәк йоклап, күбрәк кырда йөгерергә, суларга тырышам. Үземнән бөтен авырлыкны алып ташлыйм – һәм шунда ук рәхәт булып китә. Ә иртәгә – янәдән операция булмәсенә!

МЕДИЦИНА ДЕТЕКТИВЫ

Мин шәхсән үзем шикләнмим: әгәр Граф Дракула РКХ хирурглары кулына эләккән булса, аңа да үз диагнозы куелыр иде. Порфирия. Хәер, Әлмәт шәһәреннән килгән Ирина Павловага* әлеге шаярту бик кызык тоелмас иде.

Аның фаҗигасе моннан берничә ел элек башлана. Эре компанияләрнең берсендә уңышлы гына эшләүче финансист кыз яңа гына эссе яклардан сәяхәттән кайта. Һәм бераздан хастаханәгә эләгә. Беренче зары – эче авырта. Район табиблары сәбәбен эзләгән арада кызда галлюцинацияләр башлана, эчке органнарының хәле зур тизлек белән үзгәреш кичерә башлый…

– Порфирияне еш кына вампирлар авыруы дип атыйлар, – дип сөйли РКХнең терапия клиникасы җитәкчесе **Диана Абдулганиева.** – Элеккеге заманнарда аның белән авыручылар үгез каны эчкәннәр – мондый теләк гемоглобинның кинәт кенә төшүе нәтиҗәсендә туа. Ә кояш нурлары, пешереп, мондый кешеләрнең тәннәрендә озак төзәлми торган яралар пәйда булуга китерә, шуңа күрә алар интуитив рәвештә урамга төннәрен генә чыгарга тырышканнар. Бәхеткә, Иринада авыруның әлеге төрен тапмадык. Ләкин шулай да иң сирәк формаларның берсе эләккән иде.



РКХндә терапиянең барлык юнәлешләре дә эшли. Алай гына да түгел, биредә хирурглар, неврологлар, акушер-гинекологлар белән нәтиҗәле кооперация урнаштырылган.

Бирелә уртача алганда тәүлегенә дүрт йөздән артык пациентны кабул итәләр. «Медицина ярдәменең барлык төрләрен күрсәтергә һәрчак әзер тору һәм моңа сәләтле булу – безнең эш концепциябез», – дип сөйләде безгә клиниканың баш табибы Рафаэль Шәвәлиев.

Кызга диагнозны өч көн эчендә куялар. Һәм бу аның гомерен саклап кала, чөнки мондый авыруларның 90 проценттан артыгы үлем белән тәмамлана. Терапевтлар фактларны чагыштыралар, симптомнарны күздән кичерәләр, бер сүз белән әйткәндә, бу медицина детективын Шерлок Холмс методы белән чишәргә туры килә, чөнки әлегә кадәр мондый проблема белән очрашканнары булмый. Мәскәүдәге Гематология институтындагы коллегалары да куелган диагнозны, һәм шулай ук дәвалау курсының дөреслеген раслый. Эш шунда ки, порфириянең бер формасы өчен туры килгән препаратлар аның икенче төре белән авыручыны үтерергә мөмкин.

Бүген Ирина тулы канлы тормышка кайткан – эшен дәвам итә, чаңгыда йөри, әмма үз авыруы турында онытмый һәм табибларның барлык киңәшләрен тота. Мөгаен, авыруның йоклап яткан генын кышын көньякка сәяхәт кылу уятып җибәргәндер – РКХ табиблары шулай дип фикер йөртә. Һәр кеше – аерым дөнья, аңа үтеп керергә һәм аны аңларга кирәк, дип кисәтә алар.

– Табиб белән пациент арасында ышанычка корылган бәйләнеш урнашырга тиеш – моңардан башка чын медицина була алмый, хәтта ул югары технологияләргә ия булса да, – дип, үз фикере белән уртаклаша РКХ баш табибының медчасть буенча урынбасары Раиса Гуслякова. – Кызганычка, күпләр медицинага кәсепчелек итеп карарга күнеккән, ә бит асылда ул – сәнгать! Ә терапия, гомумән, фикерләү процессының иң биек ноктасы. РКХндә терапиянең барлык юнәлешләре дә эшли. Бу безнең өстенлегебез! Алай гына да түгел, без хирурглар, неврологлар, акушер-гинекологлар белән нәтиҗәле кооперациядә хезмәт куябыз...

– Мондый комплекслы якын килү Татарстанда гына түгел, Мәскәүнең һәм Санкт-Петербургның күп кенә эре хастаханәләрендә дә юк, – дип нәтиҗә ясый очрашу ахырында Рафаэль Шәвәлиев. – Менә үпкә авырулары белән пульмонологлар шөгыльләнергә тиеш кебек. Ләкин үпкә шешүенә йөрәк эшчәнлегенең җиткелекле түгеллеге (сердечная недостаточность) дә сәбәп булырга мөмкин, монда инде кардиолог ярдәме таләп ителә. Һәм мондый нюанслар шактый! Менә шуңа да бер белгеч кенә бөтенесен дә хәл итә алмый, ул зур команда эшен тулыландыра гына. РКХндә медицина ярдәменең югары сыйфатына югары технологияләр аша гына түгел, бәлки, беренче чиратта, мультидисциплинарлык хисабына да ирешелә. Бер диагностик эзләнүләр процессында төрле юнәлештәге белгечләрнең катнашуы – безне башкалардан аерып торучы мөһим күрсәткеч. Без, һичшиксез, дөрес диагнозны куячакбыз! Әле бер генә тапкыр да куймый калганыбыз юк! ■

«Элек йөрәккә тулы блокаданы пульс буенча куя идек, ә хәзер безнең кулда гаять зур инструментарий! Ләкин шулай да даими эзләнүдә булу һәм шикләнүдә тору – табибка хас яхшы гадәт», – ди РКХнең иң өлкән терапевты Сәяр Әхмәров.

Авыру ул ниндидер зарлар һәм симптомнар җыелмасы түгел, дип аңлаталар РКХ табиблары. Һәр кеше – аерым дөнья, аңа үтеп керергә һәм аны аңларга кирәк. Шул очракта гына нәтиҗә күтәргә була.

* Пациентларның исемнәре этик күзлектән чыгып үзгәртеп бирелә.

Остадан СОРАГЫЗ!

Үзләрен WorldSkills та күрсәтү теләге Татарстан колледжлары һәм техникумнарында укучылар арасында Татарстан башкаласы 2019 елда дөнья чемпионатын үткәрү хокукын яулаганчы ук барлыкка килгән иде. Җыелма командага лаеклы әгъзалар әзерләү һәм партнерларга булышлык итүгә юнәлтелгән эшчәнлек нәтиҗәсендә, Казан радиомеханика колледжын дөнья стандартларына якынайтып, югары технологияле белем бирү базасы итеп җиһазландыру мөмкин булды.

ҺӨНӘР ИЯЛӘРЕН ӘЗЕРЛӘҮ ПОЛИГОНЫ

Нәкъ менә шундый җиһазлар ярдәмендә Казан радиомеханика колледжы һөнәр ияләрен әзерләп чыгара.

– Без WorldSkills хәрәкәтендә 2014 елдан бирле. Колледж болай да яхшы җиһазландырылган, шулай да матди-техник базаны яңартуны дәвам иттерәбез һәм радиотехника белән электроника юнәлешендә заманча технологик җиһазлар сатып алабыз, – ди Казан радиомеханика колледжы директоры Камил Мөхәммәтов. – Талантлы яшьләрне беренче курстан ук җәлеп итә башлыйбыз. Башта техник иҗат түгәрәкләренә йөриләр, икенче курста аларны WorldSkills экспертлары сайлый, алга таба тренировкаларга иң талантлылары гына кала. «Радиоаппарат төзелеше» белгечлегенә укучы өченче курс студенты Азат Ситдыйков кебек, мәсәлән. Ул быел май аенда узачак WorldSkills милли чемпионатында катнашачак. Бүген Азат «Татарстан» журналы сорауларына җавап бирә.

1. Ни өчен бу һөнәрне сайладыгыз?

– Мин балачактан ук электр җиһазларында, уенчык һәм башка шундый сүтеп җыя торган нәрсәләрдә казынырга ярата идем. Әлбәттә, сүтүгә караганда, җыю кыенрак бирелә, ләкин аңа карап туктап калганым булмады. Радиодулкыннар ярдәмендә идарә ителә торган вертолет яки машина ничек эшли, аларны нәрсә хәрәкәткә китерә – шуны белү кызык иде. Үзем генә җыя алмасам, һәрвакытта да әти ярдәмгә килә иде. Бишенче сыйныфларда укыганда, үскәч кем булачагымны аңлый башладым инде. Техника һәм аңа кагылышлы бөтен нәрсә дә кызыксындыра иде. Шуңа да колледждан кала башка вариантлар турында уйламадым, чөнки монда практика күп.

2. WorldSkillsның узган ярышларында нинди кыенлыклар аша үттең?

– Биремнәрне башкару өчен вакыт бирелә, бирем буенча барысын да пөхтә итеп эшләп чыгарга, бернәрсәне дә онытып калдырмаска кирәк. Модульләрнең берсендә үз кесә метеостанциясен программалаштыру таләп ителә иде – бу биремне башкарганда, әлегә күпмедер кыенлыклар алдында калам. Программалаштыру башкаларына караганда катлаулырак бирелә. Әмма шундый киеренке вакытларда да мин дулкынланмыйм, чөнки моңа кадәр ярышларда еш катнашканым булды. Дөрес, волейбол буенча, әмма принцибы охшаш – бөтен игътибар биремдә булырга тиеш.

3. Эшче һөнәрләр чемпионатында катнашу сезгә нәрсә бирә?

– Тренировкалар полигонында безгә үз техникабызны ремонтларга рөхсәт итәләр. Күптән түгел мин үземнең ноутбугымны төзәттем. Аның клавиатурасы тулысынча ябышып кала һәм энергия белән тәэмин ителеше бозылган иде. Дусларыма телефоннарының экраннарын алыштырып бирәм, башка вак техниканы төзәтәм. Сервис үзәкләрендә мондый хезмәтләр арзан тормый, мин исә боларны үзем эшли алам. Менә шундый кирәклеге өчен сайлаган һөнәрем ошый үземә. Электроника өлкәсендәге белемнәрдән тыш, чемпионат мине ил буйлап йөртә һәм чит илләргә сәяхәт итү мөмкинлеге белән дә гаять кызыксындыра. Мәсәлән, 2020 елда милли этап – Хабаровскида, ә 2021 елда дөньяныкы Шанхайда узачак. Кызганыч, Англиядә ярышлар булмаячак, ә минем шунда барасым килә. Киләчәктә анда барырлык кына хезмәт хакы алып эшләрмен әле дип ышанам.

4. Алда торган ярышларга ничек әзерләнәсез? WorldSkillsның халыкара стандартлары безнең белем бирү стандартларыннан аерыламы?

– WorldSkillsка әзерлек өчен конкурс узганда, махсус модульләр буенча өстәмә дәресләр турында сүз баруын шунда ук аңламаган идем. Соңрак ул мине тулаем үзенә йотты, хәзер тренировкалар атнасына 30 сәгатькә кадәр вакытны ала. Хәзерге вакытта ярышлар укуга караганда мөһимрәк, әмма асылда ул да безнең дәресләрнең киңәйтелгән программасы. Модульләрнең күбесен без уку программасы буенча үткән булыр идек, ләкин бераз соңрак кына.

5. Сез киләчәккә ничек карыйсыз? Озакламый эшче һөнәрләргә алмашка роботлар килмәсме?

– Хәзер үк инде җыю һәм монтаж эшләре роботлаштырылган, ләкин автоматика схема техникасын программалаштыра алмаячак. Программалаштыруда кеше техника белән аралаша, теләгәнен аның телендә язып бирә. Димәк ки, роботлар – безнең ярдәмчеләр.

6. Һөнәр үзләштерү өчен нинди күнекмәләр һәм кешелек сыйфатлары булырга тиеш?

– Шәхси мәнфәгатьләрсез генә беркайда да булмый. Радиотехникада да шулай ук игътибарлылык, чыдамлык һәм теге яки бу әсбапның ничек эшләве турында җитди белем кирәк.

7. Тагын ун елдан соң сез үзегезне кем итеп күрәсез?

– Миннән әйбәт проектлаучы-инженер чыгар дип ышанам. Ихтимал, бу минем балачагымдагы иң яраткан уенчыгым – радиодулкыннар ярдәмендә идарә ителә торган вертолет белән дә бәйледер. Чөнки минем киләчәктә радиолокацияле көрәш эшләнмәләрендә катнашасым килә – ул вертолет, самолет һәм башка хәрби техникага комачаулый торган факторлардан саклау, шулай ук дошманның техникасын магнит импульслары ярдәмендә эштән чыгару дигән сүз. Мондый эшләнмәләр һава һөҗүме оборонасыннан да саклый.

Алёна Кутыркина фотосы

нное
ссиональное
чреждение
кий
ический
дж
worldskills
Russia

WORLDSKILLS ЧЕМПИОНАТЫ МӘЙДАНЫН ҖИҺАЗЛАНДЫРУ ӨЧЕН ҖАВАП БИРӘБЕЗ

Камил Мөхәммәтов, Казан радиомеханика колледжы директоры:

– Колледжның тренировкалар базасы ресурслары башка колледжларда, вузларда укучылар, мәктәп укучылары һәм яшь белгечләр өчен дә ачык. Мәсәлән, Шамил Вәлиуллин КАИда радиоэлектроника һәм телекоммуникацияләр институтының беренче курсында укый һәм милли җыелма команда составында 45 нче дөнья чемпионатына тренировкаларда катнаша. Иң җитди әзерлекне ул колледжның тренировкалар полигонында безнең экспертлар контроле астында узды.

Шулай ук без «Киләчәккә билет» дигән яшьли һөнәр сайлау буенча проектта катнашу өчен «Электроника» компетенциясендә һөнәри әзерлекне сынау өчен мәйдан» сыйфатында гариза бирдек. Әлеге проект нәкъ менә WorldSkills компетенцияләренә нигезләнә. Безгә килгән мәктәп укучысы үзен электрончы сыйфатында сынап карый ала, әгәр кызыксынып китсә, юниорлар командасында катнашырга тәкъдим итә, аны тренировкалар мәйданына терки алабыз.

Мондый һөнәр сайлауга юнәлтелгән эшчәнлек нәтиҗәсендә бездә узган елда бер бюджет урынына укырга алу турында өч гариза бирделәр. Бу уңыш, чөнки безнең белгечлекләр буенча уку кыен, оста куллар һәм баш эшләтә белгән кешеләр кирәк, әмма мотивациясе булган егетләр өчен кулдан килмәслек түгел.

Техник яктан яңадан җиһазландыру өчен чыгымнар таләп ителә. Электроника буенча бер эш урынын җиһазландыру 1,5 миллионнан башлана. 2018 елда безнең колледж мәгарифне үстерү программасы буенча федераль грант отты, моңа өстәп, республика бюджетыннан, партнерларыбыз – эш бирүчеләребез тарафыннан һәм колледжның бюджеттан тыш чыганакларыннан финанслар керде – техник яктан яңадан җиһазландыруның гомуми суммасы 38 миллион сумнан артып китте. Бу акчаларга без монтажлау өчен антистатик эшләү урыннары, заманча пайкалау җиһазы һәм контроль-үлчәү әсбапларының соңгы модификацияләрен булдырдык. Бүген колледж җиһазландыру ягыннан ресурс үзәкләреннән бернәрсәсе белән дә калышмый. Шуңа да колледж WorldSkills милли чемпионаты мәйданын җиһазландыру өчен җавап бирә.

Колледж кайбер эш бирүчеләргә караганда, алдынгырак җиһазларга ия. Әмма безнең кебек үк яңа җиһазлар белән эшләүче предприятиеләр дә бар, алар заманча эшләү урыннары һәм хезмәт шартларының яшь белгечләр өчен ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын аңлый. Заманча заказлар да шундый ук җиһазлар таләп итә.

Колледжда без 20 елдан артыграк кулланган, шулар буенча укыткан җиһазлар иде – пайкалау, сузу әсбаплары иске, эшләү урыннары җәлеп итәрлек түгел. Партнерлык кысаларында шәһәребезнең кайбер предприятиеләре иганә ярдәме күрсәтте, бушлай җиһазлар бирде, дүрт эшләү урынын җиһазландырырга ярдәм итте.

ХЫЯЛЫМ ТОРМЫШКА АША

Равилә Бикмөхәммәтова, һөнәри цикл дәресләре укытучысы, практика җитәкчесе. Радиоэлектроника аппаратурасын монтажлау һәм җыю буенча эксперт-тренер:

– Биредә мин 40 елга якын эшлим. Иң зур үзгәрешләр безнең студент Айнур Миңгәрәев II Милли чемпионат җиңүчесе булгач башланды. Гәрчә без беренче тапкыр гына катнашкан идек. Дөресен әйткәндә, җиһазлар аһ итәрлек түгел, әмма егетләр барыбер эшләделәр. Шуннан соң колледж беренче тапкыр дүрт яңа эшләү урыны булдырды.

Технологияләр бер урында гына тормый, үзең белми торып, башкаларны өйрәтеп булмый. Җиде еллар элек без өстән генә монтажлау турында ишетеп кенә белә идек, хәзер инде рәхәтләнеп катнаш монтаж кулланабыз. Колледжның укыту программасы халыкара таләпләргә ярашлы итеп төзелгән. Эш укучыларның урыннар алуында гына да түгел, мөмкин кадәр яхшы әзерлекле белгечләр тәрбияләп чыгару мөһим. Биредә укып чыккан белгечләргә ихтыяҗ булганда, алар аякларында нык басып торганда, хыяллар чынга аша.

ЯҢА ҖИҺАЗЛАР БУЛГАНДА УКУ КЫЗЫГРАК

Алексей Грузов, 3 нче курс студенты, WorldSkills-2018 төбәк чемпионатында катнашучы. «Электрон приборлар һәм җайланмалар» белгечлеге:

– Мин укый башлаганда, монтажлау остаханәләрендә мондый заманча җиһазлар юк иде әле – пайкалау станцияләре тора, бары тик бер генә эшләү урыны тулаем җиһазландырылган иде. Әмма узган ел яңа заманча җиһазлар кайтартылды һәм уку кызыграк була башлады.

WorldSkills турында безгә укытучылар сөйләде һәм тренировкалар башларга тәкъдим итте. Ун кеше арасыннан сайлап алганнан соң икәү калды. Шулай итеп, без өстәмә дәресләр ала башладык. Колледжда уку программасы буенча да күп нәрсәгә өйрәтәләр, әмма тренировкалар базасында без программаны тирәнрәк һәм алданрак үзләштерәбез. Мәсәлән, WorldSkills чемпионатының икенче модулендә программа белән тәэмин итү эшләнмәсе бара. Без температура һәм дымлылык датчигы белән микроконтроллер, яктырту датчигы – фоторезистор программалаштырдык. Боларның барысын да кесә метеостанциясенә программалаштырырга кирәк иде. Аппарат температура һәм дымлылыкны үлчи, караңгылык дәрәҗәсенә карап, яктылык белән экранга чыгара. Яки өченче модуль – биш төрле урыннан ватылган җайланма бирелә, шундагы ватылган урыннарны билгеләргә кирәк. Без шуларны табып, җайланманы эшләтергә һәм аның белән үлчәргә тиеш идек. Әллә ни катлаулы түгел, әмма белергә һәм уйларга кирәк. Тренировкалар базасында өйрәнгәннәрне искә төшерергә һәм кулланырга. **т**


worldskills
Russia







СТРАТЕГИЯ – МИНЕМ ФИКЕР

Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү турындагы фикерләрне туплауны дәвам итәбез. Гыйнвар уртасында бер төркем татар язучылары җыелып, әлеге документ турында сөйләште. Без бу санда сүзне иҗат әһеленә бирергә булдык.

«СӘНГАТЬ ХАЛЫККА ИЯРЕРГӘ ТҮГЕЛ, УЛ ХАЛЫКНЫ ИЯРТЕРГӘ ТИЕШ»

Ренат Харис, шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе

– Стратегиянең төп адресатлары – балалар һәм яшьләр. Димәк, ул, беренче чиратта, нәкъ менә аларның мәнфәгатен кайгыртырга тиеш. Бүгенге 40–50 яшьлек кешеләрнең психологиясе инде «утырган», характерлары формалашкан, гадәтләре тотрыклы. Әйе, урта яшьтәгеләр белән дә эшләү кирәк. Мисал өчен, һәр учреждениедә, министрлыкта, офиста кечкенә генә булса да татар әдәбияты китапханәсе булдыру һ.б. (татар, рус һәм башка телләрдә).

Стратегия куйган максатка ирешер өчен «яңа кеше рухы инженерлары» кирәк. Максим Горький үз заманында бу вазыйфаны язучыларга йөкләгән булган. Шулай да булсын! Ләкин кеше рухының төп инженерлары – укытучылар. Алар балаларыбызда милли горурлык хисе тәрбияләүче иң җаваплы кадрлар. Моның өчен Татарстанда Казан дәүләт педагогика университетын торгызырга, аны дөньядагы иң алдынгы укыту-тәрбияләү методикалары һәм әсбаплары белән тәэмин итәргә кирәк. Безгә белем бирүчеләр генә түгел, ә педагог-укытучылар кирәк. Татарстан моны, федераль үзәкне җәлеп итмичә, үзе генә дә тормышка ашыра ала. Аңа бернинди федераль законнар комачаулый алмый. Педагогика университеты Татарстан җитәкчелегенең һәм хөкүмәтенең беренче иң мөһим кайгырту объекты булырга тиеш.

Шулай ук Татарстандагы бөтен төр югары уку йортларында, ике-өч семестр булса да, җиңеләйтелгән программа белән татар әдәбияты укытылырга тиеш дип саныйм. Югары уку йортларын тәмамлаган татар белгечләренең туган телен һәм әдәбиятын белмәүләре халыкка тискәре йогынты ясый. Аларның җыелыш алып баруларын, халык белән сөйләшүләрен, интервьюларын тыңлап тору күңелсез. Хәтта татар министрлары, галимнәре, җитәкчеләре, район, шәһәр башлыклары да рәтләп татарча сөйләшә белми.

Массакүләм мәгълүмат чаралары халыкның рухын, эстетик зәвыгын, әхлакын тәрбияләүдә зур роль уйный. Шуның өчен дә татар журналистикасын булдыру мөһим. Моны КФУдагы татар журналистикасы кафедрасын яңадан сүтеп-корудан башларга кирәк. Әйтик – магистратура форматында. Анда башка вузлардан инде белгечлек алган, күпмедер язу сәләте дә булган татар телле бакалаврларны чакырырга кирәк. Юкса икътисад, медицина, музыка, театр, сынлы сәнгать, авыл хуҗалыгы, сәнәгать, төзелеш, финанслар турында профессиональ анализ ясап язылган язмалар белән Татарстан матбугатына, бигрәк тә Россия матбугатына чыга алырлык татар журналисты әлегә юк. Ни өчен шулай, дим, чөнки федераль телевидение каналларының һәрберсендә диярлек төрле сәяси шоулар бара. Аларда руслар, әрмәннәр, таҗиклар, яһүдләр, грузиннар, поляклар, украиннар, молдаваннар һ.б. катнаша. Шуларның берсендә дә татар милләтеннән булган сәясәтчеләр күренми. Димәк, без халыкара аренага чыгып сүз әйтерлек сәясәтчеләр дә әзерләмәгәнбез булып чыга. Бу мәсьәлә дә татар халкының үсеш проблемасына карый.

Татар халкы турында россиякүләм күрсәтерлек бер генә кинофильм да юк. Татар халкын түбәнсетә торган «Золотая Орда», «Орда» кинофильмнарын санамаганда, әлбәттә. Үзебез дә булдыра алмыйбыз, бөек кинорежиссёрларны, киностудияләрне дә бу эшкә тарта белмибез. Андый фильмнарсыз татарны дөнья тарихында һәм бүгенгесендә зур урын тоткан олпат халык итеп күрсәтеп булмый.

Татар эстрада сәнгате турында да фикерем бар. Андагы үзешчәнлектән арынмыйча, татарның эстетик зәвыгын заман таләпләре югарылыгына күтәреп булмаячак. Профессиональ сәнгатькә һәм әдәбиятка халык үз зәвыгы югарылыгыннан таләп куя, ә бу культура алгарышын туктатачак. Сәнгать халыкка ияреpгә түгел, ул халыкны ияртергә тиеш. Бу өлкәдә соңгы өч елда Президентыбыз ярдәмендә «Үзгәреш җиле» фестивале барлыкка килде. Йөзгә якын иң данлыклы халык җырлары, композиторларыбызның билгеле әсәрләре яңача яңгыраш алды. Аларның кайберләре инде «Культура» каналына, башка федераль телевизион каналлар аша халыкара киңлеккә чыкты. «Үзгәреш җиле» казанышларын халкыбызның зәвыгын тәрбияләүдә бик тә интенсив файдаланырга кирәк дип уйлыйм. Моның иң гади юлы – аның җырларын республика радио, телевизион каналларыбыз аша халыкка җиткерү...

Халык үзлегеннән үсми һәм камилләшми, аны талантлы шәхесләр үстерә. Әлбәттә, дәүләт, хөкүмәт халыкка да, шәхесләргә дә тиешле шартлар тудырганда. Беренче чиратта – әдәбият һәм сәнгать кешеләренә, чөнки фән, икътисад, хуҗалыкны алып бару – болар турыдан-туры милли өлкәләр (тармаклар) түгел. Талантлы язучыларга, композиторларга, режиссёрларга, рәссамнарга, артистларга республика җитәкчелеге, дәүләт оешмалары тарафыннан аерым мөнәсәбәт булырга тиештер. Бигрәк тә – яшьләргә.

Язучы, композитор, рәссам, күренекле театр әһеле вафат булгач, иҗат берлекләрендә мирас комиссияләре эшләде. Алар язучының кульязмаларын, дөнья күрми калган әсәрләрен барларга, аны тәртипкә китерергә, архивка тапшырырга булыша иде. Иҗат берлекләре бүген хокуксыз бер иҗтимагый оешма булып калды. Кадерле мирасларның язмышы белән хәзер беркем дә шөгыльләнми, хәтта кызыксынмый. Алар юкка чыга, йә алардан башкача файдаланалар.

Әзерләде:
Руфия Фазылова

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Йөз яшьтә дә **НИЧЕК** көр күңелле булырга

Язмышлар зилзиләсендә **НИЧЕК** «чиста» калырга

Ватанпәрвәрләрне **КАЙДА** әзерлиләр

Шаһинәләр **НИНДИ** принцларны көтәләр

«МИН ДӘ БЛОКАДАДА ЯШӘДЕМ, ТИК НАЧАР ХӘТЕРЛИМ. **КОТОЧКЫЧ ТӨШ КЕБЕК»**

Сугыш елларында Казанның 101 нче мәктәбе блокададагы Ленинградтан китерелгән балаларны укырга кабул итә. Хәзер анда Татарстанның илебез тарихындагы куркыныч сәхифәсенә багышлап ачылган уникаль музее урнашкан. Гыйнвар ахырында биредә ленинградлылар – блокада кичергән ветераннар җыелды.

Фото: Алёна Кутыркина

Альберт Комяков, «Бөек Ватан сугышы ветераннары – блокададагы герой-шәһәр Ленинград кешеләре» дигән җирле Казан шәһәре иҗтимагый оешмасы рәисе, авыр балачагы, үзенең герой әнисе һәм ветераннарның хәрби-патриотик тәрбиягә керткән өлешләре турында.

– Бәхеткә, мин блокададагы Ленинградның коточкыч хәлен тулысынча хәтерләр өчен, бик кечкенә булганмын. Мине аннан алып чыкканда – ә бу 1943 елның кышындагы хәл – мин нибары өч яшьтә генә булганмын. Әмма йортлар җылытылмаган һәм кешеләр, аз булса да җылыныр өчен, агачлардан башлап, паркетларга кадәр яккан ул вакыттан миндә истәлек булып хроник бронхит калган.

Минем әни кешеләрнең ни рәвешле соңгы мөмкинлек чикләрендә дә исән калулары турында сөйли иде. Шулай бервакыт ул, соңгы көчен җыеп, эштән кайтып килгәндә, бау белән буш бала чанасы тартып килүче кызыл флотчыга очрый. Аяклары хәлсезләнеп, шул чанага егыла. Ә бит җиргә егылса, торып баса алмаган булыр һәм абыем белән миңа да көн бетәр иде. Хәрби аны тиз генә абайламаган да әле, шул дәрәҗәдә ябык һәм җиңел булган ул, борылып карагач кына күреп, аның кайда яшәвен сораган да өйгә кадәр китереп куйган.

«Син ябык, хәлсез, кая сиңа авыр эшкә бару, бар предприятиегә, укы да үзеңә юл яр», – дип киңәш иттеләр миңа поездда бергә барган ир-атлар, ә минем, илдәге гомуми җанланышка кушылып, мәктәпне тәмамлаганнан соң доброволец булып чирәм җирләргә барышым иде. Поезд Чиләбе аша үтә, мин шунда төштем дә җирле машина төзү заводына эшкә урнаштым. Бер уңайдан читтән торып техникумда укый башладым.

Сигезенче класстан мин яхшы укырга кирәклеген аңлый башладым, максатчанга әвереллдем. Шуңа да Чиләбедән туп-туры МДУга укырга керергә ниятләп киттем. Университет буйлап хыялланып йөрдем дә... әни янына, Ленинградка кайтырга булдым. Вокзалга юнәлдем. Һәм шушында, Мәскәүнең Ленинград вокзалында, элекке мәктәп дустымны очраттым. Ул мине Карелиягә, Петрозаводскига китәргә күндерде (ул чакта бөтен җирдә «Долго будет Карелия сниться» дигән җырны уйнаталар, ул безне үзенә чакырып тора иде, әйтерсең). Килдем, заводка механик булып урнаштым да Петрозаводск Дәүләт университетының кичке бүлегенә укырга кердем.

Хатыным белән без инде 52 ел бергә, аның белән Ялта янындагы халыкара «Спутник» лагеренда танышкан идек. Өйләнештек тә, мин аны Петрозаводскига алып кайттым. Әмма тиз арада ул, минем Ленинград бронхитым көчәеп китүдән куркып, Татариягә күчәргә күндерде. Шулай итеп без биредә нигез кордык, тамыр җәеп җибәрдек.

Һәр вазыйфама мин бик җаваплы карадым. Безнең буын башкача булдыра да алмый. Инженер булып эшләдем, соңыннан партия эшен алып бардым. Пенсиягә Казанның Мәскәү районы администрациясе башлыгы урынбасары буларак чыктым, аннан соң миңа ветераннарның район союзында җитәкче булырга тәкъдим иттеләр, аннары блокадачылар оешмасы рәисе итеп сайладылар. Бу да – патриотизм тәрбияләү буенча эш. Анда катнашканнарның истәлекләре бәһасез.

Мәктәпләргә килеп, сугыш вакытында ниләр кичергәннәрен сөйләрлек кешеләр елдан-ел азая бара. Элек патриотлык хисе күпкә көчлерәк иде. Сугыштан соң шактый вакыт дәвамында хәтер исән булды, чөнки күпләр үзләре сугыш чорында үскән һәм анда катнашкан. 90 нчы еллардан без зур тизлек белән ул чорны күргән һәм кичкәннәрне югалта барабыз. Ориентирлар башка хәзер. Җитмәсә, алар тиз һәм кардиналь рәвештә үзгәрә. Әмма хәзер ситуация яхшырак якка төзәтелә башлады кебек. Мәсәлән, минем урынбасарым Эльвира Турентинова бөтен блокаданы Ленинградта үткәргән һәм барысын да хәтерли. Февраль аена гына да ул 20 мәктәпкә баруны планлаштырган. Балалар аны зур игътибар белән тыңлый, сораулар бирә. Бөтен өмет шуларда – хәзер инде алар яңа буыннарга сугыш афәте турында сөйләячәкләр, болар бүтән беркайчан да кабатланмасын өчен.

29 гыйнварда Татарстан Президенты безнең блокадачылар коллективына яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүгә керткән өлеше һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен тантаналы рәвештә Рәхмәт хаты тапшырды. **Без әлеге кыйммәтле документны безнең өчен кадерле 101 нче мәктәпкә бирергә булдык. Музей төзегәннәре өчен аларга блокадниклардан зур рәхмәт!**

Прошло уже 75 лет
С освобожденья Ленинграда.
Вот и название сменили,
Санкт-Петербургом окрестили,
Но всё же мы не позабыли,
Что сотворил геройский град…
Бомбёжки, голод и разруха,
Обстрелы частых канонад,
Но не сломили они духа
Твоих людей, мой Ленинград.
…Я тоже жил тогда в блокаде,
Но помню плохо. Страшный сон.
А в 43-м вместе с братом
Нас вывезли под Кострому в детдом.
Я обращаюсь к вам, потомки:
Храните в памяти ту жизнь,
Когда ценой погибших миллионов
Сумели победить фашизм!

Альберт Комяков

«ИҢ ГАҖӘЕП СЫЙФАТЫМ – ҖАНЛЫЛЫК, ТЕРЕЛЕК»

Җиде буынның шаһиты булган Зәйнәп Хәлиулла кызы Хөснетдинова әби-бабаларын да хәтерли, аңа оныкларының оныкларын күрергә дә насыйп булган. Әүвәлгечә күр күңелле, тормышны ярата торган әбекәй февраль аенда йөз яшьлек гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Бәхетем – балаларымда, дип тулы ышаныч белән белдерә ул.

Автор:
Алсу Троицкая

ТОРМЫШ ТУРЫНДА

– Миңа тормышта бәхет елмайды – вак-төякләрдә дә, иң әһәмиятле гамәл-адымнарда да. Бәхетле гомер кичердем. Рәшәткә артына тыгып куя алалар иде, шөкер, котылып калдым. Шундый сынаулардан соң кырык яшькә кадәр гомер дә итә алмам, дип уйлаган идем. Күрәсез, йөзгә кадәр яшәргә насыйп булды... Миндәге иң гаҗәп сыйфат – җанлылык, терелек – дип көлә Зәйнәп апа.

Авыл халкының күпчелеге, шул исәптән Зәйнәп апалар гаиләсе өчен дә, колхозлаштыру бер фаҗигагә әйләнә. Кулак ярлыгы тагылгач, туган нигезләре булган татар авылыннан ничек качулары турында искә алу аңа туксан елдан соң да авыр әле. Күзлек пыяласы артында яшь тамчылары ялтырап китә:

– Кулак, дип, гаиләбезнең бөтен нәрсәсен – җиребезне, йортыбызны тартып алдылар, бер бозауны гына күршеләрдә яшереп калдыра алдык. Ә бит асылда без ялкау булмаган өчен, авыр хезмәттән курыкмаган өчен зыян күрдек. Еллар узгач, әти-әниемә ул вакытта никадәр куркыныч янаганын, аларның хәтта качып китәргә мәҗбүр булганлыгын аңладым. Шул рәвешле без Владимир өлкәсендәге Вязники шәһәренә барып чыктык... Туку фабрикасына эшкә урнашып, беренче тапкыр йон тетү машинасы каршына басканда, миңа 16 яшь тә юк иде әле. Эшкә әтиемнең паспорты белән алдылар. Тормыш җайга салына башлаган гына иде, сугыш башланып китте...

СУГЫШ ТУРЫНДА

– Тормыш кинәт моңсу, төссез һәм тозсыз тоела башлаган мизгелләрдә, шул дәһшәтле биш елда никадәр авыр булганын искә төшерә идем. Сугышның беренче айларында туку фабрикасы эшләде әле. Аннары, чимал беткәч, станокларны сүндереп, безне танкларга каршы окоп казырга җибәрделәр. Салкын һәм юеш иде, ачлыктан интектек. Аннары госпитальдә, урман кисүдә, басуда эшләдем... Әтине – хезмәт армиясенә, энемне фронтка алып киткәч, әни белән Татарстанга, туган авылыбыз Шахмайга кайттык.

1942 елның 8 ноябрендә дус кызым белән мине Казанга, хәрби комиссариатка чакырдылар. Товар вагонына төяделәр дә көнчыгышка таба алып киттеләр. «Кызлар, Кемерово кокс химиясе заводында эшләячәксез, аннан барлык ир-атларны фронтка алганнар, Бөтен өмет сездә һәм пенсионерларда», – диделәр. Комбинаттагы эш тәмугка тиң булды. Түшәмнән тамып торган конденсат яулыкларны, чәчләрне яндырып керә иде. Сменалар – 12 шәр сәгать. Яллар да юк, отпусклар да.

Бервакыт миңа ике смена рәттән эшләргә туры килде, алмашым авырып китте. Тәүлек буе эшләдем, ә аннары тагын үз сменам вакыты җитте. Урам складына, тутырыр өчен, цистерна китерделәр. Мин шуны карап, тикшереп торам. Кырык градус салкын. Цистерна тулганчы, тиз генә бытовкага барып, җылынып килим, дип уйладым. Мичкә сөялдем дә шулай аягүрә йоклап киткәнмен бит. Моторчы кыз кычкырган тавышка уяндым: «Син нәрсә эшләдең? Цистерна тулып аккан, корткычлык өчен утыртачаклар үзеңне!» – ди ул.

Иртән мине цех башлыгына чакырдылар. Ул кычкырырга тотынды. Шунда кинәт минем дә сабырлыгым төкәнде: «Йокларга ярамый, ә өч смена эшләргә ярыймы?!» Начальник тавышын йомшартты: «Ярар, бар! Яхшылап ял ит, йокың туйсын...»

Язмыш мине шулай аяды һәм иректә калдырды. Әллә тәкъдир түгел, начальник мәрхәмәте белән булдымы икән ул хәл?..

МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

– Мәхәббәтем бердәнбер һәм гомерлек булды, беренче сыйныфтан ук яраттым мин аны. Хәйретдин белән сугыш вакытында да, аннан соң да хат язышып тордык. 1946 елда аның өйгә кайтуын белдем. Ә мин әле – Кемеровода! Ялга җибәрергә уйламыйлар да. Хәйләгә барырга туры килде. Дус кызым киңәше буенча, заводта эшләргә әнине дә, әтине дә алып килергә вәгъдә итеп, директор исеменә гариза яздым. Җибәрде.

Туй узуга ук район прокуратурасына хат килде. Мине эзлиләр: «Исән-сау икән, кичекмәстән кире җибәрергә!» Шул вакытта ирем Мәскәүгә – элеккеге командирларының берсенә хат язды. Ул командир исә завод директоры белән сөйләште...

БӘХЕТ ТУРЫНДА

– 1944 елда миңа заводта Мактау грамотасы һәм 500 сум премия бирделәр. Бөтен коллектив алдында, сәхнәдә. Ә 1946 елда «Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән хезмәт батырлыгы өчен» медале белән бүләкләделәр. Менә бу бәхет иде. Горурлык та...

Хәйретдинем белән озын-озак, мәхәббәтле тормыш кичердек. Бу да – бәхет. Ул алтын туебыз көнне вафат булды. Балаларыбыз да бик әйбәт, акыллы булып үстеләр. Барысы да мәктәпне – алтын медальгә, институтларны кызыл дипломга тәмамлады. Алты оныгым, аларның унбер баласы һәм бер оныгымның оныгы бар. Кызым һәм киявем тәрбиясендә, бернинди кайгы-мәшәкать белмичә, егерме елга якын яшим инде. Берничә ел элек Көек авылына үз йортыбызга күчтек. Киләчәгем турында борчылмыйм. Балалар һәм оныклар сәламәт яшәсен иде, дип кенә телим. Мине яратып яшәгән туганнарым бар. Болар барысы да – бик зур бәхет...

Фото: Александр Ефремов

ШАГЫЙРЬНЕҢ ЭЧКЕРСЕЗ ДӨНЬЯСЫ

Фотолар ТР Милли архивы фондларыннан алынды

Шагыйрь кайда һәм кайчан ярала? Әнисенең йөрәк астында бөреләнгәнче, кайда була ул? Нәкъ менә билгеле бер урында, гаиләдә, шартларда, заманда тусын өчен, Галәмдә нинди зилзиләләр бөтерелә дә, нинди тәртип урнаша? Бигрәк тә һәр шигъри юлы сулышка сусыл-рәхәт җил булып ягылырдай шагыйрьләрнең яралу сере мәңгелек табышмак булып кала. «Туфрактан», дибез без, гадәттә. «Суыннан», дибез. «Әнкәсеннән», «әткәсеннән» диярга дә яратабыз. Әмма болар табышмакны барыбер чишми. Шулай да рифмалы юллар, биографик детальләр, замандашларының истәлекләре аша капшана-капшана барып, без ул мәңгелек серне чишәргә омтылабыз.

Без балачактан ятлап үскән шигырьләре, поэмалары белән кадерле бу шагыйрьне замандашларының күпчелеге «сабыйларча эчкерсез», «саф күңелле», «көчле рухлы» дип искә ала. Аның язмышындагы кайбер әһәмиятле һәм дәһшәтле борылышлар да әнә шул шәхси сыйфатлары, холык-фигылендәге хасиятләре белән бәйле булмадымы икән, дип уйлыйм еш кына. Ул калдырган шигърияттә тормышның яктылыгы да, хәсрәте дә гаҗәеп психологизм, нечкәлек аша бирелә. Чисталык бөркелә. Аның турында еш кына «чиста иде» дип тә әйтәләр. Каләмдәшләренең сугыш хатларында язышкан сүзләрендә дә нинди тирән мәгънә, кадерләү ята: «Фатихны ничек тә саклап каласы иде...»

Фатих Кәрим тормышы һәм иҗаты турында үзе исән чакта ике автобиография язып калдыра. Аларның берсе 1943 елның 22 октябрендә языла. Каралама кульязмасын хәрби частьтәгеләр, шагыйрьнең башка кульязмалары белән бергә, үлеменнән соң, гаиләсенә озата. Рус телендә язылган оригиналы хәзер ТР Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының фондында саклана. Шагыйрьнең икенче автобиографиясе дә мәгълүм. Анысын Фатих Кәрим 1944 елның 10 ноябрендә ТАССР Язучылар берлеге өчен яза.

Фатих Кәримнең тормыш сәхифәләре буйлап әнә шул ике документка нигезләнеп юыртып узыйк. Шартлы рәвештә 1943 елда язылганын – беренче, 1944 елдагысын икенче автобиография дип атау дөрестер.

Әзерләде:
Луиза Янсуар

«КӘККҮКНЕҢ ТАМАГЫ БИК СИЗГЕР...»

*Минем туган авылым –
Дим буенда. Уникe яшькә
кадәр балачагым шул авылда,
Дим буенда үтте.*

2 нче автобиографиядән.

Дим елгасы.

Фото: fotokto.ru

«Дим буе матур ул. Анда сандугачлар сайрыйлар, тургай, сыерчыкларның саны булмый. Ташкын кайтып, су тонгач, төбендәге ташлыклар күренеп ага башлагач, анда бөтен тугай әрәмәләренә кунып кәккүкләр дә кычкыра башлыйлар. Ә су коенырга яратучы малайлар, кызлар шул кәккүкнең беренче кычкыруын гына көтәләр.

Мин йон юучы Сәхипниса әбиемнән:

– Әби, нигә кәккүк иртә кычкырмый ул, нигә кәккүк кычкыргач кына су коенырга ярый? – дип сораган идем.

Ул түбәндәгечә җавап бирде:

– Кәккүкнең тамагы бик сизгер, нәзберек була, ди, балам, аның. Шуңа күрә коенырлык булып җылынып җиткәч кенә, шул суны эчеп, тамагы кымыз эчкән җырчы башкортларныкы кебек җәйланып китә, ди».

«Дим кызы Фатыйма» хикәясеннән өзек.

Мин – Кәримов Фатих Вәлиевич, 1909 елда Башкортостан АССРның Бишбүләк районы Ает авылында дин хезмәткәре – мулла семьясында туганмын. Бала чактан сукыр булган әтиемнән бүтән семья членнары игенчелек белән шөгыльләнгән. 1918 елда 65 яшендә әтием авырып үлде. Мин әнием тәрбиясендә калдым һәм, 1922 елга кадәр алар белән бергә яшәп, авыл мәктәбенең ике классын тәмамладым.

1 нче автобиографиядән.

1909 елның 9 гыйнварында дөньяга килгән малайга Фатих дип исем бирәләр. Гарәп теленнән тәрҗемәдә ул «ачучы», «башлап җибәрүче», «яулап алучы, җиңүче» дигән мәгънәләрне белдерә. Бәлки, мулла әтисе өчен бу исем Коръәнне ачып җибәрүче сүрәнең исеменә бәйле рәвештә дә, олы мәгънәгә ия булгандыр. Шәҗәрәләренә караганда, элек бу гаиләдә Фатих исемен берәүгә дә кушканнары булмый.

Гаиләнең килеп чыгышы хакында мондый риваять бар: имеш, аларның ерак бабалары – чыгышы белән Мисырдан. Алай гына да түгел, ул әле табиб, сәяхәтче, хаҗи да булган, имеш.

Авылдашлары һәм якташлары арасында. Фатих Кәрим – алгы рәттә, сулдан икенче.

Фатихның әтисе Әхмәтвәли ике тапкыр өйләнә. Беренче хатынынннан дүрт баласы туа. Икенче хатыны Гөлҗамалдан исә – унбер бала: Габдулла (13–15 яшендә вафат була), Оркыя, Мәҗит, Фатыйма (1921 елда тифтан үлә), Габдерәхим (1915 елда тифтан үлә), Мәрьям, Габдулла, Гобәйдә (3 яшендә чәчәк авыруыннан вафат була), Әхмәтлатыйф (яшь ярымлык чагында тифтан үлә), Гобәйдә һәм иң кечесе – Фатих.

Фатих туганда гаиләдә җиде бала була. Алар бер-берсенә гомер буена ярдәм итешеп яшиләр. Мәсәлән, 1938 елда Фатих Кәримне кулга алганнар дигән хәбәр килеп ирешкәч, Гобәйдә апасы, пәлтәсен сатып, шул акчаларны Фатихка тапшырыр өчен олы кызын Уфадан Казанга җибәрә.

Гаиләдә авыр хезмәт белән көн итеп яшиләр, тормыш йөген бергәләп тарталар. Сукыр әтиләреннән кала, барысы да басудакырда эшли, крестьян хезмәтенең ни икәнен кечкенә Фатих үз җилкәсендә татып үсә. Авыр яшәсәләр дә, бу гаиләдә җылы, тату рух, бер-берсенә карата ихтирам, ярату хөкем сөрә.

Әбисе, әнисенең риваятьләрен, әкиятләрен күңеленә сеңдереп, әтисенең шигырьләрен тыңлап, дөньяга балачактан аек акыл белән дә, шагыйранә хиссият белән дә карарга өйрәнеп үсә кечкенә Фатих. Аның турында «бик тәэсирләнә торган, хисле иде», «кызыксынучанлыгы һәм мавыгучанлыгы белән аерылып торды» дип искә алалар. Шагыйрьнең юморы хакында да легендалар йөри. Сизгерлеге, нечкәлеге, кечә күңеллелеге хакында да.

Фатих Кәримнең әтисе балаларын укымышлы һәм намуслы итеп тәрбияләп үстерергә тырыша. Ул үз авылларында авторитетлы кеше була, монысы да балаларга үз йогынтысын ясамый кала алмаган, билгеле. Фатих өчен иртә китеп барган әтисе гомергә зур идеал була.

Кәримовлар гаиләсендә балалар укырга һәм язарга мәктәпкә барганчы ук өйрәнәләр. Әниләре Гөлҗамал матур җырлавы белән билгеле. Шулай ук бик оста итеп балаларга әкиятләр, риваятьләр сөйли, аларны да яттан сөйләтә торган була ул.

Кечкенә Фатихның урамдагы сарайда китаплар һәм дәфтәрләрен саклый торган кечкенә сандыгы була. Ул хәтта балыкка барганда да китапсыз бармый, дип искә ала Гобәйдә апасы.

Әдәбият белән кызыксынуым, әтием үлгәч, һәр көнне әниемне елата-елата аңа «Сак-Сок» бәетен укудан башланды. Һәм әдәби әсәрләр язу теләге бала чагымнан ук йөрәгемә кереп урнашты. Егет чагыннан ук тома сукыр әтиемнең үзе өчен язган шигырьләрен безгә укытыргалаганын ишетү, апам Мәрьямның үз дәфтәренә Дим буе табигатен тасвирлап язган күп кенә шигырьләрен башкалардан яшереп миңа гына укуы, революция еллары башлангач, абыем Ярлы Кәримнең матбугатта чыгып барган шигырьләрен уку – болар минем әдәбият өлкәсенә табан юнәлеш ясавыма төп һәм башлангыч этәргеч булдылар.

2 нче автобиографиядән.

АБЫЙ ДА, ӘТИ ДӘ...

Әхмәтвәли мулланың вафатыннан соң, озак та үтми, туган авылына күп еллар читтә каңгырап йөргәннән соң, Габдулла кайтып төшә. Ул, өлкән абыйсы буларак, Фатихка әтисен алыштыра. Габдулла Кәрим, Каргалы мәдрәсәсен тәмамлап, дөнья гизәргә чыгып китә: казах далаларында мөгаллим булып эшли, Оренбургта газета тарата, Ташкентта ишегаллары себерә, Курганда кучер була. Үз теләге белән фронтка китә. Берничә тапкыр авыр яралана, контузия ала. 1920 елда аны «Башкортостан хәбәрләре» газетасына эшкә алалар, аннары – Эстәрлетамакның РКП (б) өяз комитетына. Соңрак ул «Башкортостан» газетасының сәяси секретаре вазыйфасын башкара, Ярлы Кәрим тәхәллүсе белән көн үзәгендә торган сәяси-иҗтимагый темаларга кискен-кискен мәкаләләр яза. Шулай ук – шигырьләр белән пьесалар да.

Хатыны Кадрия Ишукова белән. 1935 ел.

1922 елда минем туган абыем, татар шагыйре, 1918 елдан ВКП (б) члены, Гражданнар сугышы елларында Ленинградтагы башкорт полкының политработнигы Габдулла Кәримов кайтты. Ул мине Бәләбәй шәһәренә алып китте һәм педагогия техникумының хәзерлек курсларына укырга урнаштырды. Мин анда ике ел укыдым һәм 2 нче хәзерлек группасын тәмамладым, шунда ук 1923 елда пионерлар оешмасына кердем. Ә 1924 елда шул ук абыем Габдулла Кәримов мине Казанга чакырды. Ул анда партиянең Верхнегородской райкомында агитпроп мөдире булып эшли иде.

Мин аның янына Казанга килдем.

1 нче автобиографиядән.

Энесе Казанга килгәч, абыйсын, эше буенча, Башкортостанга күчерәләр. Киткәндә, Габдулла Кәримов Фатихны Н.К. Крупская исемендәге яшүсмерләр йортына урнаштырып калдыра. Фатих анда бер ел яши. 1925 елда комсомол сафларына керә.

Абыйсының революцион романтизмы һәм оптимизмы аның формалашуына бик зур йогынты ясый. Фатих аның уйларын, дөньяга карашларын сеңдерә. Шулай ук Бәләбәй педагогика техникумында укыганда Гази Кашшаф белән аралашуы да аңарда зур тәэсир калдырган була. Кашшаф ул чакта белгән каләмдәш дустының «шат күңелле» булуын, «бөек көрәш һәм үзгәрешләргә алып чыгачак планнар белән янып йөрүен» язып калдыра.

1925 елда мин Казан җир төзелеше техникумына укырга кердем һәм 1929 елга кадәр шунда укыдым. Абыем Габдулла Кәримов Башкортостан республикасының Белорецк кантонында партия эшендә эшләде, 1926 елда аны, психик авыру аркасында, Уфа психиатрия больницасына салдылар, ул анда 1937 елга кадәр булды һәм 1937 елда үлде.

1 нче автобиографиядән.

САРЫ БОТИНКАЛАР БЕЛӘН ЧӘЧӘК ГӨЛЛӘМӘСЕ

Җир төзелеше техникумы Фатих Кәримгә булачак тормыш иптәше Кадрия Ишукова белән очрашуны бүләк итә. Шулай бервакыт Кадрия туташ комсомол ячейкасы җыелышны узарга тиешле бүлмәгә чәчәкләр гөлләмәсе кертә. Аларны кая куярга белмичә аптырабрак тора. Фатих Кәрим шул чакта аңа чәчәкләрне үзенең кружкасына куярга тәкъдим итә.

«Миңа ул баштарак бер дә ошамады. Шыгырдап торган сары ботинкалары күңелгә тия торган иде. Соңрак мин бу ботинкаларның, Фатих киеп килә торган пиджак кебек үк, бөтен тулай торакка бер булуларын һәм аны чиратлап киюләрен белдем...»

Кадрия Ишукова истәлекләреннән.

Кадрия белән Фатихны берләштерә торган уртак яклар шактый була: икесе дә 1909 елда туганнар, икесе дә читтән килгәннәр, икесе дә тулай торакта торалар, икесенең дә биографиясе «чиста» түгел... Кадрия Ишукова тумышы белән Сембер ягыннан, Гаффаровлар нәселеннән була. Алар бик хәлле руханилар санала, Кадриянең әтисе исә сәүдә эше белән шөгыльләнә, революциядән соң, беренчеләрдән булып, «кызыл иттарткычка» эләгә.

Кадрия Ишукова бер вакыйганы искә ала торган була. Бервакыт комсомол ячейкасына ике аноним хат килә. Аларда Ишукова белән Кәримовны пролетар булмаган чыгышларын яшергәннәр, дип, эшләрен тикшерергә кирәклеккә ишарә ясала. Ячейка секретаре буларак, Фатих Кәрим бу аноним-каларны ертып та ташлый алган булыр иде, әлбәттә. Әмма ул аларны оешма вәкилләренә күрсәтеп, җыелыш җыярга кирәклеген әйтә. «Кысыр чәчәкләр» поэмасында сурәтләнгән вакыйгалар әнә шул җыелышка барып тоташмыйммы икән?

1930 елда Кадрия Ишукова белән Фатих Кәрим өйләнешәләр. Кадрия Ишукова бу хакта миңа ничек искә ала: «Безнең язмышлар кушылганда, Фатих миңа бервакыт болай диде: «Безнең тормыш, көнләшүчеләр дә сокланырлык үрнәк булсын иде...»

Кадрия Ишукова истәлекләреннән без бу елларда яшь шагыйрь Фатих Кәримнең спорт белән мавыгуын, футбол матчларына йөргән, классик көрәш белән кызыксынуын беләбез. Шахмат яраткан ул, көннәр буе такта артында утырган чаклары булган. Өйләренә язучы Мирсәй Әмирнең еш килүен искә ала Кадрия ханым. Алар икесе очрашса, ашар өчен дә тактадан аерып булмый иде үзләрен, ди. Җәй көннәрендә яшь гаилә Татарстан китап нәшрияты оештырган пикникларга чыга торган була, анда волейбол уйныйлар. Кышкы кичләрдә исә Фатих Кәрим Кабан өстендә боз шуарга яраткан.

Фатих Кәрим алгы сызыкта көрәшеп, берничә мәртәбә авыр яралана. Казандагы госпитальдә. Май-июнь, 1942 ел.

1925 елдан әдәбият белән шөгыльләнә башладым, ә 1927 елдан комсомолның татар өлкә матбугатында әдәби әсәрләрем чыгып килә. 1928 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты пионер газетасы «Яшь ленинчы»ны чыгара башлады һәм мине редколлегия әгъзасы итеп билгеләде. Анда мин бер ел эшләдем. 1929 елда, техникумны тәмамлагач, «Крестьян газетасы» дигән өлкә газетасына әдәби сотрудник булып урнаштым. Бер елга якын анда эшләгәч, «Азат хатын» журналы редакциясенә җаваплы секретарь булып күчтем. Анда елга якын эшләгәннән соң, татар язучылары органы булган «Атака» журналына күчеп, редколлегия члены, җаваплы секретарь булып эшләдем. 1931 елның көзендә Кызыл Армиягә алындым. Берьеллыклар командасына кертелдем, ләкин 3 айдан соң Идел буе хәрби округының политидарәсе приказы белән мине Идел буе хәрби округының Казанда татар телендә чыга торган газетасына хәрби журналист итеп күчерделәр. Анда мин хәрби хәбәрләр бүлегендә 1933 елның гыйнварына кадәр, ягъни демобилизацияләнгәнче эшләдем. Ул чакта бу газетаның редакторы булып миңа ВКП (б) членлыгына кандидатлыкка керү өчен рекомендация биргән Нәҗметдинов К.Г. эшли иде.

1933 елның гыйнварында ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты мине Татгосиздатның яшьләр-балалар әдәбияты секторына җаваплы редактор итеп билгеләде. Анда мин 1937 елның май аена кадәр эшләдем.

1941 елның 30 декабрендә мин Кызыл Армия сафларына чакырылдым...

1 нче автобиографиядән.

«ЧИСТАЛАР» ҺӘМ «ЧИСТА ТҮГЕЛЛӘР»

Шагыйрьнең КГБ архивларындагы «эше», ул үзе акланып, күп еллар үткәч тә ябык килеш ята. «Яшерен» дигән гриф алынган булып исәпләнсә дә, кайбер материаллар «ябык» булып калуын дәвам итә. Болар – нигездә протокол өземтәләре.

Матбугатта Фатих Кәрим тормышындагы «ак тaплар» турында беренчеләрдән булып язучы Рафаэль Мостафин язып чыкты. 1920–50 нче еллардагы репрессия корбаннарының «эш»ләрен яхшы белүчеләрнең берсе буларак, ул Фатих Кәримгә карата да үз мөнәсәбәтен анык белдерде: аны эзәрлекләү кулга алганчыга кадәр бик күптәннән башланган иде инде, ди ул. 1937 елда «Кызыл Татарстан» газетасында Ләбиб Гыйльминең бер мәкаләсе басылып чыга. Шунда ул шагыйрьне совет пролетар әдәбиятындагы «чит элемент» дип атый, «советка каршы» язучыларның берсе, дип тамга суга. Фатих Кәрим «эше»ндәге төп гаепләү пунктларының берсе – аның троцкизмда гаепләнгән рус шагыйре Павел Васильев белән дустанә мөнәсәбәтләре. Чыннан да, Фатих Кәрим бу шагыйрьнең поэзиясенә ачыктан-ачык соклану белдергән була. Алар бервакыт

Кадрия Ишукова кызлары Ада һәм Ләйлә белән. 1944 ел.

Язучылар йорты ресторанында шигърият турында озаклап сөйләшеп тә утыралар…

Менә шуннан башлана инде. Бу беренче «таш» акрынлап зурракларын кузгата: Фатих Кәримне комсомол сафларыннан чыгаралар, «ике якка уйнаучы пычак», әмма асылда «халык дошманы» дип атап, эшеннән чыгаралар. Берничә айдан кулга алалар.

Фатих Кәрим үзе моның асылын якыннарына болайрак аңлата: Татгосиздатта эшләүче Фатих Кәримгә берничә ел элек комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Ләбиб Гыйльми «Чын мәхәббәт» дигән яңа романын китергән була. Кәрим аны, «эшләп бетерергә кирәк», дип, кире кайтара… Тагын бер «ачу саклаучы» дип Нур Баянны искә алалар. Әмма бу «ачу»ны да Кәрим, әйтерсең, үзе «сорап ала» – ул аның шигырьләрен тәнкыйтьләп, «чиле-пешле» дип атап, эпиграмма язып чыккан була.

Рафаэль Мостафин бу чорны «дары мичкәсе»нә тиңли – массачыл репрессияләр тамыр җәйгәндә, кайда, кайчан, кемнең нинди әйткән сүзе, кылган гамәле килеп чыгып «шартлаячагын» бәрәү дә күрәзәлек итеп белә алмый. Шагыйрь Ренат Харис фикеренчә, кайсы гына эпоха булмасын, кеше факторы, шәхси фактор – үз көчен җуймый торган гаять көчле психологик корал ул.

«МИНЕМ ДӘ ӘТИЕМ БАР!...»

Әле кулга алынганчыга кадәр үк, үз муены тирәсендә элмәкнең кысылуын сизеп алган Фатих Кәрим көмәнле хатынын Уфага озата. Хәлнең ни дәрәҗәдә хәтәр булуын сиздермәскә тырыша. Кадрия Ишукова 1937 елда үзе Уфада яшәгәндә эшсез һәм яртылаш дуслэрсыз, терәксез калган иренең Казанда кульязмаларын тәртипкә китерүе, күп укуы турында яза.

Хатыны кайтып кергәндә, Фатих Кәрим бик нык ябыккан, йончыган була. Кадриясе шкафтан катып беткән эремчек кисәге табып ала, ташларга тели. Шулчак Фатих Кәрим аңа: «Ташлыйм күрмә, ул бит минем төп ризыгым иде, ул мине ачлыктан коткарды!» – ди. Ә үзе Уфага гаиләсен кайтарырга билетларны беренче класска алырлык итеп җибәрә…

Фатих Кәримне кулга алыр алдыннан бер көн алда – 1938 елның 2 гыйнварында төрмәдә язучы Мирсәй Әмирдән сорау алалар. Мирсәй Әмир аңа исемнәре аталган язучыларның берсен дә «советка каршы» дип исәпләмәвен ассызыклый. Пантюркизм белән Троцкий тарафдары булуда гаепләнгән Фатих Кәримнең 1938 елда фатирын тентегәндә 4 папка кульязмалар булуы теркәлгән. Берсе тулысы белән хатлардан тора, диелә.

Шагыйрьнең эшен ул чактагы шактый язучыларның «эш»ләрен алып барган һәм моңардан ләззәт, тәм тапкан, тарихтан яхшы белгеле булган тикшерүче Усманов алып бара. 1938 елның 11 гыйнварында дәүләт сагының кече лейтенанты Смирнов Фатих Кәрим белән беренче сорау алу уздыра. Нәтиҗәдә Фатих Кәрим үзенең җинаятен дә «таныган», башкаларны да «саткан» документ төзелә. Бу документта бөтен нәрсә җентекләп, алдан уйланылып төзелгән булуы белән таң калдыра… азакта куелган шагыйрь имзасы гына, документ белән эш иткән архивларны «казучылар» белдергәнгә ышансак, сәер һәм үз-үзенә охшамаган…

Суд карары 1938 елның 3 гыйнварында кулга алынган Фатих Кәримне «контрреволюцион эшчәнлек алып баруы» раслангганга, иреккә чыгаруны мөмкин түгел дип таба, аның милкен конфискацияләргә кирәк дигән карар чыгара. Бернинди гаризалар, СССРның Югары судына юлланган хатлар да шагыйрьнең «эше»н киредән карауга китерми. Ягринлагта Фатих Кәрим тугызынчы лагерь участогында эшли. Монда язган хатларында да өмете барыбер сүрелмәгән икәнлеге күренә. Хатыны Кадрия Ишкулова да СССРның Югары судына язуын дәвам итә.

1940 елның 2 ноябрендә шагыйрьне аклауга тәүге адымнарның берсе булган документ пәйда була. Анда шагыйрь эшен яңадан карау турында сүз бара… 1941 елның 3 декабрендә фурункуллар белән капланган, авыру, хәлсез Фатих Кәрим өенә кайтып егыла. Кайтса, ишекләрендә – йозак. Хатыны эштә, балалар – балалар бакчасында. Ашбүлмәсе ролен дә үтәгән бүлмәгә керә. Хатыны балаларны бакчадан алыр алдыннан мичкә ягып җибәрер өчен йөгереп кайтса, ишегалды себереп йөрүче Маруся аны: «Кер әле миңа», – дип дәшеп ала. Керсә – Фатих Кәрим утыра…

Кадрия Ишкулова ирен житәкләп балалар бакчасына алып китә, балаларны алырга. Ул вакытта дүрт яшьтә булган Ләйлә, бөтен төркем алдында әйтеп сала: «Әйдәгез, минем әтине чыгып карыйк, минем дә бит хәзер әтием бар!»

«БЕР ГЕНӘ ШЕЛТӘ АЛГАНЫМ ДА ЮК…»

Фатих Кәрим фронтта алгы сызыкта күренекле татар язучыларының берсе. Алай гына да түгел, мөмкинлек чыккан һәр мизге-



лендә ябырылып язган әдип тә. Күз алдына китерүе дә кыен: яулар тынып торган арада ул 9 поэма, 2 повесть, 1 драма әсәре, 100 дән артык шигырь иҗат итә.

Журналыбызда Фатих Кәримнең фронт чоры турында язма басылган иде, анда аның гаиләсе белән алышкан хатлары да урнаштырылды. Ул хатларда шагыйрьнең бөтен асылы күренә.

Ә автобиографиясендә, ирекле илдә, тыныч шартларда кичкән «зиндан»нарын, күргән михнәтләрен ваемлапмы, ул болай язып калдырган...

Кызыл Армия сафына чакырылгач ук мин яңа формалаштырылган 436 дивизиягә туры килдем һәм февральдә шул дивизия белән фронтка киттем. Смоленск өлкәсендә Суханичтан арырак, Масаальск юнәлешендә булдык. «Зайцева Гора» дигән биеклек өчен сугышларда мина ярчыгы белән сул аягым яраланды, госпитальгә җибәрелдем, анда 1942 елның 20 августына кадәр дәваландым. Шуннан соң Татвоенкомат аша команда белән Тула өлкәсенә җибәрелдем һәм, 226 нчы танкка каршы дивизионга туры килеп, ПТРның беренче номер хезмәтен башкардым. 22 ноябрьдә кабат аягым мина ярчыгы белән җиңелчә яраланды һәм 2953 нче номерлы ВГЛРга озатылдым. Анда 1943 елның 25 маена кадәр торырга туры килде, чөнки уң аягымдагы яра янында көчле экзема башланды. 25 майда савыгучылар батальонына килеп җиттем. Анда мине 1 нче ротаның 2 нче взводына командир итеп билгеләделәр. Шуннан бирле мин штат буенча шул вазыйфаны башкарам.

1941 елның 30 декабреннән бирле РККА сафында булып, бер генә шелтә алганым да юк...

1 нче автобиографиядән.

Сапер взводы командиры, лейтенант Фатих Кәрим 1945 елның 19 февралендә Пруссиядә һәлак була. Кабере Кенигсберг шәһәреннән 40 чакрым ераклыкта урнашкан Багратионовск шәһәре янындагы туганнар каберлегендә була. Сугыш вакытында әлеге каберлек «37, 8 нче калкулык» дип атап йөртелә. Шагыйрьнең каберен 1956 елда табып алалар һәм Багратионовск шәһәрендәге мемориал комплекска күчереп җирлиләр. Комплексның үзәгендә булган кабер ташына: «Лейтенант Фатих Карим – татарский поэт, погиб героем в бою с немецкими захватчиками 19.02.1945 г.» дип язылган.

Фатих Кәрим – I дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнгән.

«Фатих Кәрим – һәр шигырь юлы белән ватанына фидакарь хезмәт иткән җырчы солдат. Аның Казан музеенда реликвия итеп саклана торган шинеле генә түгел, кулъязмаларының соңгы битләренә кадәр пулялар белән тишкәләнеп беткән».

Луи Арагон, француз язучысы

ПАТРИОТЛАР КАЙДА ТӘРБИЯЛӘНӘ?

– Тәтештә! – өйдә үткәргән ял көннәреннән соң, әлеге борынгы шәһәргә яңа уку атнасына китеп баручы ике метрлы җитез кадеттан «Татарстан» үзенең конкрет соравына әнә шундый конкрет җавап алды. Киң җилкәле, аркасына капчык аскан, хәрби аяк киеменнән иде ул кадет... Без дә аның артыннан юлга кузгалдык.

Фото: Алёна Кутыркина

Автор:
Алёна Кутыркина

ҖИТДИ АЕРМА

Гади үсмернең бүлмәсендә моны күз алдына китерүе дә кыен: кояш нурларында бер генә тузан бөртеге дә, ялтыраганчы ышкып юылган идәндә бер генә чүп кисәге дә күренми! Ә җеп сузып тигезләгәндәй карават җәймәләре өстендәге мендәрләрнең пөхтә өчпочмаклары җилкәнле көймәләр флотилиясен хәтерләтә. Һәм тынлык… Ни өчен тын булуы аңлашылса да, әмма бер уку бүлмәсе ишегенә язу беркетелгән: «Тавышланмагыз! Барабанчылар шөгыльләнә!» Менә бу язуны аңлап булмый.

Тәнәфестә кадетлар, гади мәктәп балалары кебек, юлларында очраган бөтен нәрсәне ватып-аударып, көлешә-көлешә, коридордан йөгереп үтәргә мөмкин. Әмма болай эшләмәскә тырышалар, чөнки тәртип бозу өчен үзләрен чираттан тыш наряд көткәнен яхшы беләләр. Тик биредәге кыз һәм малайларның җәзага мөнәсәбәте «гражданкага» караганда бөтенләй башка – монда ул тәртипне яхшырту һәм гомуми построениедә макталу өчен стимул булып тора.

Укытучылар мәктәпнең 9 Май хөрмәтенә парадка ничек әзерләнүен искә төшерә. Анда катнашыр өчен, кадетлар яхшы укырга тиеш булган. Бишенче сыйныфта укучы бер малай «койрыкларын» төзәтеп өлгерми, шунлыктан бәйрәмне оештыруда катнашса да, аңа форма кияргә рөхсәт ителми. Тамашачылар, кызганып, аны парадта катнаштыруны үтенсә дә, малай җитди итеп: «Кирәкми, барысы да гадел, шулай булырга тиеш!» – дип җавап бирә.

Шунлыктан ата-аналарга балаларның, биредә ярты ел укыганнан соң, кадетлар һәм гади мәктәп арасында аерма бармы, дигән сорауга: «Аерма җитди », – дип хәрбиләрчә төгәл җавап бирүенә гаҗәпләнергә кирәкми. Бу җавап чыгарылыш имтиханнарыннан соң тагын да ышандыргычрак яңгырый – кадетлар БДИ не гади мәктәптәге яшьтәшләреннән яхшырак бирә, чөнки катгый дисциплина аларга секунд саен телефон һәм башка гаджетлар белән уйнап утырырга ирек бирми, урта мәктәптә исә әлеге гаджетларны бөтенләй тыю мөмкин түгел.

ТЕТЮШСКАЯ КШИ

“ – Элек мин военкоматта эшләдем, һәм армия турында бернәрсә дә белмәгән, шуңа күрә анда хезмәт итәргә теләмәгән яшьләрне күрү мине бик гарьләндерә иде. Телефон, әйтерсең, кулларына ябышкан – аларның бердәнбер мавыгуы һәм дөнья белән элемтәсе ул. Шунлыктан, кадетлар мәктәбе директоры вазыйфасын тәкъдим иткәч, мин шунда ук ризалаштым.

ВАТАННЫ КӨЧЛӘП ЯРАТТЫРЫП БУЛМЫЙ

Вил Нуруллин, генерал-майор Владимир Хапаев исемендәге Тәтеш кадетлар интернат-мәктәбе директоры:

– Быелгы уку елында безгә бишенче сыйныфка бер Казан малае укырга килде. Аның кадет булу теләге бик ихлас булган кебек, күз яшьләре дә, әнисен сагынуы да шулкадәр үк ихлас иде. Тынычлана алмыйча, ул һаман елады да елады. Психологка да алып бардык, гел игътибар үзәгендә дә тоттык. Бераз онытылып тора да, ялга өйләренә кайтып килүгә үк, барысы да яңадан кабатлана. Малай мөстәкыйльлекнең бездәге дәрәҗәсенә әзер түгел иде. Ул ияләшсен, тынычлансын һәм өен сагынмасын өчен бер ай вакыт кирәк булды.

Ияләшеп беткәч, балаларның ял көнендә дә өйләренә кайтасы килми, чөнки бездә һәрвакыт ниндидер булса кызыклы шөгыль табып була. Мәсәлән, проектор сатып алгач, ашханә кадетлар өчен кино залына әйләнде. Уйламаганда, совет фильмнары үсмерләрдә зур кызыксыну тудырды. «Ул да безнең кебек, тик күп еллар элек», – ди балалар миңа «Офицеры» фильмының нәни герое турында. Кадетлар үзләре дә күңелсезләнеп утыра торганнардан түгел, аларның энергияләре ташый: әле мендәр белән сугышалар, әле бер-берсенә теш пастасы сылыйлар… Элек ничек булган, хәзер дә шулай шукланалар.

Элек мин военкоматта эшләдем, һәм армия турында бернәрсә дә белмәгән, шуңа күрә анда хезмәт итәргә теләмәгән яшьләрне күрү мине бик гарьләндерә иде. Телефон, әйтерсең, кулларына ябышкан – аларның бердәнбер мавыгуы һәм дөнья белән элемтәсе ул. Шунлыктан, кадетлар мәктәбе директоры вазыйфасын тәкъдим иткәч, мин шунда ук ризалаштым. Минем өчен бу – үсеп килүче буынны тәрбияләүгә йогынты ясау мөмкинлеге, чөнки балалар – әллә ничә тапкыр кабатланган фикер булса да, безнең киләчәгебез бит.

Биредә без үз ватаннарын һәрвакыт яратачак һәм яклаячак патриот малайлар һәм кызларны тәрбиялибез. Бу – үзеңнең гаиләңә, туып-үскән җиреңә, кече ватаныңа һәм тулаем туган илеңә мәхәббәт. Аны көчләп тагарга кирәкми, әмма шәхси үрнәктә тәрбияләргә кирәк. Кадетлар мәктәбендә моңа күп игътибар бирелә. Эти-әниләр дә балаларына нәселнәсәпләре турында сөйләсен иде, бу очракта үз тарихлары белән кызыксыну һәм горурлану алар өчен нормага әйләнәчәк.

Кадетлар мәктәбе дисциплина гына түгел ул, чөнки аны тәмамлаучыларның барысы да хәрби карьераны сайламый бит. Аларда тәрбияләнгән җаваплылык хисе һәм кешеләр белән аралашу күнекмәләре кадетлар мәктәбен тәмамлаучыларга киләчәктә гаиләдә яклаучы һәм эшләрендә профессионал булырга ярдәм итә.

ТЕТЮШСКАЯ КШИ
НУРУЛЛИН В.Р.
ТЕТЮШСКАЯ КШИ
БОГАТОВ Д.Д.
ЕФИМОВ Е.С.
ТЕТЮШСКАЯ КШИ
ГРИГОРЬЕВ К.Д.

МИН ИНДЕ ИКЕ ТАПКЫР ПАРАШЮТ БЕЛӘН СИКЕРДЕМ!

Егор Журавлев, 10 сыйныф укучысы:

– Мин бирегә Киров өлкәсендәге кечкенә шәһәрдән килдем, 6 нчы сыйныфтан бирле укыйм. Балачактан ук хәрби булырга хыялландым. Туганнарым моның өчен, балигъ булуны да көтмичә, кадетлар мәктәбенә керергә киңәш бирде.

Бередә дисциплина яхшы, бөтен җирдә тәртип – һәм бу минем холкыма туры килә. Миңа тагын кораллы күнегүләр һәм хәрби әзерлек ошый. Ике тапкыр парашют белән сикердем инде, хәзер өченче тапкыр сикерергә җыенам. Беренчесендә бик куркыткан иде, икенчесендә инде ияләнәсең.

– Кадетлар мәктәбендә уку миңа күпкә кызыклырак, кайвакыт хәтта атнаның үткәнен сизми дә калам. Буш вакытта тренажерлар залына, китапханәгә барырга яки берәр файдалы эш эшләргә, мәсәлән, кар көрәргә була.

МАКСАТЫМ – ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХӘРБИ УНИВЕРСИТЕТЫНА УКЫРГА КЕРҮ

Диана Корсакова, 10 сыйныф укучысы:

– Кадетлар мәктәбе турында миңа алты ел элек әнием сөйләгән иде. Ул минем хәрби булуымны теләде, шуңа мине бирегә укырга җибәрде.

Баштарак миңа кыен булса да, тора-бара, кире-сенчә, бөтен нәрсә ошый башлады. Син нәрсәгә булса да омтыласың һәм моның сиңа кирәк икәнен аңлыйсың икән, кыенлыкларга инде игътибар итмисең. Минем хәзерге максатым – Оборона министрлыгы Хәрби университетына укырга керү.

Җәен кадетларга парашют белән сикерү мөмкинлеге бирелә, мин дә сикердем. Беренче тапкырында әле аңлап җиткермисең, ә менә икенче тапкырында инде куркыта, тик мин барыбер тагын сикерәчәкмен.

Мәктәптә кызлар егетләр белән тигез хокуклы, әз генә безнеңгә дә рөхсәт ителә. Егетләр безнең белән дус, безне яклыйлар, хәтта миңа мәхәббәт аңлатучылар да булды…

ХӘРБИ КАРЬЕРА ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАМ

Всеволод Черенков, 8 сыйныф укучысы:

– Мин инде 7 нче сыйныфта укый башлагач ук кадетлар мәктәбенә күчәргә җыенган идем, тик Казандагысында урын булмады. Җәен мин Тәтеш мәктәбенә кабул ителдем, һәм моңа бик шатмын.

Минем буем 1 м 90 см, мин мәктәптә иң озыны, хәтта тәрбиячеләрдән дә озынрак. Сыйныфташларым баштарак миннән бераз шүрли иде, хәзер инде минем дусларым күп, бигрәк тә өлкән сыйныфта укучылар арасында.

Кадетлар мәктәбендә уку миңа күпкә кызыклырак, кайвакыт хәтта атнаның үткәнен сизми дә калам. Буш вакытта тренажерлар залына, китапханәгә барырга яки берәр файдалы эш эшләргә, мәсәлән, кар көрәргә була. Гомумән, дәрестән тыш физик йөкләмәләр җәза сыйфатында билгеләнә. Гадәттә мин шелтә алмыйм, тик менә үткән атнада берьюлы ике наряд эләктердем: беренчесен – сыйныфташымны коридор буйлап куган өчен, икенчесен – построениегә соңга калган өчен. Мин еш кына старшинадан үземне урамда эшләргә чыгаруын сорыйм, миңа саф һавада нәрсә дә булса эшләү ошый.

Хәрби карьера турында хыялланам. Офиста эшләү мине бер дә кызыктырмый, шунлыктан хәрби училищега керергә планлаштырам. Хәрби офицер булсаң, нинди шәп бит: сугыш тактикасы, хәрби амуниция – болар турында мин тәүлекләр буе укырга әзер! Күптән түгел безгә җыелма модельләр тараттылар, минем сыйныфка БМД-1 эләкте. Әзер модельне тәкъдим итү өчен мин аның техник характеристикалары һәм ул катнашкан сугышлар турында мәгълүматны җентекләп эзләдем.

Түземсезләнеп җәй җитүен көтәм: Коркачыкта беренче тапкыр парашют белән сикерәчәкмен һәм «Гвардеец» лагеренда яшь сугышчы курсын үтәчәкмен.

Автор:
Алёна Кутыркина

ДИВАРЛАР ҺӘМ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ АША – ЙӨРӘК ТҮРЕНӘ

Актлар залы туп-тулы. «Сугыш турында сөйләгәннәрен» тыңлар өчен берничә сыйныф җыелган. Лектор аудиториягә мөрәҗәгать итә:

– Арагыздан кемнең дә булса Нюрнберг процессы турында ишеткәне бармы?

Барысы да, авызына су капкандай, эндәшми. Соңгы рәттә утырган бер малай гына, курка-курка, кулын күтәрә. Бөтен залга – берүзе. Дулкынланудан тотлыга-тотлыга, җавап бирә:

– Бу – Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң үткәрелгән суд. Анда Җиңү яулаган илләр фашист Германиясе башлыкларын хөкем итте...

Малай булдырды. Тик ул, кабатлыйбыз, бөтен залга берүзе иде. Калганнар, аның яшьтәшләре, сугыш турында бик аз белә – кызганыч дәрәҗәдә аз, дияр идем. Конкрет бер мәктәп укучылары гына түгел. Кызганыч, бүген Россиядәге мәктәп укучыларының Бөек Ватан сугышы, ягъни аларның ата-бабалары туган илләре өчен җанын биргән яу турындагы белемнәре, йомшартып кына әйткәндә, шактый сай.

...Лектор Александр Лапко, малайның җавабын тыңлап, сүз башлар өчен, күңеленнән беренче җөмләсен уйлый. Балаларга сугыш дәһшәтләре, кешелек дөньясына каршы кылынган җинаятьләр һәм безнең Җиңү тарихын башкача язарга омтылу турында бәян итү генә кирәк түгел аңа. Моны күңел төпкеленә чын-чынлап үтеп керерлек итеп эшләү зарур. Аның әйткән сүзләре уйланырга, тоемларга, аңларга мәҗбүр итсен өчен...

– Искерми торган, һәрвакыт мөһим булган фактлар бар һәм аларны барлык киләчәк буыннар да истә тотарга тиеш, «Нюрнберг процессы дәресләре» лекциясенең башы аудиторияне кирәкле ешлыкка көйләп җибәрергә мәҗбүр итә. Яшүсмерләрнең карашында әле яңа гына шайтаннар бии иде, ә хәзер анда – игътибар һәм җитдилек...

– Балачактан ук мин илебез тарихы һәм, аерым алганда, Бөек Ватан сугышы тарихы белән кызыксындым, – дип сөйли миңа Александр Лапко. – Асылда, моңа һич тә гаҗәпләнерлек урын юк. Россиядә яшәп, сугыш турында белмәү, аны хәтердә тотмау, миңа калса, бер дә килешми торган эш булыр иде. Тик, шуңа да карамастан, берничә ел элек мин кинәт шуны сизә башладым: үткәндәге хәтта иң хәлиткеч вакыйгалар да өлкән буын кешеләре аңында акрынлап тоныклана башлый. Балалар турында әйтеп тә торасы түгел!

Һәм мин эшкә керешергә карар кылдым. Тормышка ашырылган тәүге идеям – Ватан сугышында җиңү китергән маршалларның исемнәре язылган баннерлар. Яшьтәшләрем сугыш турындагы мәгълүматларны шулай хәтердә яңартсын, ә балалар – кызыксынып, Интернетка өстәмә мәгълүмат алырга керсен дип теләдем. Әмма тиздән аңлашыла башлады: баннерлар гына җитеп бетми, ә куелган тырышлыкны максатчан рәвештә аерым бер аудиториягә юнәлтергә кирәк. Мин үзем өчен потенциаль төркемне билгеләдем – 5 нче сый-

Фото: Алёна Кутыркина

ныфтан 11 нче сыйныфка кадәрге укучылар, беренче курс студентлары. Аларны ничек кызыксындырырга да, мәгълүматны ничек җиткерергә? Фронттагы кебек өчпочмак хатлар уйлап таптым. Бу хатларга хәрби җитәкчеләр һәм алар кул астында барган сугышлар турында мәгълүмат урнаштырдым. Нәтиҗәдә, хәрби маршал турында һәр яңа баннер янына ун меңлек тираж белән бастырылган хатлар да өстәлде.

Ә Нюрнберг процессы турындагы лекциям 2015 елның күңелсез вакыйгаларына каршы үзенә күрә бер җавап булды. Хәтерләсәгез, ул вакытта ил буенча яшүсмерләр вандализмы белән бәйле дулкын узды. Балалар Бөек Ватан сугышы каһарманнарына һәм вакыйгаларына багышлап куелган һәйкәлләрне мәсхәрәләп, шуны видеоларга төшереп, роликларны социаль челтәрләргә урнаштырганнар иде. Бу гамәлләр – ата-бабаларыбызның батырлыклары турында елга бер тапкыр гына искә алучы өлкәннәрнең битарафлыгы нәтиҗәсе, дип ышанам мин. Бу хәлдән чыгу юлы бер генә – балалар күңеленә үтеп керергә, алар үзләре, бәлки, һичкайчан күрмәячәк нәрсәләрне күрсәтү.

Беренче тапкыр Әлмәт шәһәренең 10 нчы мәктәбендәге Актлар залында чыгыш ясадым. Үзем кайчандыр шушы уку йортын тәмамлаган идем. Тәэсире бик көчле булды, тыңлаучыларның күзләрендә яшь тамчылары ялтырады. Бер айдан соң мин һәр көн бер лекция укый башладым, көн саен башка бер мәктәптә. Лекцияләрне гел камилләштерергә тырышам, каткат эшкәртәм-шомартам. Барысын да яңабаштан кичереп сөйлим, чөнки мин ихлас булмасам, балалар ялганны тоеп алачак, шул чакта бөтен тырышлыклар да юкка чыгарга мөмкин.

Александр Вячеславович үз лекцияләрен «Нюрнберг. 70 елдан соң» документаль фильмы фрагментлары белән аралаштырып алып бара. Кинохроника ул. «45 нче елда Бавариядәге шәһәр хәрабәләр хәлендә ята. Анда Өченче рейх башлыкларын хөкем итәләр, нацизм белән соңгы сугыш – документлар, шәһадәтнамәләр, нервлар бәрелеше бара иде», – ди кадр артындагы тавыш. Фашист җинаятьләре шаһитларының истәлекләре тәкъдим ителгән икенче фрагменттан соң залда атмосфера тамырдан үзгәрә. Балалар тынып кала, аудиториядә ниндидер куркыныч тынлык урнаша.

Мондый очрашулар ахырында балалар, сүзсез генә лектор янына киләләр дә, илебез бөеклегенә һәм аның халкының героик характерына тагын бер кат инанганнары өчен, кулын кысып рәхмәт белдерәләр. Александр балаларны үзе белән таныштырганда: «Фамилиям – Лапка, тик ахырда «о» языла», – ди. Истә кала торган фамилиясе буенча кайберәүләр соңыннан аны социаль челтәрләрдә бик җиңел эзләп таба.

– Үзара элемтә бар, менә алар, уннарча фикерләр, – ди Александр, килгән хәбәрләргә күз йөгертеп, – мәсәлән, Академик лицейдан бер кыз язган: «Чыгышыгыз өчен зур рәхмәт әйтергә телим. Минемчә, бу хакта безнең буынга сөйләү бик мөһим, чөнки, никадәр генә күңелсез булмасын, болар барысы да онытылырга мөмкин. Дөресен әйтим, хәзер без (без генә түгел, барлык россиялеләр) ирекле һәм тыныч яши алсын өчен, ул кешеләргә ни кичерергә туры килгәнен күреп, күз яшьләремне тыеп тора алмадым».

Яки менә тагын берсе: «Бүгенге чыгышыгыз өчен зур рәхмәт, мин беренче тапкыр барысын да бик ачык аңладым; кайбер сыйныфташларым елмаеп утырдылар яки тыңламадылар, ләкин бу күз яшьләре күренмәсен өчен генә иде. Бүлмәгә кергәч, берәү дә сөйләшергә теләмәде, сүз әйтерлек тә түгел иде».

Лекция белән күп тапкырлар чыгыш ясаганнан соң, мин шуңа аптырашта калдым, нигә мин сөйләгәннәрне балалар беренче тапкыр гына ишетә, ә сорау биргәндә, бер генә кул күтәрелә? Укытучылар белән сөйләшкәч, Бөек Ватан сугышына нибары 3-4 дәрес кенә бирелүе ачыкланды. Ә Европада ул арада совет солдатлары хөрмәтенә куелган һәйкәлләр җимерелә, чөнки «Көнбатыш» нацистлар Германиясен җиңүдә Советлар Союзының ролен кечерәйтергә омтыла. Моны игътибарсыз калдырырга мөмкинме?

Балаларга кирәкле мәгълүматны җиткерүнең иң нәтиҗәле ысулы – аларның каршына аны бөтен асылы белән чыгарып кую. Бөек Ватан сугышы тарихындагы төп вакыйгалар һәм аның геройлары чагылдырылган 26 стендтан гыйбарәт «Сугышчан дан галереясе» турында идея әнә шулай туды. Мәгълүмат тагын да яхшырак үзләштерелсен өчен, галерея, нигездә, кыска, әмма тирән эчтәлеккә ия язулы фотосурәтләрдән тупланган иде. Стендларны урнаштырып чыкканнан соң, укытучылар баштагы вакытта балаларның галерея урнашкан ял урынында хәтта йөгереп йөрүдән дә тыелганын белдерде. Мин соңрак игътибарның кимегәнен аңлыйм, әмма алар бу мәктәптә 10 ел гомерләрен уздырачак, шуңа күрә әлеге мәгълүматның аңнарына сеңеп калачагына шик юк. «Татнефть» компаниясенең матди ярдәме белән «Сугышчан дан галереясе» 9 майга кадәр Әлмәтнең барлык мәктәпләренә дә куелачак.

Александр Вячеславович Лапко.
«ДИАЛОГ ПЛЮС» ҖЧҖ директоры, икътисад фәннәре кандидаты. Әлмәт районы Новотроицкое авыл җирлеге советы депутаты, «Россия хәрби-тарихи җәмгыяте» Гомумроссия иҗтимагый-дәүләт оешмасы һәм «Сугышчан туганлык» Бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасындагы Әлмәт бүлекчәсе әгъзасы, «Нюрнберг процессы: тарих һәм хәзерге заман» III Халыкара фәнни форумында катнашучы.

Бу проект республика кысалары белән генә чикләнеп калмыйча, россиякүләм югарылыкка ук чыкты. Кырымда «Нюрнберг процессы: тарих һәм хәзерге заман» Өченче халыкара фәнни форумында ясаган чыгышымнан соң, миңа Калмыкиядән шалтыраттылар. Анда да «Сугышчан дан галереясе» белән кызыксындылар, аларга бастырып чыгарыр өчен барлык материалларны бик теләп юлладым.

Бәхеткә, берничә ел актив эш дәверендә мин һич кенә дә рухи талчыгу тоймадым. Чөнки «ДИАЛОГ ПЛЮС» ҖЧҖ коллективыннан гыйбарәт ышанычлы таянычым бар. Барлык ният-теләкләрне бары тик аларның бердәм эшчәнлеге ярдәмендә генә тормышка ашырырга мөмкин.

Чиратта – Татарстанның тагын 20 районы, аларда бер тапкыр да лекция укыганым юк әле. Ул арада инде өч ел узды һәм өлкән сыйныф укучыларының яңа буыны үсеп җитте. Бу – чын күңелдән бирелеп эш йөртүне таләп итә торган чиксез процесс. «Сугышчан дан галереясы» акрынлап илебезнең барлык мәктәпләрендә дә пәйда булыр дип бик өметләнәм. Безнең балалар, нәкъ менә аларның үзләренең ата-бабалары, немец фашизмын юк итеп, бөтен дөньяны куркыныч афәттән коткарып калганын белеп үсәргә тиеш. ■

Автор:
Татьяна Вафина

Гүзәллек шаһинәләреннән БӘЙРӘМ СЫЕ

Ир-егетләр бәйрәменә иң зур бүләк – кичке аш! Аның да гүзәллек шаһинәләре тарафыннан әзерләнгәне. Шуңа да бүген «Татарстан»ның аш бүлмәсендә нәкъ менә алар – «Татарстан миссы – 2019» Ралина Арабова һәм «Казан миссы – 2019» Дарья Лебедева. Бөтен гүзәллекләрен һәм сөйкемлелекләрен эшкә җигеп, алар безгә чын ирләр ризыгы – азу әзерли. Дөрес, классик рецептка гына йөз тотмыйча, үзләренчә итеп, «Татарстан миссларынча азу» дип тәгаенләп хәтта. Тагын әле диңгез кысласыннан салат хәстәрлиләр. Бәйрәм табыны салатсыз булмый бит инде!

ИР-АТ ЙӨРӘГЕНӘ ЮЛ

Ир-ат йөрәгенә юл ашказаны аша – әлеге борынгы хакыйкать гүзәллек шаһинәләренең һәркайсына мәгълүм. Гыйнварда жюри әгъзаларын буй-сыннары, нәзакәтлелекләре, шулай ук интеллектуаль конкурста күрсәткән белемнәре һәм тапкырлыклары белән сокландырган чибәр кызлар бер генә яктан – ашарга пешерү осталыгы буенча гына сыналмый калды. «Татарстан» әлеге мөһим җитешсезлекне төзәтеп, 2019 елның титуллы гүзәлләр дәрәҗәсен тагын да күтәрергә әзер.

Дарья Лебедеваның әнисе кызының тугыз яшеннән үк пешере-

Алинә Әхмәдишина фотолары

нергә яратуы турында сөйли, бигрәк тә тортларны тәмле итеп әзерли, ди. Әмма әлеге гаилә сәламәт яшәү рәвеше алып бара, спорт белән шөгыльләнә, шуңа да тортларны алар сирәк вакытта – бәйрәмнәрдә генә ашый. Аннан соң «фигура саклар» өчен өй артыннан ук башланып киткән Юдино урманы буйлап 7 чакрым йөгереп кайталар – файдалы да, рәхәт тә. Ралина Арабова, суган турый-турый, шулай ук пешеренергә яратуы хакында әйтә. Күп балалы гаиләдән булгач, еш кына аш бүлмәсендә кайнашырга туры килә икән аңарга. «Татарстан миссы»ның ике энесе бар. Әмма алар гаиләсендә әтиләре бик хасиятләп әзерләгән шашлыкны күбрәк яраталар. Татарстан өчен шундый гүзәл кызны шашлык ашатып кына үстергән дә инде ул! Әлегә эшебезнең асылы – кирәкле ризыкларны турау, ул арада без гүзәлләребезгә бик күпләрнең бирәсе килгән сорауларын яудырабыз:

Безгә кирәк:

Азу өчен:
- Суган – 2 данә;
- Кишер – 1 данә;
- Помидор – 3 данә;
- Маринадланган кыяр – 300 г;
- Ит (сыер ите) – 400 г;
- Бәрәңге – 700 г;
- Тоз, борыч – тәмена карап;
- Бизәү өчен яшел үләннәр.

Диңгез кысласыннан салат өчен:
- Диңгез кысласы ите – 2 төргәк;
- Черри помидорлары – 300 г;
- Майонез – тәменә карап;
- Сыр – 150–200 г.

«Татарстан миссы»:

ДӨРЕС ТУКЛАНУ ТУРЫНДА:

– Мин ниндидер аерым диеталар тотмыйм, ит яратам. Әтием – Кавказ ягыннан, иттән башка яши алмыйбыз.

ЧИШМӘ БАШЫ ТУРЫНДА:

– Балачакта Мәскәү районы исеменнән «Мини-мисс» конкурсында катнаштым һәм җиңдем. Шуннан «Татарстанның мини-миссы» бәйгесенә үттем. Энергетика университетына укырга кергәч, 2017 елда вуз гүзәлләре бәйгесендә җиңдем. Балигъ булгач, республика бәйгесендә сынап карарга булдым. Ике тапкыр катнаштым. Беренчесендә «Мисс фото» идем, икенчесендә инде төп таҗга ия булдым!

КАРШЫЛЫКЛАР ҺӘМ КУПАЛЬНИКЛАР ТУРЫНДА:

– Бик күпләр гүзәллек бәйгеләрендә кызларның купальниктан чыгуына карата канәгатьсезлек белдерә. Ни өчендер алар моны килешми торган, әдәпсез күренеш дип саный. Ни өчен? Пляжда без шулай ук купальниктан йөрибез ләбаса – шуннан ни зыян? Финалда безнең киемнәребез ябык. Бу бит матурлык конкурсы! Буй-сын матурлыгы да – шул исәптән. Кешеләр конкурска нәрсә күрәсен белеп килә дип уйлыйм. Купальниктан йөргән кызларны күрәсең килми икән, конкурска килеп йөрмә һәм вәссәлам!

АК ҺӘМ КАРА КӨНЛӘШҮ ТУРЫНДА:

– Бернинди көнләшү булмады. Барысы да минем өчен сөенде. Финалга кадәр үк кайбер кызлар кем җиңәчәк дип ставка ясаган иде. Кайберәүләр хәтта көрәзәлек итте... Мин бу эшләрдә катнашмадым, бары тик үз эшемне эшләргә һәм үтәмме-юкмы, дигән уйлардан качарга гына тырыштым. Читтән караганда, бу көрәзәлек итүләр кызыклы да, көлке дә.

ТАЛАНТЛАР ҺӘМ ОСТАЛЫКЛАР ТУРЫНДА:

– Әни безне спортка бирде, бернәчә төрөнә. Балачакта мине йөзәргә йөртте. Уртанчы энем бокска өйрәнде. Хәзер ул катнаш көрәш белән шөгыльләнә. Кече энемне – бүген аңа биш яшь тулды – шулай ук йөзәргә бирергә тели. Тагын мин флейта классы буенча музыка мәктәбен тәмамладым. Кызыл дипломга! Төрле музыка конкурсларында катнашканым булды, Мәскәүдә «Кремль йолдызчыклары» конкурсында икенче дәрәҗә лауреат булдым хәтта. Югары уку йортында ШТК командасында уйныйм. Күптән түгел республика фестивале үтте, без икенче урын алып, «Республика» лигасына чыктык!

ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ КОНКУРС ТУРЫНДА:

– Сораулар конкурсына махсус әзерләнмәдек, әмма барлык кызлар да, бик дулкынлансалар да, җавап бирә алды. Бигрәк тә 16 яшьлек кызга кыен булгандыр, аннан Лев Лещенко турында сорадылар – ул аны телевизордан күрсә дә, бер-ике тапкыр күргәндер. Ләкин ул җавап бирде, афәрин!

«Казан миссы»:

– Мин дөрес тукланырга тырышам. Иртән – ботка, төшке ашка – җиңелчә аш, кичен – балык, тавык яки күркә ите кушылган салат…

– Мин медицина университетында дүртенче курста укыйм. «Мисс КДМУ» конкурсында катнашып җиңүче булдым. Автомат рәвештә «Татарстан миссы» конкурсының финалына үттем. Үзем генә, әлбәттә, конкурска барырга җөрьәт итмәс идем, туганнарым илһам бирде, үгетләде.

– Табигатем белән мин йомык кеше. Халык алдына чыгу миңа һәрчак кыен бирелә: оялам, каушыйм. Һәм бу конкурс, шул исәптән купальниктан чыгу да, миңа үземне җиңәргә ярдәм итте. Ачыла, үземнең эчке каршылыкларымны җимерә алуыма бик шатмын. Гәрчә, болар миңа шактый авыр бирелде.

– Барысы да шатланды һәм ихластан котлады. Минем өчен бөтен волейбол командасы – 30 кеше җан атарга килгән иде. Алар миңа бик зур терәк булды. Хәтта плакат язып алып килгәннәр. Ул плакатны шунда ук күрмәвем өчен хәтерләре дә калды әле – дулкынлануым көчле булгандыр инде. Гомумән, алар чын спорттагыча – каты итеп җан атып утырды. Волейболда шулай кабул ителгән. Без гаиләбез белән волейбол уйныйбыз: әти «Динамо-Казан» (суперлига) командасының башлыгы, әни – «Динамо-Академия УОР» (яшьләр лигасы) командасының администраторы, апам да озак вакытлар волейбол белән шөгыльләнде.

– Миңа калса, күп кызлар таҗга лаек иде. Сайлап алу кыен булгандыр. Барысы да матур, талантлы. Кемдер – чын опера җырчысы, кемдер менә дигән итеп бии, мин ком белән рәсем ясадым… Барысына да ошады, гәрчә сәнгать мәктәбендә укымаган булсам да. Миңа һәрвакыт ошый иде бу төр сәнгать, өйрәнәсем килде, һәм мине өйрәттеләр. Мин бик бәхетле, шундый матур һәм талантлы кызлар арасыннан сайлап алдылар бит безне!

– Миңа спорт туры килде: гүзәллек конкурсы спортның кайсы төре белән ассоциацияләр тудыра, дип кызыксындылар. Җавап вариантлары бар иде, әмма мин үземнекен тәкъдим иттем. Без көч сынашырга әзерләнгәндә, туры мәгънәсендә мускулларыбызны ныгытабыз – ә бу спортның төрле төренә аваздаш, ә менә таҗ өчен ярыш спорт көрәшен хәтерләтә.

1. Кыздырабыз!

2. Әрчибез!

3. Кырабыз!

4. Чистартабыз!

5. Турыйбыз!

6. Салабыз!

7. Ваклыйбыз!

8. Өстибез!

9. Турыйбыз!

10. Пешерәбез!

11. Өстибез!

12. Турыйбыз!

13. Кушабыз!

14. Агызабыз!

15. Турыйбыз!

16. Телибез!



Дорогие читатели журнала „Татарстан"!
Я желаю Вам, чтобы все мечты и желания, которые Вы загадали, обязательно сбылись в нынешнем году. Желаю крепкого здоровья Вам и Вашим близким! Пусть Вас всегда окружает только прекрасное!

С любовью,
„Мисс Татарстан-2019"
Ралина Арабова

САЙЛАГАН ҺӨНӘР ТУРЫНДА:

– Белгечлегем – «Реклама һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр». Журналист була алам яки пиар-менеджер. Сәясәткә китә алам. Әлегә хәл итмәдем.

МОДЕЛЬ БУЛУ ТУРЫНДА:

– Март аенда «Россия миссы» конкурсына барам. Алга таба Россиядә һәм чит илләрдә уза торган төрле конкурсларда катнашачакмын.

20 ЕЛДАН СОҢ ҮЗЕМНЕ НИЧЕК КҮРҮЕМ ТУРЫНДА:

– Мин үземне бәхетле хатын һәм әни итеп күрәм. Һөнәргә килгәндә… мөгаен, иҗади булыр ул. Сәясәткә китәрменме, журналистикагамы – әлегә белмим. Барысы да булырга мөмкин. Балаларымны модельләр мәктәбенә бирер идем. Конкурсларда катнашсыннар! Үзеңне сынап, көчеңне барлап карау бик кызык, минемчә.

КИТАПЛАР УКУ ТУРЫНДА:

– Без бит иң күп укучы ил булып исәпләнәбез! Әмма мин китаплар буенча төшерелгән фильмнарны карарга күбрәк яратам. Яки китаплар буенча театрда куелган спектакльләрне дә. Качалов исемендәге драма театрында еш булам. Башта китапны укып чыгам, аннан соң фильмын карыйм яисә театрга барам. Киресенчә дә була. Мәсәлән, Булгаковның «Роковые яйца» китабын укып чыкканнан соң, рәхәтләнеп спектаклен карадым. Хәзерге вакытта күбрәк укуымда таләп ителгән махсус әдәбиятны укыйм.

ДҮРТ АЯКЛЫ ДУСЛАРЫБЫЗ ТУРЫНДА:

– Безнең өйдә Арчи кушаматлы мәче, Лариска кушаматлы күсе яши. Лариска – чын чибәркәй! Башка йорт күселәре миңа нигәдер ошамый, алар – гүя урамныкылар, шапшак кебек. Ә безнең Ларисочка – бик матур кыз. Бакчада этебез бар – Азия овчаркасы.

СӨЙГӘННӘРЕ ТУРЫНДА:

– Егетем юк. Әлегә миңа болай ошый. Берәү дә көнләми, берәү дә бернәрсәдән тыймый. Миңа һәрдаим теләктәш була торган, көнләми торган кеше очрасын иде. Юморны аңлый белсен, акыллы да, матур да булсын. Ак ат урынына ак автомобиль булса, яхшырак.


Дорогие мужчины, читатели! Желаю вам в этот прекрасный праздник, 23 февраля, боевого настроения, чистой любви, а также ярких, красочных и солнечных дней. Оберегайте и поддерживайте своих женщин.

Мисс Казань - 2019
Лебедева Дарья

– Мин дәвалау факультетында укыйм. Миңа табиб һөнәре кечкенәдән ошый иде. Белгечлекне без алтынчы курстан соң гына сайлыйбыз. Иммунолог буласым килә. Иммун системасы белән бәйле бик күп чирләр бар хәзер. Бигрәк тә балаларда.

– Мин төрле шәһәр чараларында катнашачакмын. Шулай ук безне «Идел миссы» конкурсына чакырдылар, ул җәй көне уза.

– Мин үземне табиб-иммунолог итеп күрәм. Балаларга ярдәм итәчәкмен. Үз балаларымны, телиләр икән, рәхәтләнеп модельләр мәктәбенә бирер идем. Бу мәктәп яхшы тәрбия бирә, бигрәк тә – кызларга. Үсеш һәм үзүзеңне тоту ягыннан.

– Бүгенге көндә иртәдән кичкә кадәр анатомия, гистология, офтальмология һәм башка медицина предметлары буенча әдәбият укыйм. Дәреслекләрдән тыш, тагын нәрсәдер укырга вакыт кала икән, янә медицинага кагылышлы китап укыйм. Мәсәлән, Генри Маршны. Ул табиб, нейрохирург, автобиографик китап язган зат. Мәктәптә кат-кат «Мастер и Маргарита», «Война и мир» әсәрләрен укый идем.

– Ике этебез бар. Ишегалдында безне Гельд – Мәскәү сакчысы саклый. Өйдә безне мальтезе токымлы Барни күзәтә һәм һәрдаим нәрсәдер сораныл йөри. Бик сөйкемле үзе, кунаклар килгәнне ярата.

– Минем йөргән егетем бар, һәм ул миңа һәрьяклап туры килә. Акыллы, миһербанлы, бар яктан терәк. Җаваплы да, юмор хисе дә бар, кайгыртучан һәм тугры да. Волейболчы ул, әле Грузиягә турнирга китте. Сагынып көтәм.

1. Турыйбыз!

2. Салабыз!

3. Ваклыйбыз!

4. Өстибез!

5. Болгатабыз!

6. Уабыз!

7. Сибәбез!

8. Телибез!

НИЧЕК ИТЕП ГҮЗӘЛ КЫЗЛАР ТӘРБИЯЛӘРГӘ

«Казан миссы»ның әнисе Маргарита Владимировна Лебедевадан киңәш:

– Кызларның һәрвакытта да матур күлмәкләре булырга тиеш. Аларны табынны матур итеп кору серләренә өйрәтергә кирәк – без кичке ашны һәрвакыт шәм яндырып ашыйбыз, өстәлне матур савыт-саба, чәчәкләр белән бизибез… Кызларны театрларга, «Татарстан миссы» кебек матур чараларга йөртү мөһим. Кыз бала спорт белән шөгыльләнгән хәлдә дә аның һәрвакыт спорт киемендә йөрүе кирәк түгел – тренировкалар өчен генә булсын, шул җитә. Башка вакытта күлмәк, биек үкчә кирәк, ягъни бар да – мода буенча. Кыз балага шуны аңлату да мөһим: нинди генә гүзәл булмасын, нинди генә югары титуллар алмасын, аның төп бурычы – гаилә. Ул ашарга әзерли һәм өй җыештыра белергә тиеш, әмма моның өчен рәхмәт көтмәсен, бу хатын-кызның гадәти вазыйфалары. Теләп башкарганда гына алар аңа авырлыклар китермәячәк һәм арытмаячак.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуының 30 еллыгын **НИЧЕК** билгеләп үттеләр

«Дембель альбомын» Әфганстан чиге аша **НИЧЕК** алып чыкканнар

Кыр Шонталасы башка авыллардан **КАЙСЫ** ягы белән аерыла

«Тимер кешеләр» **НИЧЕК** әйләнеп кайтты

ОТРЯД

МИН КАЙТТЫМ, ӘНКӘЙ!

15 февраль көнне Җиңү паркында сугышчы-интернационалистлар үзләренең төп әфганчылар юбилеен – совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуына 30 ел тулуны билгеләп үттеләр. 1989 елда нәкъ менә шундый ук февраль көнендә совет гаскәрләренең соңгы колоннасы, Амудәрья елгасы аша салынган Дуслык күперен узып, Әфганстан чиген кичә. 9 ел да 1 ай һәм 18 көн дәвам иткән сугыш тәмамлана.

30 ел дәвамында Әфганстан ветераннары, барысы бергә җыелып, ниһаять: «Мин кайттым, әнкәй!» – дигән күптән көтелгән сүзләрне әйтү бәхетенә ирешкән шатлыклы көнне искә алалар. Алар кайттылар. Ләкин барысы да түгел. Шуңа күрә бу бәйрәмгә килүчеләрнең – исән кайта алганнарның да, якыннарын көтеп җиткермәгәннәрнең дә – күзләрендә яшь. Җиңү паркында, 30 елдан соң – геройларга мәңгелек дан!

Фото: Александр Ефремов

CENTU

СУГЫШЧЫ-ИНТЕРНАЦИОНАЛИСТЛАРНЫҢ ДЕМБЕЛЬ АЛЬБОМНАРЫ

Армиядән дембель альбомы белән кайту – Совет армиясе солдатының намус эше. Әмма моны эшләү һәркемгә дә рөхсәт ителми. Мәсәлән, әфганчыларның бәрхет тышлы солдат альбомы чикләр аша үтә алмый, хәрби хезмәт көннәре турындагы истәлекләр хәтер сәхифәләренә генә уелып кала. Яшьлеккә хас тапкырлык булмаса, Салих Гайнетдинов белән Илшат Әхмәтҗанов та, шәт, дембель альбомнарысыз калырлар иде. Әмма солдатлар негативларны чик аша алып чыгып, өйгә кайткач фотографияләрне ясатып алып, үзләренә яңа дембель альбомы булдыралар. Барысы да тиешенчә – бәрхет тышлыгы да, буяуларны теш щеткасы ярдәмендә чәчрәтүләре дә – әйтеп бетергесез күркәмлек һәм мәңгелек истәлек. Әлеге истәлекләре белән Әфган сугышы геройлары – кичәге мәктәп эскәмиясеннән ут эченә киткән егетләр – безнең белән дә уртаклашты.

САЛИХ ГАЙНЕТДИНОВ

Фарахруд ш., Әфганстан

Хезмәт итү еллары: 1985-1987

Форма №29

Призывнику ____________

проживающему ____________

ПОВЕСТКА

На основании Закона СССР „О всеобщей воинской обязанности. Вы призваны на действительную военную службу и зачислены в команду № 69. (Здесь указывается номер, установленный для каждой команды областным военным комиссариатом).

Приказываю Вам „18“ апреля 1985 г. к „8“ часам явиться для отправки на сборный пункт по адресу: ____________

М. П. ____________ райвоенком

____
звание, подпись

„__“ ____________ 198 года







"ВАТАННЫ САКЛАУ – СССР ның ХӘР ГРАЖДАНЫның ИЗГЕ БУРЫЧЫ"

– ГРЕЧКО –

НАКАЗ

КАДЕРЛЕ ИПТӘШ!

Бу бәйрәм кичәсендә, сина Ватанны саклаучыларның данлы сафына озатканда, сина туганнарың, дусларың, коллективың наказ бирә:

– Совет кешеләренең тыныч хезмәтен куз алмасы кебек сакларга, Совет Армиясе сугышчысы бурычларын үрнәк тоста башкарырга,

–Сугышчан хәм политик хәзерлек отличнигы булырга, уз колхозыңның исемен югары йортергә, аның белән ныклы элемтә тотарга,

Халык сина ышанып корал тапшыра. Яхшы хезмәтен белән батыр сугышчы бурычын ахыргача акла!

Сина нык сәламәтлек, сугышчан чыныгу, яңа белемнәр, кутәренке кәеф телибез.

Синең коллективың, туганнарың, дусларың коммунизм хакына фидакарь эшләячәкләр.

Кләнче авылы культура йорты.

Сугыш ветераны [signature] /Бариев Ш.Б./
Партоешма секретаре: [signature] /Кадыров Э.Г./
"Патриот" клубы председателе: [signature] /Кадыров Д.Э.

ИЛШАТ ӘХМӘТҖАНОВ

Тулукан ш., Әфганстан

Хезмәт итү еллары: 1984-1986



За нашу Советскую Родину!

ВЛКСМ

КАМСКО УСТЬИНСКИЙ
(наименование райкома, горкома комсомола
РК ВЛКСМ Тат.АССР.
республики, края, области)
направляет тов. АХМЕТЗЯНОВА
(фамилия,
ИЛЬШАТА ГАДЕЛЬЗЯНОВИЧА.
имя, отчество)

на службу в пограничные войска
КГБ СССР.

Выражаем твердую уверенность, что Вы покажете пример образцового выполнения воинского долга по охране государственной границы Союза ССР.

М. П.

Секретарь комитета комсомола

ТМГ. Зак. 1449

За спиною и горы, и горе,
За спиною военный Афган.
И строкой автоматною вторит
Эхо долгое, прячась в туман.
За спиною погибшие души
И пропавшие души ребят.
И мы с болью ещё будем слушать
Эхо долгое, глядя назад...

Алексей Гудович

ТОРМЫШ ЮЛЫ

Совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуына 30 ел үтте. Хәзерге яшь буын Бөек Ватан сугышы турында күп нәрсә белә, Чечня вакыйгалары турында да ишеткәне бар, ә менә Әфган турында – бик аз... Ә бит анда катнашучылар һәм ул вакыйгаларның тере шаһитлары – армиядә хезмәт итүче бүгенге малайларның әтиләре, җаваплы җитештерү хезмәткәрләре бит. Алар үзләренең хәрби бүлекләрен дә махсус даталарда гына чыгара торган безнең арада яшәүче чып-чын һәм аз сүзле геройлар. Шундыйларның берсе – Әлмәттә яшәүче Рамил Мифтахов.

Әзерләде:
Наталья Хамматова

ИСКЕ АЛЬБОМДАГЫ БЕР ФОТО

Әфганстан сугышы аша үткән һәр кеше йөрәгенә гомерлеккә эз салып калдырган тетрәндергеч хәлләрне онытмый, хәтерендә яшереп саклый. Беренче тәэсирләр, ияләшмәгән мохит, кызыклы очрашулар яки гаҗәеп пейзажлармы ул – барыбер. Рамилгә, мәсәлән, Әфганстандагы чәчәкләр бик ошаган була. Журналист килер алдыннан гына альбомыннан табып алган, инде төсе уңа төшкән иске фотоларының берсендә хәрби формалы егет купшы бер куак янында кулларына чәчәк тотып басып тора.

– Гаҗәеп җир анда... Урыны-урыны белән тереклекнең әсәре дә юк, урыны-урыны белән шундый яшеллек утравы ки, хәтта таяк кадасаң, ул да үсеп китәр кебек. Елга өчәр тапкыр чәчәк ата, карап күзләр сөенә иде андагы үсемлекләргә.

Икенче фотода Рамил инде үзенең легендар ГАЗ-66сы фонында. Өлкән машина йөртүче-гранатомётчик Мифтахов хезмәтенең соңгы 9 аен шушы машинада Десхабс өязендә үткәргән. Башта ул Кабул шәһәренең Балла-Хиссар ныгытмасында укчы булган, анда 103 нче Витебск һава-десант дивизиясенең 357 нче парашют-десант полкы урнашкан. Ә хезмәтенең ахырында, Кабулдан сугышчыларга кыйммәтле йөкләр ташып, Кабул провинциясе кышлакларындагы заставаларны продукция, кием-салым, сугыш припаслары белән тәэмин иткән. Заставаларның бурычы 1982–1983 елларда кышлакларда инде болай да аз калган тыныч халыкны саклаудан һәм шулай ук таулардан корал, азык-төлек алырга төшүче дошман кәрваннарын чикләүдән гыйбарәт булган.

– Сез батырлык һәм геройлыклар турында язмагыз, – дип кисәтә мине әңгәмәдәшем. – Миндә алар булмады. Командир миңа гадәти көндәлек эшем өчен ике тапкыр бүләкләү кәгазе яза иде. Бездә һәр икенче кешене шулай бүләкли иделәр.

«Гадәти эш» – бу көн саен «духлар» миналап торган юллар буйлап йөк ташу. Машина йөртүченең хезмәте тулысынча сапёрның намуслы хезмәтенә бәйле, ә ул, билгеле булганча, бер генә тапкыр ялгыша. Мифтаховның күз алдында күп тапкырлар рульләрендә үзе кебек үк яшь егетләр утырган машиналар шартлый, бронетранспортёрлар һәм БМДлар яна.

«Духлар» гадәттә иртән-иртүк чыга. Кайдадыр алар, тыныч халыкны талап, азык-төлеккә ия була, ә кайдадыр «хәлләренә керүче» ярдәмчеләр табыла, һәм алар тарафына беркайчан да арт белән басарга ярамый. Бу турыда Рамилнең бик исенә төшерәсе килми. Әле истәлеккә әфган икмәген уручы шундый ук яшь, тыныч әфган егетләре белән бергә комбайн фонында төшкән фоторәсем дә сакланган. Әмма йөрәк түренә гомерлеккә кышлак янынннан узучы бер чакрым озынлыктагы, шулай да мәңгелек булып тоелган юл да уелып калган.

Таң беленгәч засадага чыккан десантчылар подразделениесе үзе үк аларны көтеп торган дошманнар чолганышына эләгә. Соңгы патронга кадәр атышалар. Шул чакта аларга ярдәмгә боеприпаслар төягән Мифтахов килә. Аның машинасына атулар бер генә минутка да туктап тормый. Кайсыдыр бер мизгелдә ул үзен үлем юлында дип хис итә һәм инде беркайчан да өемә әйләнеп кайта алмам дип уйлап куя... Ләкин боеприпаслар вакытында илтеп җиткерелә һәм подразделение чолганыштан котыла. 1983 елның 15 ноябрендә приказ буенча Рамил Мифтахов «Батырлык өчен» медаленә лаек дип табыла. Ә бүләкне инде аңа өенә кайткач, ил Совет Армиясе көнен бәйрәм иткәндә, 1984 елның февралендә хәрби комиссариатта тапшыралар.

Реклама

Фотолар авторныкы һәм Рамил Мифтаховның шәхси архивыннан

ТЫНЫЧ КҮК АСТЫНДА

Солдат беркайчан да өенә, туган шәһәре Әлмәткә кайткан көнен онытмаячак.

– Бернәрсә белән дә чагыштырып булмый торган халәт: бөтен кеше сиңа туганнарыңдай якын тоела, барысын да кочаклыйсы килә, бөтен җан ияләрен яратасың. Бу хис мине бик озак вакыт калдырмады.

Шулай булмый соң! 60 нчы елларда нефтьчеләр шәһәрен торгызган төзүчеләр гаиләсендә туып-үскән малай һәрвакыт һава-десант гаскәрләренә эләгү турында хыялланган. Урта мәктәпне һәм машина йөртүчеавтослесарь һөнәрен үзләштергән 65 нче училищены тәмамлаган егеткә чакыру кәгазе килә: 1981 елның 23 октябрендә чакырылыш пунктына килергә. Аның хыялына чынга ашу насыйп булган икән. Әмма үзен чынлыкта ни көткәнен аңлаганмы соң ул? Хәрби антка һәм укыту үзәкләренә озатылганчы ук булачак десантчылар алдына шундый сорау куелган: «Кемнең Әфганстанда хезмәт итәсе килми – сафтан чыгарга!» 170 кешедән нибары дүртесе генә чыга. Бәлки, бүгенге буын моны акыллы гамәл дип санар. Әмма ул заман егетләре башка камырдан әвәләнгән була шул.

– Без Советлар Союзында үскәнбез һәм тәрбияләнгәнбез, интернациональ бурычны үтәү безнең өчен намус эше иде, – дип аңлата үз позициясен Рамил Нурлыгаян улы.

Беларусьтагы «Лосвидо» укыту үзәгендә хәрби җитәкчелекнең бер егетне, начар ишетүе сәбәпле, Әфганда хезмәт итү өчен яраксыз дип тапкач, аның ничек өзгәләнеп елавын да хәтерли ул. Аның бик тә башкалар белән бергә самолётта Кабулга китәсе килгән. Шул чакырылыштагы 12 якташы, 12 Әлмәт десантчысы белән дембельдән соң туган шәһәрләрендә очрашу һәм аны үзенчәлекле итеп билгеләп үтү турында вәгъдә бирешкәннәрен дә яхшы хәтерли. Аларны язмыш төрле полкларга һәм Әфганстанның төрле нокталарына тарата. Шулай да алар тыныч күк астында очрашалар. Әмма инде бер-берсенә бөтенләй башка күз белән карыйлар, авыртулар, үлем, коточкыч курку һәм чын өметсезлек күргән күзләр белән. Аларның очрашулары әле дә дәвам итә. Теләгән кадәр еш түгел, әлбәттә. Һәркемнең язмышы үзенчә язылган. Бер уйласаң, Әфганстаннан соң хәрби интернационалистларга юллар ачык булган. Алар илнең теләсә кайсы шәһәрендә кабул ителгән, Рамил дәрәҗәле башкала вузына керә яисә Союзның масштаблы төзелешләренә һәм җитештерүләренә китә алыр иде. Әмма әлегәчә улын югалтудан курыккан әнисенең сүзенә колак салып, аның янында калырга булган. Бары хәзер, 30 ел узгач, үз улын Хәрби көчләр составына озаткан чакта гына, аның борчылуларын аңлаган. Кызы өчен дә борчыла ул. Тик ир бала гына армиянең чынлыкта ир-ат холкын ничек чыныктырганын аңлый ала.

БӘЙЛӘП ТОРУЧЫ ҖЕПЛӘР

1985 нче елда Мифтахов очраклы рәвештә җирле газетадагы белдерүгә тап була: Әлмәттә төзелә торган оек-оекбаш фабрикасы эшчеләр җыя һәм аларга яшәү урыны да бирә. Шуннан бирле аның тормышы шушы «Алсу» фабрикасы белән бәйле. Бүген ул бәйләү цехында технологик җиһазларны көйләүче булып эшләвен дәвам итә. Ә баштарак, Пермь краендагы Лысьва шәһәрендә укып кайтканда, шул ук вазыйфа «мастер ярдәмчесе» дип атала торган була. Рамил Нурлыгаян улы яшерми, эшләүчеләргә хезмәт хакын үзләре үк җитештергән продукция белән түләгән хәтәр 90 нчы елларда кыю сугышчыинтернационалист үз гаиләсен ничек туйдырырга белмичә, тәшенкелеккә бирелә һәм фабрика белән бәйләп торучы җепләрне өзәргә омтылып карый. Ул вакыттагы күпчелек кешеләр кебек үк, бизнес белән шөгыльләнергә омтылыш ясый. Тик аның тырышлыклары уңыш китерми, 3 елдан соң, 1999 елда, кабат фабрикага әйләнеп кайта.

– Мин кечкенәдән техника яратам, – дип елмая әңгәмәдәшем. – Әти миннән бөтен өй приборларын, будильникларны, хәтта күкеле сәгатьне дә һәрчак яшерде – мин аларны гел сүтеп карый идем, эчләрендә нәрсә булуы, ничек эшләвен белү кызык иде. Ә хәзер, эшем электрониканы һәм яңа компьютер программаларын өйрәнүгә нигезләнгән булгач, эшләү тагын да кызыклырак булып китте.

«Алсу» фабрикасы «СПМ-Нефтегаз» компанияләре группасына кергәч һәм яңа җитәкчелек җитештерү процессын җитди рәвештә камилләштерергә керешкәннән соң, технологик җиһазларны көйләүче эшнең яңа әйләнешенә чыгуны үз тәҗрибәсенә күчерә башлавын таный. Шулай итеп, Мифтахов башта Кытайда, аннан Кореяда булып кайта, анда укып, үз фабрикалары өчен сатып алына торган заманча бәйләү аппаратларына хезмәт күрсәтү практикасын үтә. Цехта Италия җиһазлары өчен җаваплы белгечләр дә бар, Рамил исә, үзе шаяртып әйткәнчә, «кореецлар буенча баш». Ул, билгеләнгән программаны үтәгәндә, станокларның бирелгән бизәкләрне, күзләр санын саклап, һәм төсләр буенча күпме җеп тотып, ничек эшләве турында бирелеп сөйли. Җиһазларның туктаусыз эшләвен тәэмин итү – Мифтахов намусында. Ә дисциплина һәм җаваплылыкка килгәндә, безнең геройга тиңнәр юк. Аның фикеренчә, хәрби хезмәт барлык ир-атларда нәкъ шундый сыйфатларны тәрбияли дә инде.

Бу Әлмәт кешесе үз эшендәге тотрыклылыкны һәм иртәгәге көнгә ышанычны да югары бәяли, югыйсә Әфганда бу аңа шулкадәр җитмәгән. Бүгенге көндә, ул «игълан ителмәгән» сугыш турында күп төрле поляр карашлар яшәп килгән вакытта, сугышчы-интернационалистларга игътибар һәм хөрмәт аеруча кыйммәт. Менә Рамил Мифтахов та аерым хис-тойгылар дулкынында коллегалары белән очрашуга җыена, ул очрашуны «СПМ-Нефтегаз» компаниясе җитәкчелеге предприятиедә эшләүче барлык хәрби хәрәкәт ветераннары өчен ел саен бәйрәм табыны янында оештыра. Аларның искә алыр нәрсәләре күп, бер-берсенең әрнүләрен аңлаучы дуслары да бар. ■

КЫР ШОНТАЛАСЫ: СУ БУЕНДАГЫ ДАЛА

Шуңа игътибар итәм: һәр төбәкнең, һәр авылның үзенә генә хас гадәте, сөйләме, җыеп әйтсәң, йөзе була. Алексеевск районының Кыр Шонталасы да республиканың йөзләгән авылларыннан үз йөзе белән аерылып тора.

Автор:
Руфия Фазылова

АВЫЛ ДИП ҖАН АТУЧЫЛАР

Кыр Шонталасы зур, борынгы авыл. Тарихы XVI гасырларга барып тоташа. Бүген биредә 560 кеше яши, 168 хуҗалык бар. Менә шушы саннарны яздым да туктап калдым. Ни өчен дигәндә, каршымда саннардан торган берничә бит кәгазь ята. Кыр Шонталасы авыл җирлеге башлыгы Фәнис Хәмәдиев безнең өчен махсус документ әзерләгән. Авыл турында сораша башлагач, кулыма менә шул бер кочак кәгазьне тоттырды. Алар белән, Шонталаны урап кайтканан соң, яхшылап танышып утырам. Бу саннар авылның бөтен чынбарлыгын күрсәтә кебек. Мисал өчен, Кыр Шонталасы авыл җирлегендә 2015 елда 9 бала туган, 15 кеше вафат булган. 2017 елда – 2, 2018 елда 3 сабый туган. Үлүчеләр санына килсәк, 2017 елда – 9 кеше, 2018дә – 12. Таблицада караганда бигрәк сизелә ул: туучылар саны үлүчеләргә караганда берничә тапкырга ким. Хәер, бу бер Кыр Шонталасы проблемасы гына түгел, бөтен республикада шушы хәл күзәтелә.

– Сездә дә яшьләр калмыймы? – дим җирлек башлыгына.

– Ни кызганыч... Мәктәпне тәмамлагач, чыгып китәләр дә бүтән кайтмыйлар инде. Әйе, йортларга газ, су кергән. Алай гына да түгел: бездә таш юл салынмаган бер генә урам да юк. Безнең авылдагы кебек юллар республиканың башка авылларында юк та дип беләм. Тик яшьләргә бу гына җитми. Һәм мин аларны аңлыйм. Заман үзгәрде бит. Безнең чордагы кебек балаларга мәктәпкә барып кайту гына аз. Ата-ананың ул-кызын сәнгать мәктәбенә, биюгә, бассейнга да йөртәсе килә. Ә болар авылда юк. Менә шуңа да яшьләр район үзәгендә булса да калырга тырыша.

Кыр Шонталасы районда сыер асрау буенча беренче урында тора икән. 158 сөтлебикә исәпләнә биредә. Аерым хуҗалыклар 4–5 баш сыер тота. Җирлектә КФХ булып теркәлгән 12 эшмәкәр бар. Берәүләре мөгезле эре терлек үрчетә, икенчеләре игенчелек белән шөгыльләнә. Иң эре КФХ хуҗасы Илдар Хамматвәлиев белән таныштык. Илдар белгечлеге буенча агроном икән, Казан авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаган. (Тормыш иптәше Ләйсән белән ике кыз үстерәләр.) Хамматвәлиевлар КФХ нда 30дан артык (!) техника гына исәпләнә. 900 гектар җир эшкәртәләр.

– Аерым районнарда фермерларга җир бирмиләр яки иң начар урыннан тәкъдим итәләр. Сезгә ничек 900 гектар бирделәр? – дим Илдарга.

– 600 гектары аның пай җирләре. Эшләгәнне күреп, авылдашлар шулай арендага бирде.

Авылдашларының карары аңлашыла: бер пай җире өчен Илдар 6 центнер иген бирә, ә колхоз урынында эшләүче «Кызыл Шәрык» агрофирмасы – 3 центнер. Гап-гади арифметика!

– Иген уңган елны бәясе түбән, уңмаган елны бәя кыйммәт була, дип зарлана фермерлар. Сезнең эшләр ничек? Халыкка да пай җире өчен әйбәт кенә бирәсез икән, – дим Илдарга.

Фото: Александр Ефремов

Иң эре КФХ хуҗасы Илдар Хамматвәлиев тормыш иптәше Ләйсән белән ике кыз үстерәләр.

– Төрлечә була. Узган ел минуска чыктык, быел исә уңыш та, бәя дә фермерлар өчен отышлырак туры килде. Көз көне игенне 7 сумнан авылдашларга саттык. Хәзер исә 10 сум 80 тиеннән читтән килеп алалар. Авыл кешесенә, әлбәттә, ул бәядән бирмим. Үз җирләрендә үскән иген бит. Гади халыкка игеннең бәясе 8 сумнан артса, хайван асрауның бер тиен файдасы да калмый. Шуңа бездә шәхси хуҗалыклар игенне көздән алып куя…

Авылларда еш йөргәч, фермерларның зарын да еш ишетергә туры килә. (Сыер асраган кешегә сөт бәясе түбән, иген үстерүчегә ягулык кыйммәт һ.б). Тик Илдар зарланмады. Хәер, бу аңлашыла да кебек: ул инде аягында нык тора. Даими эшләүче 4 кешесе бар, сезон вакытында 10лап ир-атны эшкә ала. Тракторлары кышын да тик тормый: авылларда юллар ача, башка вак-төяк эшләр башкаралар.

– Мин дәүләткә рәхмәтле, – диде фермер. – Акмаса да тама. Мисал өчен, техниканың күбесен дәүләт программалары ярдәмендә алдым: 50 процентын үзем түләп, калган яртысына субсидия кайтты. Ягулыкка да ташлама бирәләр. Мисал өчен, узган елгы чәчү вакытында ягулыкны 43 сум урынына 35 сум түләп алдык. Ни дисәң дә файда. Ашламага да ташлама ясала. Мондый шартларда эшләргә була әле.

Сөтчелеккә караганда, иген үстерү җайлырак, дип саный фермер. «Елга ике тапкыр ныклап эшләп аласың да ял итәсең. Ә мөгезле эре терлек яныннан ел әйләнәсе китеп булмый». Бәлки шулайдыр да. 18 ел бу өлкәдә эш тәҗрибәсе булган фермер белми әйтмәс.

Илдар Хамматвәлиевнең туган авылы өчен җан атып торуын да әйтергә кирәктер. Авыл башындагы зурлап ясалган «Кыр Шонталасы» язуыннан башлап, Мәдәният йорты янындагы обелискка кадәр үз акчасына эшләткән. Нәрсә турында гына сөйли башласалар да, «Илдар кулы» диләр.

«ӨЙДӘГЕЛӘРГӘ ӘЙТМӘДЕМ»

Февраль ае уңае белән ватанны саклаучыларның онытылыбрак кала торганнарын да искә алырга булдык. 15 февральдә Әфганстаннан совет гаскәрләрен чыгару көне, бу датаны да оныта алмыйбыз.

Шуңа Кыр Шонталасының да Әфган сугышын кичкән иратлары белән танышырга булдык. Гаилә дуслары, күршеләр – Наил Гарифуллин белән Фәнис Фәезов Әфганстанда хезмәт иткән. Наил абый тормыш иптәше Зәйнәп апа белән ике кыз үстерә. Күп еллар дәвамында авылда баш инженер булып хезмәт куйган. Бүген исә «Сельхозснаб» оешмасында эшли.

– И, без бит инде әллә ни батырлык эшләмәдек, – дип куйды Наил Гарифуллин. – Алты ай Төрекмәнстанда хәрби өйрәнү узгач, Әфганстанга – Шинданд провинциясенә җибәрделәр. 1983 ел иде ул. Анда аэропорт бар иде, без шуны сакладык. Дөресен генә әйткәндә, Әфганстанда сугыш бара икәнен без башта белмәдек тә. Ул вакытта интернет дигән әйбер юк бит. Әниләргә дә кайда икәнемне башта әйтмәдем, борчылып тормасыннар, дидем.

Наил абый тыйнак кына сөйли дә сөйли, әйтерсең, күршедәге алмагач бакчасын гына саклаган. Ник бер зарлансын…

– Сезнең белән хезмәт итүчеләр арасында һәлак булучылар күп идеме? – дим.

– Булды инде…

– Алайса гомерегез кыл өстендә булган ич! – дим. – Үлем турында уй килми калмагандыр башыгызга…

– Уйланып аласың инде… Тик озак түгел, алай утыра башласаң, саташырга мөмкин. Әфганстанда бит дошман белән күзгә-күз карашып сугышу булмады. Шулай да белеп тора идек: тау астыннан барганда синә таба теләсә кайчан ут ачарга мөмкиннәр. Бәхеткә, минем күз алдымда андый хәл булмады. Алла саклагандыр…

Наил Гарифуллин гаиләсе белән.

Гарифуллиннар йорты.

Гарифуллиннар яңа гына әтиләрен җирләгәннәр. Тәлгать абый 91 яшендә дөнья куйган. Мактаулы исемнәре булган, бик җор телле бабай турында якыннары еламыйча сөйли алмый.

– Андый кешеләр меңгә бер генә туа, – диде Зәйнәп апа. – Тагын бераз гына булса да яшәмәде бит... Мин шушы нигезгә килен булып килдем. Гомер буе бергә яшәдек. Аннан бер авыр сүз ишетмәдем. Ул йортыбызның күрке иде...

«НЫК БУЛГАНБЫЗ»

Икенче әфганчы – Фәнис Фәезов та күршесе кебек, гади, тыйнак булып чыкты. Наил абый кебек, ул да төпчек малай, туган нигездә калган. Бу йортта да өлкәннәр бар – әниләре Асия апа 91 яшендә. Соңгы араларда авырып тора икән. Тагын әле Фәнис абыйның алтмышка җитеп килүче бертуган апасы Рәзилә дә алар белән яши.

– Әнине дә, апаны да хатыным Рәшидә карый, рәхмәт яусын, – диде Фәнис абый.

Фәнис абый хәрби хезмәткә күршесенә караганда берничә ай соңрак китә.

– Наилнең Әфганстанда хезмәт итүен мин армиягә киткәнче белмәдем дә, – диде Фәнис абый. – Хәер, мин дә башта өйдәгеләргә, дусларга кайда икәнемне әйтмәдем. Аннан белделәр инде. Әни, курыкмагыз, монда барысы да тыныч. Сугыш бармый, дип өйгә хат яздым.

– Ә чынлыкта? – дим.

– Чынлыкта... Төрле вакыт булды. «Пяндж отряды»нда идем, чик буен сакладык. Вертолетлардан да дошманны күзәтеп йөрдек. Хезмәт вакытым тәмамлангач та, ике айдан артык өйгә кайта алмадым, җибәрмәделәр.

Фәнис абый Әфганстанда булган вакытларын әнә шулай кыскача гына бәян итте. Күршесе Наил абый кебек үк, ул үзен батырга санамый.

– Хәрби бурыч үтәү – ул гадәти хәл. Безне шулай өйрәттеләр. Әфганстандамы, башка җирдә хезмәт итәсеңме, барыбер. Безнең тәрбия шундый иде.

– Тик сез сугышта булгансыз бит. Ә Әфганстаннан, бүген инде беләбез, гомер буена җитәрлек тән ярасы, җан ярасы алып кайтучылар да байтак, – дим.

– Без нык булганбыздыр, дип уйлыйм. Хәзер инде утыз елдан артык вакыт үткән, ул вакыйгалар артта калган. Менә улыбыз Фәнзил язга армиядән кайта. Барнаулда хезмәт итә. Аларга без күргәннәр эләкмәсен...

Шулай диде дә Фәнис абый, тиз генә сүзне икенчегә борып, хатыны Рәшидә апаны ничек урлап кайтканы турында сөйләргә кереште.

– Танышкач, өч көн дигәндә, урлап алып та кайттык, – дип, мыек астыннан елмайды. – Чөнки аның йөргән егете бар иде, кияүгә алып куяр, дип курыктым.

Рәшидә апа күрше Урта Тигәнәле авылыннан икән. Чынлап та, кызның очрашып йөргән егете булган.

– Кыз ризалыгыннан башка шулай урлап китәләр идеме? – дим.

– Юк инде, – дип елмайды Рәшидә апа. – Риза булмасаң урламыйлар. Фәнисне күрдем дә ошаттым. «Чык миңа кияүгә», – дигәч, ике дә уйламадым, риза булдым.

– Урлау дигәне шул аның: әтиәниләргә алдан әйтеп тормыйсың, – дип сүзгә кушылды Фәнис абый. – Клубка дип чыгып киткән җирдән тоттым да Рәшидә белән кайтып кердем. «Әти-әни, мин өйләнәм», – дидем. Шулай итеп төнге уникедә безнекеләр Рәшидәнең әти-әнисе янына чыгып китте. Әйтмичә генә калдырып булмый бит инде! Кызлары клубка дип чыгып киткән җирдән кайтмасын әле!

...Менә шундый ике гаилә, ике дус, ике күрше язмышы. «Фәезовлар белән безнең ике йортка – бер ишек», – дип елмайды Зәйнәп апа. Мин моның серен хатыннарыннан да күрдем: икесе дә ачык, кешелекле, уңган затлар. Әфганчы дуслар хатыннарыннан уңган, кыскасы!

– Танышкач, өч көн дигәндә, Рәшидәне урлап алып та кайттым, – диде Фәнис Фәезов.

Руслан бу йортта дүрт, Юля биш яшеннән тәрбияләнә.

«ЯЗМАГЫЗ, РИЗА-БӘХИЛ ТҮГЕЛ...»

Алексеевск районында тәрбиягә бала алган гаиләләр шактый. Кыр Шонталасы авылында да бар икән андый гаилә. Тәрбиягә алган ике улларын олы тормышка озатканнар да, менә өченче бала – кыз бала тәрбияләүче ир белән хатынны күрергә теләп, өйләренә бардык. Тик... хуҗабикә ханым кырт кисте: «Безнең турыда язмагыз, риза-бәхил түгел!» Мин исә бу хәлгә аптырап киттем: ни өчен? Без бит гаеп эзләп йөрмибез. Сәбәбен соңрак аңладык.

– Әни, ник язмагыз, дисең? Бәлки, минем әти белән сиңа рәхмәт әйтәсем киләдер... – дип, сөйкемле генә егет каршы чыкты. (Бактың исә, тәрбиягә алган малайларның кечесе икән).

– Алайса әйтегез, тик мине генә кыстырмагыз, – диде ана кеше.

Шулай итеп өйнең түренәрәк уздык. Руслан бу йортта 4 яшеннән, абыйсы Радик 7 яшеннән яши булып чыкты.

– Әти-әни фаҗигале төстә вафат булгач, безне интернатка биргәннәр иде, – диде Руслан. – Алтмыш ике яшендәге дәү әниебез булган, тик ул безне тәрбиягә алырга теләмәгән. Казаннан без, Северный бистәсендә туганбыз. Сабый чагымны бик начар хәтерлим.

Руслан сөйләгәндә ана кеше дә килеп утырды. Улының сөйләгәннәрен күз яшьләре белән тыңлады.

– Мин әти белән әнигә бик рәхмәтле. Тормышка яраклашып үстек. Абыйга да, миңа да Казаннан бер бүлмәле фатир алырга ярдәм иттеләр.

– Улым, юкны сөйләмә. Фатирны сезгә дәүләт бирде, мин документлар гына җыйдым, – диде ана кеше.

– Әни, ләкин сез булмасагыз, без аны ала алмас идек!

– Юк, аларын язмагыз, сеңлем. Балаларны Аллаһ ризалыгы өчен

алдым. Кешегә сөйләп, кемгәдер мактанып йөрү кирәк түгел. Балалар бәхетле булсыннар, безгә рәнҗемәсеннәр. Шул гына...

Соңрак ана кеше ачылып китте. Баксаң, ул моннан егерме ел элек яман шеш белән авырган икән. Әгәр терелсәм, тәрбиягә бала алыр идем, дип әйткән сүзе дә булган. Һәм сүзендә торган – савыккач, ире белән балалар йортына киткән. Ул хакта менә ничек сөйләде ул:

– Интернатта иң беренче очраткан балам Руслан булды. Каршыма йөгереп килде дә: «Әни, сез мине алырга килдегезме?» – диде. Ул да түгел абыйсы Радикны да янныбызга алып килде...

Бу Күкләрнең билгесе, дип, ана кеше ике малайга да документ тутыра. Һәм үзләре белән алып кайтып та китәләр.

Руслан белән Радик бүген Казанда яши. Икесе дә югары белемле. Руслан 10 ел инде диндә, намазын калдырмый икән. Ә өченче балага – Юляга 14 яшь.

– Мин ике бала таптым, улыбызга 38 яшь тулды, – диде ана кеше. – Ә менә кызыбыз... тугач та үлде. Кыз үстерәсе килеп калды. Районның опека идарәсенә баргач: «Бер кыз бала булса, әйтерсез әле, тәрбиягә алыр идек», – дидем. Озак та үтмәде: «Биш яшьлек кыз бар», – дип шалтыраттылар. Әтисе белән икенче көнне үк Казанга киттек. Юляны барып күрдек. Бик ошаттык үзен, тиз арада документларны тутырып, үзебезгә алдык. Авылга кайтканда бер авыз сүз татарча белми иде, мәктәпкә кергәнче өйрәнде үзе.

Бу гаиләдә сәгатьтән артык утырып чыктым. Күбрәк аралашкан саен, ана кеше ныграк ачылды. Исемен күрсәтергә теләмәвенең тагын бер сәбәбе кешеләрдән читенсенү икән. «Акча дип бала алалар», «Фатирны да улларына түгел, үзләренә эшләткәннәр» кебек сүзләр ишеттергәннәр. Минем шуны әйтәсем килә: закон тарафыннан куелган таләпләргә җавап бирә алган, мондый теләге булган һәр гаилә бала алып тәрбияли ала. Ә фатир үзләштерүгә килгәндә, ул фәкать ятим балалар исеменә бирелә. Анда ата-ананың катнашы юк.

...Кыр Шонталасының затлы мәчетендә дә булдык. Аны авылдашлары Фәнис Гатин төзеткән. Указлы муллаларның аерым исемлеген эшләп, мәчеткә элеп куйганнар.

Указлы муллаларның аерым исемлеген эшләп, мәчеткә элеп куйганнар.

Белгечлеге буенча химия укытучысы, КДМУ мөгаллиме Галим Хисамов туган авылы – Кыр Шонталасы тарихын ныклап өйрәнгән. Алты басмасы дөнья күргән. Галим Хисамов сөйләгәннәрдән:

– Кыр Шонталасын аерым кешеләр XIV гасырда ук оешкан дип сөйли. Ләкин мин ул фикер белән килешмим, чөнки архивларда утырып, авыл тарихын ныклап өйрәндем. Документларда беренче мәчет 1683 елда төзелә, 1744 елда җимерелә, дип бирелә. (Авыл Нугай юлында бит). Ә менә ул чорда күпме кеше яшәгәне билгеле түгел.

Күрше Тигәнәле, Кызыл Яр авыллары якынча 1650 нче елларда төзелгән. Димәк, безнең авылга да халык шул тирәләрдән күчеп утырган булырга тиеш. Урманасты Шонталасыннан Госман исемле кеше авылга нигез салган, дип фараз кылырга җирлек бар.

Исеменә килгәндә, «Шон» – Сөн, ягъни елга сүзеннән, төрки яки фин-угыр кабиләләреннән алынган атама; «тала» – дала исеменнән килеп чыккан. Даладагы зур булмаган сулык дип аңларга кирәк. Чынлап та, авыл янында елга бар. Борынгы бабаларыбыз авылны шул хөрмәткә атаган булырга тиеш.

Тагын шуны әйтә алам: Кыр Шонталасының 40 процент кешесе чукындырылган булган. Аларны кире мөселман диненә 1830 елда Мөхәммәт мулла кайтара. Бу турыда документлар бар.

КАЗАН ТӘХЕТЕНДӘ – КЫРЫМ ХАННАРЫ

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

Бер гасырдан аз гына артыграк яшәү дәверендә Казан ханлыгы белән Кырымнан да килеп идарә иткәннәр, ханнарны Касыймнан да, Себердән дә, Әстерханнан да чакырганнар. Барлыгы – унөч хан. Шулар арасында иң шөһрәтлеләре Кырым ханнары булгандыр, күрәсең. Сәхибгәрәй хан ярлыгы турында кемнәр генә ишетеп булса да белми икән?! Сафагәрәйне исә күпләр, Сөембикәнең ире һәм Үтәмешгәрәйнең әтисе булганга гына беләбез, дип шаярталар. Ничек кенә булмасын, бу ике хан тарихыбызда тирән эз калдырган.

Автор:
Фаяз Хуҗин

1519 елда, Мөхәммәд Әмин хан вафатыннан соң, 1445 елдан бирле Казан тәхетен биләп торган Олуг Мөхәммәд династиясе өзелә. Казанлылар, Мәскәүгә махсус илчелек җибәреп, хан тәхетенә Мөхәммәд Әминнең ул вакытта Мәскәүдә тоткынлыкта яткан энесе Габделлатыйф кандидатурасын тәкъдим итәләр, әмма Василий III хөкүмәте моңа каршы чыга. Кырык яшен дә тутырырга өлгермәгән Габделлатыйф кинәттән үлеп китә – аның сәбәбе беркемгә дә сер булмый. Казан тәхетенә Касыйм ханлыгыннан Шәех-Әүлияр ханның 13 яшьлек улы Шаһгали утыртыла. Мәскәү мәнфәгатьләрен алгы планга куеп эш йөртүче хан һәм аның даирәсе казанлылар арасында абруй казана алмый. Шаһгалигә каршылар – ә алар хөкүмәт әһелләре арасында да, гади халык арасында да күп була – Бакчасарайга яшерен илчелек җибәреп, Казан тәхетенә Кырым ханы Миңлегәрәйнең улын сорыйлар. Сөйләшүләр уңышлы тәмамлана.

Фиринат Халиков рәсемнәре кулланылды.

КАЗАН ТӘХЕТЕНДӘ – СӘХИБГӘРӘЙ

1521 елның язында Бакчасарайдан Казанга 300 кешелек атлы гаскәре белән хан тәхетенә тәгаенләнгән Сәхибгәрәй чыгып китә. Җәй башында алар Казанга килеп җитәләр. Шәһәр капкалары бернинди каршылыксыз ачыла. Көтелмәгән кунаклар алдында Шаһгали дә, Мәскәү илчесе һәм воеводасы да куркып-каушап калалар. Сәхибгәрәй сугышчылары исә, шул хәлдән файдаланып, шәһәрдәге урыс сәүдәгәрләрен, Шаһгали белән килгән хәрбиләрне, хөкүмәт тирәсендәге кешеләрне кыралар-суялар, аларның кибетләрен, андагы байлыкны талыйлар, йортларын яндыралар, кыскасы, шәһәрдә мәхшәр оештыралар. Нәтиҗәдә, рус елъязмачыларына ышансак, бер көн эчендә касыймлыларның биш мең кешелек хан гвардиясе, Мәскәү воеводасы Поджогинның бер мең кешелек отряды тулысынча тар-мар ителә. Шаһгали үзенең исән калган 300 кешелек кечкенә генә отряды белән Мәскәүгә качып китә. Казан тәхете, алдан уйланылганча, Сәхибгәрәйгә кала.

Миңлегәрәй хан угылы (һәм Кырым ханнары династиясен башлап җибәргән Хаҗигәрәйнең оныгы) Сәхибгәрәй 1500 елда Бакчасарайда туган. Димәк, Казан тәхетенә ул 21 яшендә утырган булып чыга. Аны тәрбияләүдә, милли аңы формалашуында билгеле бер күләмдә үги әнисе Нурсолтанның да йогынтысы булгандыр, дип уйларга кирәк. Инде белгәнегезчә, 1510–1511 елларда Нурсолтан Мәскәү әсирлегендә яткан улы Габделлатыйфны һәм Казан тәхетендә утырган улы Мөхәммәд Әминне күрү-ер өчен, вакыты буенча ел ярымга кадәр сузылган олы сәфәр кыла. Ун яшьлек Сәхибгәрәйне дә үзе белән ала. Алдан уйлап эш йөртүче зирәк акыллы хатынның бу гамәле очраклы түгел, әлбәттә. Сәфәр вакытында Сәхибгәрәй күпне күрә, күпне ишетә, Нурсолтанның да яшь ханзадәнең акылын кирәк юнәлештә чарларга мөмкинлеге була. Тарихчы галимнәрнең бердәм фикере буенча, Сәхибгәрәйнең Казан тәхетенә утыртылуында Нурсолтан хәлиткеч роль уйнаган булырга тиеш.

Сәхибгәрәйне Казанда ачык йөз белән каршы алалар. Ул тышкы кыяфәте белән үк үзенең элгәресе шыксыз Шаһгалидән аерылып торган: зифа буйлы, каратут йөзле, бераз кырысрак, көче ташып торган чибәр егет. Хәтта рус елъязмачылары да аның турында: «Он был красив лицом – совершенное полнолуние, льющее свет в созвездии миловидности», – дип язып калдырганнар.

Казан ханы буларак аның беренче кылган гамәле шул була: тәхеткә утыруның икенче көнендә үк диярлек бертуганы Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй белән сөйләшеп, Мәскәү кенәзлегенә яу оештыра. Ука елгасында урыс полкларын тар-мар итеп, Түбән Новгородны алалар, шәһәрне талыйлар-яндыралар, аннан соң Мәскәүгә юнәләләр, аны камап алалар. Олуг кенәз Василий III Сәхибгәрәй белән солых төзергә мәҗбүр ителә. Килешү шартлары буенча, Мәскәү «элекке заманнардагыча», ягъни Алтын Урда дәверендәге кебек, Казанга ясак түләп торырга тиеш була. Икенче төрле әйткәндә, Сәхибгәрәй хан Казанның Мәскәүдән бәйле-

Мәскәү илчеләренең XVI йөз Казанына килүе.

XVI йөздә Болак ягыннан кышкы Казан.

легенә чик куя, Мәскәүнең Казан өстеннән 1478 елдан бирле дәвам иткән протектораты бетерелә. Бу Сәхибгәрәй хан хөкүмәтенең зур җиңүе була. Ханлык тарихында яңа чор башлана.

1523 елда, төрле сәбәпләр табып, Казанда сәүдә итеп яткан урысларга тагын бер һөҗүм оештырыла, аларның күбесен үтерәләр, товарларын тартып алалар. Чуалышлар вакытында хәтта үз кешеләрен якларга чыккан Мәскәү илчесе Поджогин да үтерелә. Бу хәлләрне ишетеп, Василий III Сура елгасы тирәсенә, Казан ханлыгының чик буйларына гаскәр җибәрә һәм биредә киләчәктә татарларга каршы көрәштә форпост ролен үтәргә тиешле яңа калага – Васильсурск крепостена нигез салына.

Шул ук елда Сәхибгәрәй хан, Мәскәү белән Казан арасындагы көрәшнең киләчәктә тагын да көчәеп китүен күзаллап, Төркия белән килешү төзи һәм үзен төрек солтаны Сөләйман Кануниның вассалы итеп игълан итә. Бу да Сәхибгәрәйнең уңышлы адымы дип каралырга тиеш, чөнки нәтиҗәдә Казан ул заманнарның иң көчле мөселман дәүләтенең яклавына, ярдәменә өметләнә алган.

Сәхибгәрәй ханны күпләр 1523 елның 1 гыйнварында ул ниндидер бер аксөяк Шәех Әхмәт белән аның туганнарына бирелгән һәм безнең көннәргә кадәр сакланып калган тарханлык ярлыгы буенча беләләр. Аның 23 юлдан торган тексты 18 х 76 см үлчәмдәге кәгазьгә язылган. Астагы өлештә Җучиләр йорты тамгасы – кызыл квадрат (13,5 х 13,5 см) рәвешендәге мөһер эзләре саклангган. Ярлык әмирләргә, хакимнәргә, хөрмәтле шәхесләргә, урыннардагы түрәләргә, барча халыкка, гомумән, «бөтен Казан өлкәләренә һәм бөтен патшалыкларга» мөрәҗәгать белән башланып китә. Әлеге документта Шәех Әхмәтнең һәм аның туганнарының (барысының да тулы исемнәре санала) элеккеге тарханлык хокуклары тагын бер кат раслана, аларның байлыгын саклау гарантияләнә, төрле төрле салым, ясак, бурычлардан (җир салымы, морҗа салымы, азык-төлек һәм фураж җыю, куна кертү йөкләмәсе һ.б.) азат ителүләре әйтелә. Хан боерыгын бозучылар, «аларга көн булмаячак», дип кисәтелә. Яхшы гына сакланган бу ярлыкны 1912 елда Мамадыш өязе Мамалай авылында археограф һәм тарихчы Сәет Вахитов табып ала. Бүгенге көндә ул Татарстанның Милли музеенда саклана.

Эшләр гөрләп кенә бара кебек. Халык та ризасызлык белдерми, югарыдагы түрәләр дә тынычланып калгандай тоела. Әмма сәяси вәзгыять гел үзгәреп тора шул. Көтмәгәндә – бу 1524 ел була – Сәхибгәрәй Казанга бертуганының улы Сафагәрәйне чакыртып ала һәм тәхетне аңа калдырып, үзе башта Бакчасарайга, аннан соң Истанбулга китеп бара. Моның әлегә күпләргә аңлашылып җитмәгән җитди сәбәпләре бар, әлбәттә. Кырым ханы Мөхәммәд вафатыннан соң бушап калган тәхеткә дәгъва кылучыларның берсе Сәхибгәрәй була. Ызгыш-талашлар һәм бәхәсләрдән соң хан тәхетенә аның бертуган энесе Сәгъдәтгәрәйне утырталар. Бары тик 1532 елда гына, Сәгъдәтгәрәй тәхеттән үзе ваз кичкәч, Төркия солтаны Сөләйман Кануни Сәхибгәрәйгә хан урынын тәкъдим итә. Ул ризалыгын бирә һәм Кырым ханлыгы белән 1551 елга кадәр бик уңышлы идарә итә.

ТӘХЕТТӘ – САФАГӘРӘЙ

(1524–1531)

Ул – Сәхибгәрәй, Сәгъдәтгәрәй һәм Мөхәммәдгәрәй ханнарның бертуганы Фатыйхгәрәйнең улы. 1510 елда туган. Казан тәхетенә утырганда аңа бары тик 13 яшь кенә була. Аңлашыла ки, Мәскәү кенәзе Василий III Сәхибгәрәйдән соң бушап калган тәхеткә үзе билгеләгән кешене утыртырга тели. Ул Казанга каршы олы яу оештыра. 150 мең кешелек рус гаскәрләре Казанга таба өч юнәлештә: бер өлеше – (бу полкта хан тәхетенә тәгаенләнгән Шаһгали дә була) Түбән Новгород аша коры юл буйлап, калган икесе – Идел һәм Нократ (Вятка) елгалары буйлап хәрәкәт итәләр. Казанлыларның бәхетенә күрә, алар бер-берләре белән бәйләнеш тотмыйлар һәм Казанга сугышчылары да, аерым көймәләргә төялгән сугыш кораллары да бер үк вакытта килеп җитә алмый. Нәтиҗәдә руслар җиңелә. Солых шартлары буенча Мәскәү Сафагәрәйне Казан ханы буларак танырга мәҗбүр була.

Ачуы чыккан Мәскәү кенәзе, казанлыларга ниндидер этлек эшләмәкче булып, үзенең сәүдәгәрләрен Казан белән сәүдә итүдән тыя һәм Түбән Новгород янындагы Макарьев монастыреннан ерак түгел бер уңай урында яңа ярминкә – Мәкәрҗә ярминкәсе оештырып җибәрә. Ләкин Василий III нең бу карары беренче чиратта русларның үзләре өчен бик начар булып чыга: Урта Азия һәм башка Шәрык илләреннән, Кавказдан һәм Себер якларыннан килгән товарлар Казанда тоткарланып кала, Мәкәрҗәгә барып җитми. Рус сәүдәгәрләре зыянга эшли башлый.

Сафагәрәйнең эшләре уңышлы гына башланып китә. Казан төзекләндерелә, шәһәрнең бистә өлеше ныгытмалар белән уратып

алына. Вакыт-вакыт чыгып торган низагларны хөкүмәт әгъзалары бергә сөйләшеп хәл итәләр. Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне җайга салу өчен Василий III янына илчеләр җибәреп торалар. 1526, 1528, 1529 елларда җибәрелгән илчелек җитәкчеләре рәвешендә рус елъязмаларында Апай, Бәхтегилде, Чура, Табай, Ибраһим, Мамыш, Курат, Ширмәргән исемле «кенәзләр» телгә алыналар.

Әмма Мәскәү тынычланмый. 1530 елда алар Казанга чираттагы яу белән киләләр. Казанлаларга ярдәмгә Әстерханнан һәм Нугайлардан атлы гаскәрләр җибәрелә. Әмма сугыш рус гаскәрләренә уңыш китерми һәм алар Сафагәрәйгә каршы көрәштә яңа, «тыныч» ысулга күчәләр. Мәскәү илчеләре Сафагәрәйгә каршы көчләрне Казанның үзеннән эзләп табалар һәм аларны урыслар файдасына эшләргә күндерәләр. Мәскәү яклы төркемнең башында Булат Ширин һәм мәрхүм Мөхәммәд Әминнең сеңлесе Гәүһәршад тора. Шул көчләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә Сафагәрәй тәхеттән куыла. Ул бер төркем гаскәре белән Ногай Урдасына, хатынының әтисе янына китеп котыла.

Казанда исә башында Гәүһәршад торган вакытлы хөкүмәт оеша. Бу хөкүмәт тәхеткә руслар тәкъдим иткән Шаһгалине түгел, ә аның энесе Җангалине утыртып куя.

САФАГӘРӘЙНЕҢ КАЗАНГА КАЙТУЫ
(1535–1545)

1533 елның декабрь ахырында Казанга Василий III нең вафаты турында күптән көтелгән хәбәр килеп ирешә. Мәскәү тәхете тирәсендәге ыгы-зыгыдан файдаланып, Гәүһәршад хөкүмәте моннан соң руслардан бәйле булмаган мөстәкыйль сәясәт алып барачагы турында белдерә. 1535 елның 25 сентябрендә Җангали үтерелә, аның урынына яңадан Сафагәрәйне чакыралар.

Сафагәрәй 1536 елның кышында Түбән Новгородка, җәен Костромага, 1537 ел башында Муромга яу чаба. Аның бу гамәлләре Елена Глинская хөкүмәтен Мәскәү дәүләтенең көнчыгыш чикләрен ныгыту буенча төрле чаралар үткәрергә мәҗбүр итә. Чик буйларында Балахна һәм Буй ише яңа крепость-кальгалар барлыкка килә. Кырымның Сәхибгәрәй хөкүмәте рәсми рәвештә Казан ханын яклавы турында белдереп, Мәскәүгә

Сөембикә диваны.

хат юллый. Елена Глинская хөкүмәте аңа бик кыю һәм шактый тупас язылган хат белән җавап бирә: «Ты называешь Казань своею, но загляни в старые летописи: не тому ли всегда принадлежит царство, кто завоевал его? Говоря о твоих мнимых правах, молчишь о существенных правах России. Казань – наша, ибо дед мой покорил ее [в 1487 г.], а вы только обманом и коварством присваивали себе временное господство над нею». Уйландыра торган җавап.

Сафагәрәйнең икенче тапкыр ханлык итүе бик авыр шартларда үтә. Ул, казанлыларга артык ышанмыйча, хакимияткә Кырымнан килгән тарафдарларын якынлаштыра. Гәүһәршад, Булат Ширин һәм аның тирәсендәге бәк-морзалар, кырымлыларның кысулары русларныкыннан бер ягы белән дә аерылмый, дигән сылтау табып, Сафагәрәйгә каршы оппозиция оештыралар, Мәскәү белән яшерен сөйләшүләр алып баралар. Ләкин 1545 елда Мәскәү ярдәме белән оештырылган фетнә уңышсыз тәмамлана, Гәүһәршад һәм Булат Ширин үтерелә. Соңыннанрак, 1546 елның гыйнвар башында, оппозиция барыбер Сафагәрәйне тәхетен ташлап китәргә мәҗбүр итә. Сәед Биюрган җитәкчелегендәге вакытлы хөкүмәт тәхеткә яңадан Шаһгалине утырта, әмма ул бер-ике ай чамасы гына идарә итеп кала.

ХАКИМЛЕКНЕҢ СОҢГЫ ЕЛЛАРЫ (1546–1549)

Казанга үз гаскәре белән Сафагәрәй кереп урнаша. Бу юлы аның хакимлеге үтереш-суешлардан башлана. Аңа каршы оппозициядә торган элеккеге хөкүмәт әгъзалары үтерелә, алар урынына кырымлылыр куела. Мәскәү яклы фирка тулысынча тар-мар ителә. Мәскәү дәүләте Казанга каршы яу оештырып карый, гаскәрләр Зөя тамагына кадәр үк китеп җитәләр, әмма Казанны басып алырга җөрьәт итмиләр. Казан ханлыгы белән Мәскәү арасында беразга тынычлык урнаша.

Әмма Казанның үзендә хәлләр киеренкеләнә бара. Кырым килмешәкләре казанлыларны тәхеткә якын җибәрмәскә тырышалар. Гади халык исә ел саен арта барган салымнардан интегә. Боларның барысы да ахыр чиктә Сафагәрәй хакимиятен нык какшата, тотрыксызландыра. 1549 елның мартында ул һич көтмәгәндә үлеп китә. Бу үлемнең аңа каршы заговор нәтиҗәсе булуы беркемдә дә шик уятмый.

Тарихчы галимнәр Сафагәрәйне Казан тәхетендә утырган ханнарның иң мәшһүрләреннән саныйлар. Ул бит асылда Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге өчен, Кырым, Нугай, Әстерхан һәм Төркия кебек мөселман дәүләтләре белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен көрәшкән.



БЕЗ – КИТКӘН, ӘММА БЕЗДӘН КИТМӘГӘН ДӨНЬЯЛАР

Үткәнгә борылып карап язылган һәм төшерелгән китаплар белән фильмнар турында сөйләшик әле бу юлы. Аларны укыган, караганнан соң, заманның йөзе тагын да аермачыграк күренгәнгә... генә түгел, мәгълүмати сәбәп булганга да, бәлки.

«КЛАССИКА КАЙТАВАЗЫ»,
яки
КВАРТАЛЛАРДАН – ИРКЕН ДӨНЬЯГА

ЭЛЕНА ФЕРРАНТЕ. «НЕАПОЛИТАНСКИЙ КВАРТЕТ»

ФИЛЬМ «МОЯ ГЕНИАЛЬНАЯ ПОДРУГА»

Автор:
Луиза Янсуар

Элена Ферранте турында бүген үз гомерендә бер генә тапкыр китап тотып карамаган кеше генә белмидер. Time журналы аны дөньяның 100 иң абруйлы шәхесе исемлегенә кертте, шулай итеп, әле берничә ел элек кенә барлыгы да билгеле булмаган итальян язучысы чын әдәби сенсациягә әверелде. Җитмәсә, «Элена Ферранте» псевдонимы артында кем яшеренгән икәнлеген бу көнгәчә берәү дә белми. Шуңа да карамастан, дөньякүләм бестселлер булып танылган «Неаполитанский квартет» беренче китабыннан ук җитлеккән, оста куллы автор тарафыннан язылган булуы белән сокландырды да, гаҗәпләндерде дә. Аны бүген үк инде «яңа заман классикасы» дип атыйлар.

Боларны ни өчен искә алам? Мейнстрим, дип, йөз чөерергә кирәкми, диясем килә. Бу чынлап та укырга лаеклы китап. Лену һәм Лила исемле ике дус кызның бик гади, хәтта ки, беренче карашка, гадәти дә тарихы безне 50 нче еллардагы фәкыйрь Неаполь кварталына китерә. Шушы парадоксаль, драматик дуслык фонында Ферранте, артык күпертеп, маңгайга бәреп куймыйча гына, күпкә колачлырак масштабтагы үзгәрешләрне сурәтли – кварталның, шәһәрнең, илнең (Италиянең) фашизмнан арынып, мафия, кланнарга бүленү ятьмәсенә эләгүен, коммунизм иллюзияләренә күмелүен, алардан да кан коюга гына дучар булуын…

Әсәр башланып киткәндә үк интригага корыла: Лиланың улы, энисенең югалуы турында хәбәр итеп, Ленуга шалтырата. Һәм олыгайган ханым, яшьлекләренә кайтып, хәтер җебен сүтәргә керешә. Асылда, без бу дуслыкның бик катлаулы, шомлы этаплар узган икәнлеген ваемлыйбыз. Җәмгыятьтәге урыннары, интеллектуаль мөмкинлекләре һәм дөньяга карашлар яссылыгы буенча гаҗәеп төрле булуларына карамастан, кызлар бу дуслык-көндәшлекне гомер буена саклый. Соңыннан инде – аерым-аерым яшәсәләр, бер-берсеннән еракта торсалар да, – хәтердә көн дә яңарталар.

Фотолар: https://www.kinopoisk.ru һәм https://www.livelib.ru/ сайтларыннан алынды.

Бер табышкач, бер-берсенең дөньясын котылгысыз рәвештә тамырдан үзгәртә торган ике стихия, капма-каршылыкка корылган игезлек турында сөйли безгә Ферранте. Шуңа да бу стихияләр бер-берсеннән беркайчан да мәңгегә котыла алмый. Мондый очрашуны язмыш кешеләргә бер-берсенә орынып, яңа дөнья тудырырга омтылсын өчен бирәдер, бәлки, дип фаразлый кызларның берсе…

Ферранте романы фактурасы буенча без балачакта укыган «Маякчы кызы», «Солтангәрәйнең язмышы» романнарын хәтерләтә. Бөтен рухы, стилистикасы белән ул Диккенс, Шарлотта Бронте, Джейн Остен традицияләренә барып тоташа. Тәрҗемәдә, мөгаен, фәкыйрь кварталларның теле һәм сөйләш колориты югаладыр. Укыганда глобаль мегаполис шартларына күчеп барганны сиземләп үрсәләнүче үзебезнең эчке яшерен ностальгия калкып чыга, бәгырьне айкап ташлый. Кварталлардан тәпи йөреп китеп, Неапольнең хәллерәк кешеләр яши торган районнарына чыгу белән бу фәкыйрь балалар «квартал теле»ннән «гадәти телгә» күчә – шәһәр теленә. Шулай итеп, үзләренең «мескенлегеннән» арынабыз, дип ышана. Әмма аутентиклыгын, асылын җуюлары турында ул мәлдә әле берсе дә уйламый… Акрынлап, үсә-үсә, кварталдан зур дөньяга чыгып китеп, кеше булырга тырыша алар, әмма барыбер туган ояларына – «тиреслеккә» – кем булуларын раслар өчен кат-кат әйләнеп кайталар. Кайталар да, өзгәләнеп, кабат китәләр. Яшерен сагыну да, оялу да катыш бу тойгылары өчен үз-үзләрен гафу итә алмый иза чигәләр…

Провинциальлек нәрсә ул – әнә шул сорауга җавап эзли Ферранте. Ә миллилек нәрсә? Бүгенге кайбер галимнәр (социологлар, тарихчылар, политологлар) милләт төшенчәсе нәкъ менә индустриаль җәмгыять формалаша башлап, шәһәрләрдә халыкка үзен идентификацияләргә кирәк булганга барлыкка килгән, дигән караштa тора. Ферранте әсәре безгә бу гипотезаның чынбарлыкка шактый якын булуын күрсәтә. Аналитика аша түгел, ә каһарманнарының искиткеч нечкә сурәтләнгән психологик җан портретлары аша.

Мин балачагымны аз гына да сагынмыйм: безнең балачак көч басымы астында узды. Ул көч кайда барма, шунда эзәрлекләп йөри иде: өйдә дә, урамда да. Әмма мин бер генә тапкыр булса да безгә язмышның михнәтле, авыры туры килде, дип уйлаганымны хәтерләмим. Тормыш нинди бар, шундый иде. Без аны, башкалар килеп артык катлауландырмаса, үзебез әллә ни катлауландырмаска тырышып тик үсә бирдек. Мин, әлбәттә, укытучы апабыз белән руханиебыз алга сөргән, кирәк дип санаган итагатьлелек белән ихтирамнан баш тартмас идем, әмма безнең кварталда бу сыйфатларга урын юк иде. Хәтта хатын-кызлар арасында да. Хатын-кызлар ирләргә караганда да ешрак сугышты бездә: чәчләреннән йолкышып, бер-берсен җәберләп, җәрәхәтләп. Бу үзенә күрә бер чир, диярсең... Ир-атлар котырып китә дә, аннан сүрелә, әмма әниләр, әбиләр, тыштан тыныч, сабыр күренсәләр дә, бер чыгырыннан чыкса, соң чиккә җитми туктамый иде…

Әсәрнең буеннан-буена Неапольга мәхәббәт ярылып ята. Аны күрәлмау, аңа нәфрәтләнү, аны фаш итү битлекләре артында чарасызлыктан интегеп яшәгән үзәк өзгеч бер гомергә сузылган мәхәббәт. «Нәрсә ул, синеңчә, мәхәббәтсез шәһәр, – дип сорый дусларның берсе. – Ул – бәхетсез кешеләр яши торган шәһәр». Баштарак алар бу бәхетсезлекне күрмиләр, Неапольнең диңгезгә чыгып тора торган ярына бер мәртәбә дә барып карамаган, диңгездә коенмаган әти-әниләренең бил бөгеп узган гомере турында да уйланмыйлар. Алар бу шәһәрне дә, үзләренең мескен урамнарын, йортларын да сабыйларча абсолют ярату белән яраталар. Аннары, дөнья киңәйгән саен, аның барлык җитешсезлекләрен күрә, җирәнә, читенсенә, ояла башлагач кына Неапольга булган хисләре (бер-берсенә булган хис шикелле үк) чын сынау алдында кала. Бу сынауны узар өчен йөрәкләренең бөтен тамырларын умырырга туры килә… Тик әлеге дә баягы мескен кварталлар, көязләнеп, глобаль үзгәрешләр шаукымына бирелгәч, көннәрдән бер көнне икесе дә элеккеге сабый чактагы «тиреслекне» сагынуын абайлап ала…

«Кешеләр элек булган бар нәрсәләрне үткәндә калды, дип исәпли. Алар тыныч, мул тормыш хакына шул үткәннән баш тартырга ук риза. Ләкин белмиләр: үткәннән, ничек кенә тартышма, беркая да китә алмыйсың. Без әле һаман да инде үзе юк әйберләр арасында яшибез. Дөресрәге, алар бездә яши».

Элена Ферранте

«Непаолитанский квартет» дүрт китаптан тора. Беренчесен («Моя гениальная подруга»ны) экранлаштыручы продюсерларның берсе – кино сөючеләр даирәсендә зур шау-шу кубарган «Молодой папа» сериалы режиссеры Паоло Соррентино. Сериалның беренче сезоны инде прокатка чыкты, икенчесен дә без агымдагы 2019 ел премьералары чылбырында карый алачакбыз, дип ышандыралар.

«Моя гениальная подруга» беренче тапкыр 2018 елгы Венеция кинофестивалендә күрсәтелде. Аның режиссеры Саверио Костанцо моңа кадәр «Голодные сердца» триллеры белән тамашачы һәм кино тәнкыйтьчеләре игътибарын, ихтирамын яулаган

иде. Шуңа Ферранте романнарының экран версиясе нигездә фестиваль киносына якын булачагына шик юк иде.

Китапның уңышы, сораштырулар күрсәткәнчә, тарихи барышны нәкъ менә шушылай ике үсмер кыз күзлегеннән сурәтләп бирүдә. Балалар караш ноктасыннан кайбер хәлләр самими, беркатлы трансляцияләнсә дә, алардагы реакция, рефлексия бик әһәмиятле. Алар беренчел тойгыларга нигезләнеп фикер йөртә, бәяли. Фильмда да моны, шөкер, саклый алганнар. Без барыбыз да Фрэнсис Форд Копполаның Марио Пьюзо әсәренә нигезләнеп төшерелгән «Крестный отец» циклын хәтерлибез. «Моя гениальная подруга» кайсыдыр ягы белән аңа бик охшаган. Тагын әле ул әчке бер лиризмы белән үз заманында тулы бер буын өчен кадерле булган Серджо Леоненың «Однажды в Америке»сын да хәтерләтә.

Төшерүчеләр реализмга шул дәрәҗәдә омтылган ки, хәтта актерларга кастингны да Неаполь урамнарында уздырган. Фильмда профессиональ актёрлардан бигрәк, дебютантлар өстенлек итә. Хәтта төп рольләрне башкаручы героинялар да дебютанткалар арасыннан сайлана – Лила белән Лену берәүне дә хәтерләтмәскә, кабатламаска тиеш чөнки...

Кыскасы, романнар циклы заман әдәби тукымасына «классика кайтавазы»н кайтарган кебек, аның буенча төшерелгән сериал да стиле, эстетикасы белән без инде онытырга өлгергән нуар сулышын кайтарды.

КАҺАРМАННАР БЕЛӘН СӘЯХӘТ, *яки* КУЯННАР, ҮРДӘКЛӘР, КЕШЕЛӘР ТУРЫНДА...

Февраль ае – традицион «Оскар ае». Быелгы уенчылар арасында иң беренче сызыкта торучылар – Йоргос Лантимосның «Фаворитка»сы белән Альфонсо Куаронның «Рома» картиналары. Һәр икесе «Оскар»га 10 номинациядә дәгъва итә. 31 гыйнварда Россия экраннарында да прокатка чыккан һәм кино тәнкыйтьчеләре тарафыннан йә чиксез хупланган, йә чиксез тәнкыйтьләнгән «Фаворитка»га тукталмасак, дөрес булмас иде.

ЙОРГОС ЛАНТИМОС. «ФАВОРИТКА»

Номинацияләре:

- Иң яхшы фильм
- Иң яхшы хатын-кыз роле
- Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле
- Икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле
- Иң яхшы режиссёр
- Иң яхшы сценарий
- Иң яхшы оператор эше
- Иң яхшы костюмнар
- Иң яхшы монтаж
- Иң яхшы куючы рәссам эше

Бүләкләре: *2019 ел Алтын глобусы, Актерлар гильдиясе премиясе, 2018 ел Венеция кинофестиваленең махсус бүләге.*

Лантимосның бу лентасын күпләр режиссёрның бүгенгәчә төшергән «иң нормаль фильмы» дип атады. Бу сүздә хаклык юк түгел. «Клык», «Альпы», «Лобстер», «Убийство священного оленя» ленталарын хәтерләүчеләр килешми калмас. Бу юлы соңгы елларда Голливудның чын мәгънәсендә фаворитына әверелгән, кайберәүләр фикеренчә, аны гомумән стагнациядән ук коткарган грек режиссёры сәнгати алымнарына да, режиссёр кодексына да тугры калган, бер үк вакытта теләсә нинди әзерлектәге тамашачыга аңлаешлы да була алган фильм төшерүгә ирешкән.

Кемдер «Фаворитка»ны сарай интригаларына корылган тарихи фильм буларак кына кабул итәргә әзерләнеп килер кинотеатрга. (Ни өчен кинотеатрга, дим, чөнки аның бөтен «фишка»лары зур экранда гына бар яме белән ачылачак!) Килер дә... монда хәлләрнең күпкә катлаулырак икәнлеген күреп шаккатыр...

Лантимос ябык, клаустрофобик пространстволарны үз итә торган режиссёр. Җитмәсә, бу пространстволарда ул ситуацияне абсурдның соңгы чигенә җиткереп, каһарманнарын мантыйкның аргы ягында торган карарлар кабул итәргә һәм гамәлләр башкарырга этәрә. Дебора Дэвисның Британия тарихындагы XVIII гасырга – Англиянең Франция белән сугыш алып барган чорына кагылышлы сценарием да (ә ул – үзе бер мөстәкыйль әсәрне хәтерләтә!) «грек сихерчесе» үзенчә, «лантимосча», укый. Һәм: «Ни өчен королева Анна чоры кызыклы булды сезгә?» – дигән сорауга, артык тирәнгә кермичә, бик гади дә, гадәти дә җавап бирә: «Бу королева турында британлылар үзләре дә начар белә, бәлки шуңадыр. Ә сценарийга килгәндә, Дебора Дэвис королеваның герцогиня Мальборо һәм фрейлинасы Сара Черчилль белән булган мәхәббәт уеннары, интригалары фонында шактый четерекле проблема күтәрә – хатын-кыз хаким нинди ул, аның белән нинди импульслар идарә итә, аның стратегиясе, тактикасы нәрсәгә корылган?» Шулай итеп, Лантимос безне янә бер мәртәбә үзе яраткан темага китереп чыгара: кеше, башка затлар белән нинди механизмнар ярдәмендә идарә итә?

Җитди темаларны юмор, хәтта ки фарс аша ачып бирү дә – Лантимосның яраткан алымы. Шуңа герцог Мальборо белән сарайдагы башка дворяннарның затлы интерьерларда каз чабышлары уздырып ятуы, йә булмаса тере мишеньга җиләк-җимешләр төзәп атуы кебек күңел ачу ысуллары караучыны әллә ни аптыраштa калдырмастыр, дип уйлыйм. Җитмәсә, шуның аша без «икмәк һәм күңел ачу» шигаренең кайсы чорда да үз актуальлеген югалтмавын ваемлый алабыз. Королева Анна сарае белән безнең бүгенге җәмгыять яссылыгы, шул рәвешле, күзгә күренеп якыная төшә...

«Мин кешеләрне сәер, аңлаешсыз ситуацияләрдә күзәтергә яратам. Аларга уңайсыз һәм читен булганда. Комфорт зонасыннан чыккан мәлендә кеше ялангач булып кала, «чын» ягы белән ачылып китә. Һәм ул инстинктларына мөрәҗәгать итә. Инстинктлар ярдәмендә ситуациядән лаеклы рәвештә чыга ала икән, бу инде аның үз профессиясенең остасы булуы хакында сөйли. Димәк, мин аны, шикләнмичә, куллана алам».

Йоргос Лантимос.

Королева Анна чорын тарихчылар еш кына «Хатын-кыз патшалыгы дәвере» дип атый. Гәрчә чынлыкта хәлләр режиссёр картинасында сурәтләнгәнчә үк абсурдка барып җитмәсә дә. Әмма Лантимос безгә инде беренче мәртәбә генә кабатламый: «Минем өчен тарихи вакыйганың дәреслектә язылганча дөреслеге әһәмиятле түгел, фильмда мин дөреслек артыннан кумыйм. Тарихи җирлек минем өчен үз тарихымны сөйләргә сәбәп кенә...» Шул рәвешле, Лантимос Королева Анна һәм аның фавориткасы – «тимер ханым» – герцогиня Сара Мальборо белән аның яңа хезмәтчесе Абигейл Хилл арасындагы мөнәсәбәтләр «өчпочмагын» үз идеясенә туры китереп «әвәли». Нәтиҗәдә, без феминизм (ир-атлар монда фон гына), шәхси мәнфәгатьләргә, интригага корылган хакимиятнең һәм мәхәббәтнең (бүгенге политологлар һәм социологлар бу хакта күптәннән чаң суга), үз принципларыннан баш тарткан яки алар бөтенләй булмаган хәлдә тәгаен бер роль уйнарга мәҗбүр булган шәхеснең деградациясе (заман чирләренең иң күзгә ташланганы) турындагы бик тә заманча коктейльдән авыз итеп карыйбыз. Заманча, әмма ләкин конъюнктур түгел...

Лантимос фильмын уен структурасында төзи: ул шахмат тактасын да хәтерләтә, ачкыч тишегеннән караган квест булмәсен дә. Оператор Робби Райан эше аерым игътибарга лаек: камера, фото һәм кино сәнгатендә билгеле булган «балык күзе» алымын кулланып, үзенә бер тылсым белән хәрәкәт итә – тамашачы кинәт кенә эллипс формасына кергән бүлмәләрдә клаустрофобия тойгысы кичерә башый, тигезлеген җуеп, кинәт кенә авып китә, шуып төшә... нәрсәгә дә булса ябышасы, тотрыклылыкны саклыйсы килә, әмма барып чыкмый. Әлеге эффект фильм каһарманнары кылган гамәлләрнең дә чынлыкта юкка булуына ишарә итә гүяки... Кайдадыр канлы сугыш бара, ә монда – сарайның купшы, ләкин укшыткыч кысан пространствосында – шәхси бәрелешләр өстенлек итә. «Асылда, олы вакыйгалар гаять тар даирәләрнең шәхси мәнфәгатенә корыла» – Лантимос чыгарган вердикт әнә шундый. Ул яңа түгел, әмма аны әле болай итеп күрсәткәннәре юк иде моңарчы...

Фильмда бар да ачыктан-ачык һәм натуралистик чынлыгында күрсәтелә. Тәнкыйтьчеләр бу режиссёр тудырган антуражга карата яңа бер термин уйлап чыгарды: «физичность». Бөтенләе белән эстетик булмаган күренешләрдән үзенә күрә бер җирәнгеч, сискәндергеч эстетика тудыру – Лантимосның тагын бер «фишка»сы. Биредә, барокко стилендәге интерьерлар фонында, бу алым үтә бер җетелеккә ия.

«Мин үзем төшергән фильмнар аша беркайчан да нидер җиткерергә тырышмыйм. Анысы – минем эшем түгел. Персонажлар белән дә – шул ук хәл. Бу персонаж миңа мондый икән, дип, фильмның башыннан ук аны «танып алырга» тиеш түгел караучы. Әгәр ул аны беренче кадрлардан ук таныса, бу персонажга ияреп сәяхәт итү нигә кирәк?»

Йоргос Лантимос.

Шуңадыр, финал аерым бер киеренкелеккә ия: без, асылда, герцогиня Мальборо белән королева Анна каһарманнары аша аңлыйбыз моны. Коточкыч цинизмга, фарска корылган сарай вазгыяте эчендә аларның мәхәббәте һәм дуслыгы – бер йотым саф сулыш булган икән. Алар моны бергә чакта үзләре дә белмәгән... Әнә шундый якты, тәмле сулышлы лиризм белән өретеп, тулы тәэсирне үзгәртә дә куя режиссёр. Чиркану – кызгану, аңлауга, кире кагу – кабул итү... яратуга ук әверелә. Һәм син, фильмны репитка куеп, инде һәр ымны, һәр адымны башка караш белән карауга күчәсең. Пазл җыела. Җитмәсә, камераны катып калырга мәҗбүр итүче сихри эре-эре кадрлар белән сыйлый безне Лантимос: королева Аннаның азакта барысын да ваемлауга килгән мизгелен генә алыйк... аны өзлексез карарга мөмкин...

P.S. Без бүген феминизм турында сөйләргә һәм лаф орырга яратабыз. Аңа кадәрге һәм аннан соңгы дөньяны кыл икегә бүләбез. Көч басымы, хакимият басымы турында да еш сөйләнәбез. Ә менә асылда һәр нәрсәнең кабатлануга корылган булуы турында хәтерлибезме?

facebook.com/protatarstan

Реклама 16+

ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

МАХСУС ПРОЕКТ

— 39нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Илгиз Әхмәтҗанов,
«Республика наркология диспансеры» ДАССУнең баш табибы, февральдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Профессиональлек һәм кешелеклелек өчен рәхмәт

– Хөрмәтле Илгиз Илдарович! Республика наркология диспансеры коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән котларга телибез!

Сез тормышта үз юлыгызны табып, һөнәри күнекмә-тәҗрибәләрегезне кешеләрне дәвалау, аларга ярдәм итү өчен елдан-ел уңышлы кулланып киләсез. Сез медицина өлкәсендә һәрвакыт үсештә булырга омтылдыгыз, һөнәр нигезләрен иң түбәннән үзләштердегез, профильле белем алып, интернатураны уздыгыз, тәҗрибә туплап, «Татарстан Республикасы буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль дәүләт учреждениесенең Казандагы 10 нчы филиалында абруйлы җитәкче булдыгыз.

Хәзер исә, менә инде бишенче ел, «Республика наркология диспансеры» ДАССУнең баш табибы вазыйфасын башкарасыз. Без Сезне гадел җитәкче һәм хуҗалыкны оста алып баручы буларак беләбез. Сезнең тирәгездә һәрчак профессиональлек һәм иптәшләрчә ярдәмчеллек мохите хөкем сөрә. Сез алдыгызда торган барлык максатларга ирешә беләсез, чөнки сүзне озакка сузмыйча, вакытында эшкә керешергә күнеккәнсез.

Кешелеклелегегез, хезмәткәрләргә карата сакчыл мөнәсәбәтегез өчен рәхмәтләребезне ирештерәбез. Ветераннарга күрсәтелгән ярдәм өчен дә аерым рәхмәт. Сезгә сәламәтлек, иминлек, яраткан гаиләгез һәм хезмәттәшләрегез даирәсендә яңа матур бәйрәмнәр телибез!

«Республика наркология диспансеры» ДАССУ хезмәткәрләре

Марсель Хәбибуллин, «Түбән Кама наркология диспансеры» филиалы баш табибы,

Сирень Халиков, «Әлмәт наркология диспансеры» филиалы баш табибы,

Рамил Сатдаров, «Яр Чаллы наркология диспансеры» филиалы баш табибы

– Хөрмәтле Илгиз әфәнде, юбилей көнегездә барлык җылы котлауларга кушылырга рөхсәт итегез!

Шуларга өстәп, алга куелган максатларыгызны тормышка ашырыр өчен, Сезгә мөмкин кадәр күбрәк тормыш энергиясе телибез. Сезнең һөнәри абруегыз безне дә нәтиҗәле эшкә һәм уртак казанышларга омтылырга рухландыра. Игътибарлы киңәшләрегез һәм ныклы җитәкчелек итү сәләтегез өчен рәхмәт белдерәбез. Киләчәктә дә шундый ышанычлы һәм квалификацияле белгеч белән бер командада эшләргә өметләнәбез.

Фотолар «Республика наркология диспансеры» ДАССУ тарафыннан бирелде.

Реклама

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН СӘЯХӘТ ИТЕГЕЗ

Татарстанның үзенчәлекле урыннары буйлап сәяхәтебезне дәвам итәбез. Татарстанлылар яңалык тәкъдим итәргә бик оста, турист халкын үз музейлары «ятьмә»сенә «эләктереп алу» өчен ни генә уйлап тапмыйлар. Бу яктан бигрәк тә ярлы-елгалы районнарда яшәүчеләр шомарган – ятьмә үреп балык-киек аулау Чулман һәм Идел ярында яшәүчеләрнең канына сеңгән.

БАЛЫКЛЫ КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕ

Кайчандыр өяз үзәге булган Тәтеш шәһәрчегендә күңелләребезгә нәкъ менә шундый халәт инде. Балык биредә һәр җирдә – елгада да, кибетләрдә дә һәм... музейда да.

Автор:
Алёна Кутыркина

ИСКИТКЕЧ ПӘҺЛЕВАН БАЛЫК

Җирле халык аны,гади генә итеп, Балык музее дип атый. Тулырак исеме – Балык тоту тарихы музее. Тәтешлеләр бу музейны үзләре уйлап тапкан, аннары уй-ниятне тормышка ашыруда да эшне озакка сузмаган. Хәзер исә туристларның өзелеп торганы юк. Аларны ишек төбендә үк Тәтеш балыкчылары шушы тирәләрдә эләктергән иң атаклы балык (чын зурлыгындагы сын рәвешендә) каршы ала.

КЫРПЫ ТАРИХЫ

960 килолы могҗизаи кырпы балыгы тарихы ул елгадан тартып чыгарылганнан соң үткән йөз ел эчендә газеталарда, журналларда, Интернет челтәрендә күп тапкыр сөйләнгән инде, тик аны «ватан»ында – Тәтештәге балык музее янында гына табигый зурлыгында күреп була. Экскурсия вакытында йөз еллар элек булган вакыйгалар тәмләп тасвирлана. Идел буе төбәгендә ачтан интегүчеләргә гуманитар ярдәм сыйфатында балыкны ул чагында Казанга алып киткәннәр, ә менә аннан чыккан 196 кг кара уылдык тәтешлеләрнең үзләренә тәтегән. Биниһая зур кырпыны эләктергән балыкчы Александр Илларионович Страшин шул вакытта өенә бер чиләк кара уылдык алып кайткан! Их, булган бит заманнар...

Сүз уңаеннан, әлеге гаҗәеп кырпы бу тирәдәге елга-суларда тотылган бердәнбер зур балык түгел. Музейдагы балык һәм балыкчы даны диварына шул ук 1921 елда тотылган 415 килолы кырпы фотографияләре дә эленгән. Ә инде хәзерге заман балыкчылары шул ук күргәзмәдә 120 килолы җәен һәм 12 килолы чуртан белән мактанып тора, – тиз тәэсирләнүчән кунакларны бу да хәйран калдыра. Тәтеш районы Балык тоту тарихы музее филиалы мөдире Александр Петрунин гына могҗизалы балыкларның зурлыгын һәм аларның атамаларының бер-берсенә туры килүен дөрес бәяли, аңлата ала:

– 300 килограммнан авыррак балык кына чын кырпы дип саналган. Шуннан кечерәк булган барысы да – кырпы малайлары (белужата). Чөнки кырпы бер гасыр яши!

– Балыкчылык – күңел халәте ул, – дип саный Александр. – Ә Тәтеш – нәкъ менә балыкчылык ягы, биредә балык тоту белән борынгы заманнардан ук шөгыльләнгәннәр. Беренче балык тоту урыны безнең эрага кадәр II–IV меңьеллыкларда тәгаенләнгән булган, казу эшләре вакытында балыкчы коралы – ятьмәләр һәм тотылган балыкны озаграк саклау мөмкинлеге биргән ыслау урыннары да табылган биредә.

СУ АСТЫ ДӨНЬЯСЫ ТАРИХЫ

– Туган иләндә шундый шәп җирләр булганда, ә җирле халыкның активлыгы һәм фантазиясе көннән-көн яхшыра барганда, нигә кая да булса йөрергә әле? – дип, бу соравын журналист халкына юнәлтә Александр.

Яхшыра баруның ни аңлатканын без музейның үзендә үк күреп инана алдык. Аяк астында – пыяла идән, әйтерсең каядыр ерак Мисыр тирәсендәге диңгез төбе кебек су асты дөньясының мавыктыргыч тарихын күрсәтә ул – кызыклы да, матур да, хәйран да калдыра.

Әйе, XIX гасырда сәүдәгәр Полосухин – ә Балык мирасханәсенең бер өлеше аның йортында урнашкан – киләчәк музееи күз алдына да китерә алмагандыр. Хәтта заманча туристларга да мондый интерактив экспонатлар яңалык булып тора. Идеянең оригинальлеге Алабугадагы кер юу урынына (портомойня) һәм Зөядәге Агач археологиясе музеена бик шәп көндәшлек тудыра. Пыяла идәннән күренә торган су асты дөньясы экспонатларын теш табибы бүлмәсендәге кебек тәртипләп киштәләргә тезелгән мамонт тешләре, борынгы хәзинәләр, тарихи диорамалар һәм балык сурәтләнгән яртылаш көзге кисәкләре тулыландыра...

ГАШЫЙКЛАР ТАРИХЫ

– Элек кияү егетләре боларны кәләшләренә бүләк иткән, – дип аңлата ярты көзге рәвешендәге ядкәрләр тарихын экскурсоводыбыз. – Ә гашыйкларның берсе вафат булгач, көзгене яртылаш ватып алып, аны мәрхүмнең каберенә салганнар. Көзгенең икенче яртысы исә хуҗасының үлеменә кадәр саклана, – янәсе, теге дөньяда гашыйклар кавышсын өчен. Тәтеш риваяте Ромео белән Джульетта яки Изге Валентин турында легендалардан кайсы ягы белән ким? Менә шулай шул, һич кайтыш түгел.

ӘКИЯТ ТАРИХЫ

Экскурсия вакытында туристларны борынгы бер каберлектә табылып, баш сөяге нигезендә яңадан торгызылган бер тәтешленең (XV гасырда яшәгән) башы «күзәтеп тора». Әле нәкъ түшәм астында балык тотып утыручы малай да бар, күр дә тор, кырпы малаен эләктергәндәй, сезне дә кармагына каптырып алыр кебек. Бытырдап кайнап утырган аквариумдагы ялтыравык матур

Автор фотолары

В гостях
у рыбака

карпларның күзләре дә гел кунакларга төбәлгән. Җемелдәп торган зәңгәр яктылык әйләнә-тирәне әкияткә әйләндерә. Менә кемдер тәрәзә төбендә ачкычларын онытып калдырган – каптырмасында зәңгәргә ак төс белән уеп «су анасы» дип язылган…

– Сездә су аналары да бармы? – дип кызыксынабыз экскурсоводтан.

Александр елмая:

– Тәтеш музее Татарстанда экспонатлар саны ягыннан – иң зурысы.

Элек мондагы елга-суларда кырпы гына түгел, ә искиткеч әкияти җан ияләре дә булгалаган, дигән нәтиҗә ясыйбыз. Әкиятләрдәге су аналары да – яртылаш балык бит. Аларны ничек пешерергә икәне генә аңлашылмый, кызык, тәмле була микән?

– Бу җирлектәге иң тәмле балык – берш (Идел сыласы), – дип җавап бирә Александр, уйларыбызны сизгәндәй.

Тәтештәге балык кибетендә без кучтәнәч итеп нәкъ менә шул бершны сатып алабыз. Шуның янына корбан белән карпны да өстибез. Менә хәзер экскурсиябез тәмам дип санарга була. Бу як халкында бик төпле әйтем бар: Тәтештә булмаган кешенең чын балык күргәне юк! Арасында яңа тотылганы да, ысланганы, тозлысы да булган ярты еллык балык запасыннан тыш, без бу өлкәдә моңарчы һич ишетмәгән-белмәгән нәрсәләр белән зиһенебезне баеттык:



• Балык тәңкәсе белән бергә үсә. Аның һәр тәңкәсендә агачтагы кебек боҗралар бар, шулар буенча балыкның яшен билгеләргә була.

• XVII гасырда табигатьтәге балык ресурслары монастырь һәм чиркәүләр карамагында санала, шуңа күрә балыкчылар барлык кыйммәтле балыкны дәүләткә һәм чиркәүгә тапшырырга тиеш булганнар. Шул хактагы әмернең күчермәсе Тәтеш балык музеенда саклана.

• XIX гасырда Идел буйлап беляналар – зурлыгы заманча лайнерлардан һич тә калышмаган кораблар йөри. Алар рәт-рәт 200 чыршы борысыннан ясалган. Бу кораблар бер генә сезон хезмәт иткән һәм, барасы җирләренә ирешкәч, тулысынча сүтелеп, өлешләп сатылган.

• Тәтештәге Вшиха тавына бурлаклар әнә шундый исемне биргән, үзләре сөйрәп бара торган судно туктап торган вакытта, алар шушы таудагы мунчага юл тоткан һәм монда бетләрдән арына торган булганнар.

• Һәр бурлакка бригадада үз вазыйфасына туры килә торган кушамат тагыла. Алда баручыны «Шишка» дип атыйлар. Бригадада аның артына баса торган ике «урынбасары» «Подшишельные» дип йөртелгән. Судноны урыныннан кузгатучы иң нык ир-атлар исә «Ломовой»лар булып чыга. Ә «Забегающий» кушаматлысы алдан бара, бурлаклар үтәсе юлдан ботакларны җыеп, каршыга килә торган салларны һәм көймәләрне кисәтеп йөри. «Подневольный»лар исә – юлга чыкканда ук хезмәт хакын хәмергә тотып бетереп, аннан соң бригадада ризык бәрабәренә генә эшләгән бурлаклар.

• Кама сусаклагычы җәелгәнче, Тәтеш тирәсендә Иделнең киңлеге 900 метр гына була. Су биеклеге 28 метрга күтәрелгәч, елга 6 чакрымга киңәя. Шуннан соң еш кына балыкчылар кармагына су төбенә киткән йортлардагы төрле кирәк-яраклар да эләгеп чыккалый.

• Шалдер – җирле балыкчылар өчен иң яхшы транспорт. Халыкта аны «кишкотряс» дип атыйлар. Ул җирле осталар тарафыннан «Иж» мотоциклы нигезендә эшләнә, шуңа трактор яки «КамАЗ»дан өч камера куела. Шалдер – бөтен җирдә йөри ала торган транспорт, суда да батмый, тик закон тарафыннан тыелган, чөнки аны рәсми теркәп булмый. Т

«ТАТАРСТАН»НЫҢ АЛТЫН ЗАПАСЫ

«Татарстан» журналының фотобанкы яңа коллекция белән тулыланды – бу Рамил Галинең «Тимер кешеләр»е. 15 февральдә «ТАТМЕДИА» АҖндә 30 елдан артык стажга ия булган күренекле Татарстан фотографының күргәзмәсе ачылды.

Татарстан буйлап сәяхәт итеп, Рамил Гали төрле масштабтагы уникаль вакыйгаларның шаһиты гына булып калмаган, ә бәлки плёнкада тулы бер чорның тарихын чагылдырган елъязмачыга да әверелгән. «Тимер кешеләр» дигән исем белән аталган күргәзмәгә Татарстан кешеләренең 1988–1993 еллардагы тормыш эпизодлары кереп яшеренгән.

– Хәзер, 30 ел узгач, 1990 нчы еллардагы вакыйгалар тарих булып кына тоела башлагач, мин ул чорны искә алу һәм үзгәрешләр барган мәлләрдә кадрга эләккән төрледән-төрле кешеләрне күрсәтү өчен, шул чор фотографияләренә кабат кайтырга булдым. Ул чакта – драматик вакыйгалар барган, үзаңны үзгәртеп коруга китергән катлаулы елларда – рухы нык, холкы тимердәй кешеләр генә исән кала ала иде, – ди Рамил Якубович.

– Казан шәһәре мэриясе белән берлектә экспозицияне «ТАТМЕДИА» медиакомпаниясенең лаеклы фотожурналистлары күргәзмәләре белән ай саен яңартып торырга карар ителде, – дип вәгъдә итте ачылыш вакытында «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Андрей Кузьмин. Ул безгә 2019 елда бөтен республикадан унике фоторәссамның хезмәт нәтиҗәләрен күрә алачагыбызны хәбәр итте.

«Тимер кешеләр»нең фотографияләре «ТАТМЕДИА» АҖнең брифинг-залына илтүче коридор диварларын бизәп тора. Шунысы да игътибарга лаек: фотографияләр үзләре кайчандыр туган һәм ясалган урынга кабат әйләнеп кайтты – кайчандыр монда, нәшриятның беренче катында, фотолаборатория урнашкан иде. Нәкъ менә анда – химик матдә эремәләрендә, лампаның кызыл уты яктысында – узганнарның бүгенге мизгелләре дөньяга яралган да иде.

Рок-концерт. Улларын Әфганстанда югалткан гаилә. Татарстан мәчетендәге беренче фото. Коммунистларның соңгы митингы. Зәя психиатрия хастаханәсе пациенткасы... Бу туктап калган аклы-каралы мизгелләр – йөзләр һәм хисләр – үз чоры турында тарихның тулы бер булегеннән артыграк сөйләп тора.

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

2019 ел.
Казан ш., Җиңү паркы.
Совет гаскәрләренең
Әфганстаннан чыгарылуының
30 еллыгын бәйрәм итү.

Фото: Александр Ефремов

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый

1986 ел.
Тулукан ш.,
Әфганстан.

Фото Илшат Әхмәтҗановның шәхси архивыннан